Сегодня нет такого преподавателя, который не мечтал бы о том, чтобы его общение с учащимися было бы увлекательным, интересным, эмоциональным, а главное — тем ценным приобретением, которое бы ученики смогли преобразовать в собственное мировосприятие и мироощущение. Использование современных траекторий на уроках русского языка и литературы помогает научить школьников чувствовать слово и думать над ним, искать в нем истинный смысл, восхищаться всей «громадой» русского языка, выражать себя в творчестве. А также формирует личность школьника, помогает воспитать образованных, нравственных людей, которые способны к сотрудничеству, отличаются мобильностью, динамизмом, конструктивностью.

Однако следует особое внимание уделить внимание тому, что при использовании современных образовательных технологий, безусловно, должно присутствовать чувство меры. Не перегрузить, не нагромождать, не навредить, – этот постулат неоспорим. Целенаправленное формирование ключевых компетенций у учащихся возможно только при системном подходе к проблеме.

## ЛИТЕРАТУРА

1. Селевко Г. К. Современные образовательные технологии: Учебное пособие. – М.: Народное образование, 2004.

2. Никишина И. В. Инновационные педагогические технологии и организация учебно-воспитательного и методического процессов в школе. Волгоград: Изд-во «Учитель», 2008.

3. Тимонина В. Ю. Диалог о роли компьютера в преподавании русского языка / В.Ю.Тимонина, Л.А.Тростенцова // Русский язык в школе. – 2006. — № 4. – С. 14.

4. Асмолов А. Г. Системно-деятельностный подход в разработке стандартов нового поколения // Педагогика . – 2009 – № 4. – С. 18–22.

5. Шубина Т. И. Деятельностный метод в школе. http://festival.1september.ru/articles/527236/

6. Степанов Е. Н. Личностно-ориентированный подход в работе педагога: разработка и использование [текст] / Е. Н. Степанов – М.: ТЦ Сфера, 2003. – 128с.

7. Якиманская И. С. Личностно-ориентированное обучение в современной школе [текст] / И. С. Якиманская. М.: Сентябрь, 1996. – 96 с.

# ФОРМИРОВАНИЕ КОММУНИКАТИВНОЙ КОМПЕТЕНЦИИ УЧАЩИХСЯ НА УРОКАХ РОДНОГО ЯЗЫКА И ЛИТЕРАТУРЫ

**Р. Н. Габдулвалиева, Г. Г. Гафарова**

*МБОУ «Гимназия 175» Советского района г. Казани Республики Татарстан, Россия*
marselkom@mail.ru

# FORMATION OF STUDENTS' COMMUNICATIVE COMPETENCE IN THE LESSONS OF THEIR NATIVE LANGUAGE AND LITERATURE

**R. N. Gabdulvalieva, G. G. Gafarova**

*Municipal budgetary educational institution «Gymnasium 175»*
*Sovetsky district of Kazan, Russia*
marselkom@mail.ru

Коммуникативная компетенция – это осведомленность школьников в особенностях функционирования родного языка в устной и письменной форме, реализуется в процессе решения следующих практических задач: формирования прочных орфографических и пунктуационных умений и навыков; овладения нормами родного литературного языка и обогащения словарного запаса и грамматического строя речи учащихся; обучения школьников умению связно излагать свои мысли в устной и письменной форме. В результате обучения родному языку учащиеся должны свободно пользоваться им во всех общественных сферах его применения.
**Ключевые слова**: компетенция, мотив, новые педагогические технологии, дидактические принципы, электронные источники.

Communicative competence is the awareness of schoolchildren in the peculiarities of the functioning of their native language in oral and written form, implemented in the process of solving the following practical tasks: the formation of strong spelling and punctuation skills; mastering the norms of their native literary language and enriching the vocabulary and grammatical structure of students' speech; teaching schoolchildren the ability to coherently express their thoughts orally and in writing.
As a result of teaching the native language, students should freely use it in all public spheres of its application.
**Key words:** competence, motive, new pedagogical technologies, didactic principles, electronic sources.

# ТУГАН ТЕЛ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ УКУЧЫЛАРНЫҢ КОММУНИКАТИВ КОМПЕТЕНЦИЯСЕН ФОРМАЛАШТЫРУ

**Р. Н. Габделвәлиева, Г. Г. Гафарова**

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә укучыларның коммуникатив компетенциясен формалаштыру юллары күп галимнәрне җәлеп иткән актуаль проблемаларның берсе. Балада укуга, уку эшчәнлегенә ихтыяҗ, кызыксыну тудыручы эчке бер этәргеч булырга тиеш. Бу этәргеч «мотив» төшенчәсе белән билгеләнә. Мотив көчле булганда гына укучы активлык күрсәтә, ягъни уку эшчәнлегенә ихтыяҗ туа.

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә укучыларның коммуникатив компетенциясен формалаштыру түбәндәге дидактик принципларга таянып эшләүне таләп итә: күрсәтмәлелек, аңлылык, активлык, үти алу һәм көч житү, фәннилек, яшь һәм шәхси үзенчәлекләрне исәпкә алу, эзлеклелек һәм системалылык, тормыш белән бәйлелек, ныклы үзләштерү.

Укучыларның коммуникатив компетенциясен формалаштыру юлларын хәл итүдә укытуның актив метод, форма һәм чаралары ярдәмгә килә. Методик әдәбиятта укучыларның коммуникатив компетенциясен формалаштыру юллары укыту барышында әһәмиятле урын алып тора.

Укучыларның коммуникатив компетенцияләрен формалаштыру процессында укучыларга белем әзер килеш бирелми, ә бәлки алар аны мөстәкыйль танып-белү вакытында ала, ягъни төп игътибар укучының мөстәкыйль танып-белү эшчәнлегенә юнәлтелә.

Коммуникатив компетенция формалаштыру юлларын дөрес оештырганда, ул укучыларның тел өйрәнүгә карата мөнәсәбәтләрен уңай якка үзгәртә, белемнәрнең аңлылыгына этәрә, мөстәкыйльлеккә өйрәтә, иҗади фикерләүне үстерә.

Укытуның эчтәлеген, укучылар эшчәнлеген оештыруның оптималь формаларын куллану, дөрес алымнар сайлау көткән нәтиҗәгә ирешүгә юнәлтелгән. Болар – аралашуга, җанлы сөйләмгә таянучы методик алымнар комплексы:

1) Беренче планга укучыларны сөйләшергә өйрәтү чыга, ә теоретик материал, белешмәләр сөйләм процессында, текстны анализлау нәтиҗәсендә чыгарыла.

2) Аралашуга өйрәтү фикер эшчәнлеген үстерү белән бергә үрелеп бара, чөнки фикер йөртү аралашуга ихтыяҗ тудыра.

3) Аралашуга мотивация тудыру ярдәмендә өйрәтү. Укытучы укучыларда танып белүгә омтылыш уятуны нигез итеп ала.

4) Сөйләм эшчәнлеге төрләренә бер-бер артлы түгел, ә параллель рәвештә өйрәтү: һәр дәрестә сөйләм эшчәнлегенең дүрт төре дә катнаша. Дәрес максатында күрсәтелгән сөйләм дозасы сөйләм эшчәнлегенең дүрт төре аша да үтеп чыга. Алар: тыңлап аңлау (аудирование); сөйләү (диалог, монолог); уку; язу.

Сөйләм телендә вербаль чаралардан тыш вербаль булмаган чаралар да кулланыла (күрсәтмәлелек, хәрәкәт, мимика, ишарә, пауза һ.б.)

Коммуникатив компетенцияне үстерү бурычын хәл иткәндә, шулай ук хезмәттәшлеккә нигезләнгән яңа технологияләр куллану бик отышлы дип уйлыйбыз. Бу технологияләр түбәндәге нәтиҗәләргә китерә:

– укучыларда туган телне өйрәнүгә кызыксыну уяту, аралашуга өйрәтү;

– туган тел һәм әдәбияты дәресләрендә укучыларның эшчәнлеген активлаштыру,

– укучыларны эзләнергә мәҗбүр итү.

– укучыларның фикерләү сәләтен үстерү, белемнәрне камилләштерергә этәрү, уйлау.

– эстетик тәрбия бирү.

Яңа педагогик технологияләргә түбәндәге технологияләр керә: информацион, шәхескә юнәлтелгән, коммуникатив, уен, проблемалы укыту, иҗади үсеш, критик фикерләүне үстерү, проект технологияләре һәм башкалар.

Заман мәктәбен информацион технологияләрдән башка күз алдына да китереп булмый. Боларга интерактив такта, төрле техник чаралар керә. Бу, әлбәттә, мәктәпнең мөмкинлекләреннән чыгып оештырыла. Алар нигезендә:

– укучыларның укуга кызыксынуы арта; дәрестә эш формалары төрләнә;

– тиз арада укучыларның белем һәм күнекмәләрен тикшереп алу мөмкинлеге туа;

– барлык укучыларның да эшчәнлеген контрольдә тоту; укучыларны эзләнергә мәҗбүр итә.

Электрон белем бирү чыганаклары уку-укыту системасының аерылгысыз бер тармагы. Болар: Электрон китапханә, Татар иле, «Татар телле заман» сериясе, «Ана теле» онлайн мәктәбе, «Татармультфильм» берләшмәсе, укытучыларның шәхси сайтлары һ б.

Шулай ук, Май-тест, kahot программасын куллану да нәтиҗәле алым. Монда укучыларның белемнәрен тест формасында тикшерү каралган. Тестлар тел белеменең нинди дә булса бүлеген яисә сөйләм эшчәнлеген тикшерү максатыннан булырга мөмкин.

Коммуникатив технология, ягъни аралашуга өйрәтү технологиясен куллану шулай ук отышлы дип уйлыйбыз. Күнегүләр системасы аралашуга корылган. «Пресс» методы әдәбият дәресләрендә иң уңышлы методларның берсе дип саныйбыз. Әсәрне укыганнан соң кулланыла. Бу метод 4 этаптан тора: Ә. Еникиның «Матурлык» хикәясе нигезендә карап китик.

1. Үз фикереңне әйт. Мин хикәядәге төп геройның әнисен матур дип уйлыйм.

2. Фикереңне дәлилләЧөнки Бәдредтин үзенең әнисен бик ярата хөрмәт итә.

3. Фикереңне расла. Мәсәлән, әнисенең йөзе бик ямьсез булса да, ул аңа сокланып карый, шәкертләргә чәй ясарга әнисен чакыра, иптәшләреннән уңайсызланмый, әнисен күрсәтергә оялмый.

4. Гомумиләштерү, нәтиҗә. Димәк, кешедә тышкы матурлык кына түгел, эчке матурлык та бар дигән нәтиҗәгә килә алабыз. Бу алым укучыларның иҗади фикерләү сәләтен үстереп, сөйләмгә этәрә.

Ачкыч сүзләр алымын татар теле һәм әдәбият дәресләрендә дә яратып кулланабыз. Бу алымны парларда, төркемнәрдә, индивидуаль эшләр өчен тәкъдим итәбез. Мәсәлән, татар әдәбияты дәресләрендә әдәби әсәрне өйрәнгән вакытта тактага тексттан алып 4–5 ачкыч сүз язабыз. Бу ачкыч сүзләр алга таба әсәрнең эчтәлеген өйрәнүгә зур этәргеч бирә.Укучыларның күзаллауларына нигезләнеп, бу ачкыч сүзләр төрле юллар белән табыла. Ачкыч сүзләрне тапканда уен технологиясенең квест алымын кулланабыз. Квест алымы ул – инглиз теленнән тәрҗемә иткәндә, маҗаралы уен, эзләнү, биремнәрне үтәүне аңлата. Ә биремнәрне төрлечә бирәбез. Мәсәлән: дүрт рәсемнән бер сүз табу, ребус чишү, төшеп калган, яки артык сүзне билгеләү, хәрефләр җыелмасыннан сүзне табу һ.б. Бу алым укучыларны кызыксындырырга, белемнәрне камилләштерергә, эзләнергә этәрә, уйлау, фикерләү сәләтен үстерергә ярдәм итә.

Алга таба бу тапкан ачкыч сүзләргә фаразлау (гепотеза) алымын кулланабыз. Фаразлау алымы ул – булачак вакыйгага, мөнәсәбәткә башкалардан алда үз фаразларыңны белдерерү, күрсәтү, татар телен өйрәнүгә кызыксыну уяту. Укучыларга шушы сүзләрне кулланып хикәянең эчтәлеген күзаллап үз фаразларын язарга кушабыз. Аннан соң укучылар белән чыганак текст һәм үз фаразларын чагыштырабыз. Фаразлар өйрәнеләчәк әсәрнең эчтәлеге белән туры килергә дә, туры килмәскә дә мөмкин. Бу метод теләсә нинди мәгълүматка игътибарлы карарга, вакыйгаларның үсешен фаразларга өйрәтә, иҗади күзаллауны үстерә, укуны дәвам иттерергә этәргеч булган интриганы саклый (алга таба нәрсә булыр, минем фаразларым акланырмы һ.б.). сораулар нигезендә укучы кызыксына, уйлый, фикерли, эзләнә, иҗади фикерләү сәләтен үстерә, ахырдан нәтиҗә ясый.

Укучыларда коммуникатив компетенцияләр формалаштыруда безгә М. М. Шәкүрова, Л. М. Гыйниятуллина, О. Р. Хисамовлар авторлыгында эшләнгән «Туган тел (татар теле)» уку әсбабы да ярдәмгә килә.

2019–2020 уку елында без 1 нче сыйныфлар өчен нәшер ителгән яңа экспременталь дәреслек белән апробация үттек. Хәзер башлангыч сыйныфларда бу дәреслекләр белән эшлибез. Заманча төзелгән беренче сыйныф дәреслеге белән эшләү дәверендә без бу дәреслекнең коммуникатив технологияләргә нигезләнеп эшләнүенә игътибар иттек.

Укыту-методик комплекты татар телен туган тел буларак өйрәнә торган 1 сыйныф укучылары белән эшләүче укытучыларга тәкъдим ителә. УМК уку әсбабын, электрон дәреслекне, укучы өчен эш дәфтәрен, аудиоязмалар дискын һәм укытучылар өчен методик әсбапны үз эченә ала. Бу укытучылар өчен бик уңайлы. Электрон дәреслек тә, аудиодиск та укытучыга бик зур ярдәмлек булып тора. Уку әсбабы балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелгән. Бу дәреслекне кулга алуга, укучыларда кызыксыну уяна, чөнки ул бик матур рәсемнәр белән бизәлгән.

Урта (тулы) гомуми белем бирү оешмаларының башлангыч белем бирү этабында «Туган тел (татар теле)» предметы Федераль дәүләт белем бирү стандартларында күрсәтелгән гомуми белем бирү нәтиҗәләренә куелган таләпләргә туры китереп эшләнгән. УМК укучының коммуникатив компетенциясен формалаштыруга юнәлдерелгән. Балалар әдәбиятын, тарихын, фольклор әсәрләре аша өйрәтүгә зур игътибар бирелгән. Дәреслеккә кертелгән материаллар укучының тулы грамоталыгына ирешү, әйтмә һәм язма тел культурасын күтәрү һәм тел гыйлеменең морфология бүлеге буенча фәнни нигездә эзлекле белем күнекмәләре булдыруны күз алдында тотып эшләнгән. Моннан тыш укучыда дәреслектә китерелгән күнегүләр, мисаллар ана теленә мәхәббәт хисе тәрбияли, туган телебезнең матурлыгын тоярга өйрәтә. Коммуникатив компетенция формалаштыру юлларын дөрес оештырганда, ул укучыларның тел өйрәнүгә карата мөнәсәбәтләрен уңай якка үзгәртә, белемнәрнең аңлылыгына этәрә, мөстәкыйльлеккә өйрәтә, иҗади фикерләүне үстерә, матурлыкны танырга, кешеләрне аңларга өйрәтә.

Шулай итеп, коммуникатив компетенция формалаштыру юлларын дөрес оештырганда, ул укучыларның тел өйрәнүгә карата мөнәсәбәтләрен уңай якка үзгәртә, белемнәрнең аңлылыгына этәрә, мөстәкыйльлеккә өйрәтә, иҗади фикерләүне үстерә.

## ИЗУЧЕНИЕ ЛИТЕРАТУРНОГО НАСЛЕДИЯ АМИРХАНА ЕНИКИ В ВУЗЕ

**Г. Р. Гайнуллина**

*Казанский (Приволжский) федеральный университет*
gulfiarasilevna@mail.ru

## STUDYING THE LITERARY HERITAGE OF AMIRKHAN ENIKI AT THE UNIVERSITY

**G. R. Gainullina**

*Kazan (Volga Region) Federal University*
gulfiarasilevna@mail.ru

Вопрос изучения литературного наследия Амирхана Еники в высшей школе не становилась предметом научно-методических работ. Ранее в трудах методистов затрагивалась тема изучения литературного наследия Амирхана Еники в средней

школе. Важно проследить изучение студентами филологических факультетов классиков татарской литературы.
**Ключевые слова:** литературное наследие, Амирхан Еники, проза, миф.

The issue of studying the literary heritage of Amirkhan Eniki in high school did not become the subject of scientific and methodological works. Earlier in the works of methodologists, the topic of studying the literary heritage of Amirkhan Yeniki in high school was touched upon. It is important to trace the study of classics of Tatar literature by students of the philological faculty.
**Key words:** literary heritage, amirkhan eniki, prose, myth.

## ЮГАРЫ УКУ ЙОРТЫНДА ӘМИРХАН ЕНИКИНЕҢ ӘДӘБИ МИРАСЫН ӨЙРӘНҮ

**Г. Р. Гайнуллина**

Татар прозасының Бөек Ватан сугышы чоры (1941–1945) һәм милли нигезләргә кайту дәверен, хәзерге прозаны XX йөз башы татар прозасы белән бер үремтәдә өйрәтү Әмирхан Еникинең (1909–2000) әдәби мирасын аерым игътибарга алып тәкъдим итү аша барыла. Чөнки «татар әдәбиятындагы үзгәрешләрнең тамырлары сугыш чорына китә һәм аларны Ә. Еники прозасы башлап җибәрә» [1: 186].

XX йөз башы татар прозасында барлыкка килгән аерым жанрлар XX гасырның икенче яртысы, хәзерге проза үсешендәге үзенчәлекләрнең алшарты, нигезе булып тора. Шундый жанрларның берсе – татар прозасында XX йөз башында ук калыплашкан, үсеш кичергән нәсер жанры. «Ә. Еники татар әдәбиятын жанрлык хасиятләре ягыннан үзгәртү юлларын да эзли, шуның бер сукмагын синтетик характерлы нәсер жанрында таба» [1: 190]. Әдәбият галиме Д. Заһидуллина карашынча, нәсер – XX йөз башы татар модернистик прозасында иң төп жанрларның берсе: «Мәхәббәт темасына язылган әсәрләрдә лирик башлангыч, эмоциональ-интонацион тәэсирлелек көчле. Еш кына ритмы сөйләм, кабатлаулар, күпнокталар белән белдерелгән, әйтелеп бетмичә өзелгән фикер, хисләрнең бер чиктән икенчесенә ташлануы күзәтелә. Шуңа күрә әсәрләрнең күпчелеге нәсер жанрында» [2: 156].

Классик һәм архаик мифларга игътибар үскән XX гасыр татар сәнгатендә, әдәбиятында – «сүз орнаменты» актуальләшкән чорда орнаменталь стильгә йөз тоту аңлашыла. Ләкин «XX йөз башы татар әдәбиятында нәсер жанрының формалашуы орнаменталь стиль барлыкка килүне соңарта» [1: 186].

Әйтергә кирәк, Ә. Еники татар прозасына сугыш чорында XX йөз башыннан нәсер жанры традицияләрен генә түгел, фәлсәфи проза алымнарын да кайтара. «...Фәлсәфи әсәрләрдә тәкъдим ителгән дөнья сурәте чынбарлыкның яшәеш бөтенлегендәге бер кисәк буларак моделен төзи, автор фикерен зур гомумиләштерүләргә китерә» [2: 118].

«Кем җырлады?» (1956) хикәясе белән Ә. Еники татар прозасында яңа сукмак барлый: фәлсәфи проблематиканы әсәр үзәгенә куя [4]. Хикәя сугыштан соңгы татар прозасының үзгә юлга кереп китүен күрсәтә. Фәлсәфи жанрдагы кече күләмле әсәрдә төп кыйммәт итеп куелган мәхәббәт яшәү/үлем бинар оппозициясендә тәкъдир ителә. Әйтергә кирәк, XX йөз башы татар фәлсәфи прозасында «яшәү/үлем бинар оппозициясендә мәхәббәтне төп кыйммәт итеп күтәргән» [2: 120] әсәрләр шактый. Мисалга Ә. Тангатаров хикәяләрен китерү дә җитә.

Милли нигезләргә кайту дәвере прозасында Ә. Еникинең хикәя-повестьларында кешенең рухи дөньясын, тарихи яки иҗтимагый сәбәпләргә бәйләмичә, фәлсәфи кыйммәт дип бәяләү өстенлек итә. Автор хикәяләүчесе аша татар укучысы белән яшәү мәгънәсе турында сөйләшә. Әдипнең «Әйтелмәгән васыять» хикәясе (1965) шундыйлардан.

1960–1970 еллар татар прозасында милли яшәеш фәлсәфәсен тәкъдим итү берничә юнәлештә бара. Беренче – яшәп килүче идеология шартларында системаның нигезен билгеләгән якларны ачуны күздә тоткан тәнкыйди юнәлеш 1955–1957 елларда Ә. Еникинең «Саз чәчәге», 1962 елда Ә. Еникинең «Рәшә» повестьлары язылу белән калыплаша. Әдипләр иҗтимагый проблемаларны алга куеп, татар кешесенең милли йөзе турында уйланалар. Психологизм алымнары, символлар бирелеше ярдәмендә автор тавышы тагын да ачыграк яңгыраган бу әсәрләрдә укучы күңеленә курку хисе кешедәге иң матур тойгыларны җимерә алучы, аны түбән тойгыларга таба боручы көч, дигән хакыйкать урнаштырыла [1: 174].

Ә. Еники кешенең җәмгыятьтәге урыны, әйләнә-тирәдәгеләргә мөнәсәбәте, шулай ук тормыш хәрәкәтенең кагыйдәләре турында уйланырга ярата. Геройны алга әйдәүче яки рухи упкынга өстерәүче эчке процесслар нидән гыйбарәт, нәрсә аны шул сукмактан атларга мәҗбүр итә – язучы әнә шуларның эчке механизмын һәм сәбәпләрен аңларга тырыша. Шул уңайдан, 1955 елда «Саз чәчәге» дигән повестьны иҗат итә. Ә. Еники бу әсәрендә миили яшәеш тәртибен, җаен юкка чыгара баручы идеологияне тәнкыйтьли. 1962 елда Әмирхан Еники җәмгыятьне рухи төшенкелеккә китергән кайбер күренешләрне әдәби яктан яктырткан «Рәшә» повестен иҗат итә.

XX гасырның 70–80 нче елларында Ә. Еники милли яшәеш фәлсәфәсен үз асылыңны табу, буыннарга тапшыра алу турындагы эчтәлек аша да сөйләп бирә. «Гөләндәм туташ хатирәсе» (1975) романтик повестенда «тарихи материал психологик эчтәлекле мәхәббәт турында сөйләүдә эретелә» [1: 202]. Әсәр эчтәлегенә субъектив образ – Гөләндәм исемле туташ алып керә, повесть хикәяләүченең мәхәббәт тарихын сөйләвенә корылган. Автор романтик алымнар ярдәмендә үкенечле мәхәббәт тарихын сөйләп чыга.

Шул рәвешле, XX йөзнең икенче яртысы татар прозасындагы үзгәрешләрне XX йөз башы һәм XXI йөз прозасы белән бәйләп аңлату барышында Әмирхан Еникинең әдәби мирасы тирән өйрәнелә. Классик әдибебезнең мирасын әдәби барыш картинасын өйрәткәндә тәфсилләп анализлау нәтиҗәсендә әдәбият галиме Д. Заһидуллинаның «XX йөзнең икенче яртысы прозасы – Әмирхан Еники дәвере» ул дигән карашы дәлилләнә [4: 15].

## ӘДӘБИЯТ


1. Заһидуллина Д. Ф. 1960–1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 383 б.

2. Заһидуллина Д. Ф. Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. – Казан: Татар.кит. нәшр., 2003. – 255 б.

3. Заһидуллина Д. Ф. Дөнья сурәте үзгәрү: XX йөз башы татар әдәбиятында фәлсәфи әсәрләр: Монография. – Казан: Мәгариф, 2006. – 191 б.

4. Заһидуллина Д. Ф. XX гасырның икенче яртысы татар әдәбиятын өйрәнү мәсьәләсе / Әмирхан Еники һәм XX йөз татар әдәбияты. – Казан: РИЦ «Школа», 2009. – Б. 13–18.

## МОРАЛЬНО-НРАВСТВЕННОЕ И ЭСТЕТИЧЕСКОЕ ВОСПИТАНИЕ В ПРОЦЕССЕ ИЗУЧЕНИЯ ХУДОЖЕСТВЕНОЙ ЛИТЕРАТУРЫ
### (на примере романа Ф. Садриева «Утренний ветер»)

**А. Ф. Ганиева**

*Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова*
*Академии наук Республики Татарстан, Россия*
aygulgani@mail.ru

## MORAL AND AESTHETIC EDUCATION IN THE PROCESS OF STUDYING FICTION
### (on the example of F. Sadriev's novel «Morning wind»)

**A. F. Ganieva**

*Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov*
*of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, Russia*
aygulgani@mail.ru

Духовно-нравственное воспитание молодого поколения всегда являлось одной из важных задач литературы. В настоящее время, когда в обществе растут преступления, варварство и несправедливость, воспитание у подростков нравственных качеств и духовных ценностей стало еще актуальнее. Уроки литературы способствуют интеллектуальному и духовно-нравственному развитию личности. Задача учителя литературы – раскрыть традиционные ценности татарской духовной жизни, учить постигать ее, способствовать развитию духовной стойкости личности. Как фактический материал, роман Фоата Садриева «Таң җиле» («Утренний ветер») станет удачным вариантом для достижения поставленных целей. В статье роман анализируется и выделяется его художественное и общественное значение.
**Ключевые слова:** татарская литература, Фоат Садриев, проза, роман, герой.

Spiritual and moral education of the younger generation has always been one of the important tasks of literature. Nowadays, when crimes, barbarism and injustice are growing in society, the education of moral qualities and spiritual values in adolescents has become even more relevant. Literature lessons contribute to the intellectual and spiritual and moral development of the individual. The task of the literature teacher is to reveal the traditional values of the Tatar spiritual life, to teach to comprehend it, to promote the development of spiritual perseverance of the individual. As a factual material, Foat Sadriev's novel «Tan jile» («Morning Wind») will be a good option to achieve your goals. The article analyzes the novel and highlights its social significance.
**Key words:** Tatar literature, Foat Sadriev, prose, novel, hero.

## ӘДӘБИ ӘСӘР ӨЙРӘНҮ ПРОЦЕССЫНДА ӘХЛАКЫЙ ҺӘМ ЭСТЕТИК ТӘРБИЯ БИРҮ
### (Ф. Садриевның «Таң җиле» романы мисалында)

**А. Ф. Ганиева**

Яшь буынга рухи-әхлакый тәрбия бирү һәрвакытта да әһәмиятле бурычларның берсе булып тора. Җәмгыятьтә җинаять, вәхшилек һәм гаделсезлек артып барган хәзерге көндә исә үсмерләрне югары әхлаклы, рухи бай итеп тәрбияләү тагы да актуальләшә. Әдәбият дәресләре шәхесне интеллектуаль һәм рухи-әхлакый яктан үстерүгә ярдәм итә. Әдәбият укытучысының бурычы – татар рухи тормышының традицион кыйммәтләрен ачу, аны аңлар-

га, шәхеснең рухи ныклыгын үстерүгә ярдәм итү. Фактик материал буларак Фоат Садриевның «Таң җиле» романын алу куелган максатларга ирешү өчен уңышлы вариант булып тора.

Ф. Садриев иҗатында заман проблемаларын киң фәлсәфи планда яктыртуга омтылыш көчле. Фәлсәфилек халыкчанлыгы, һәркемне борчый торган мәсьәләләргә юнәлдерелүе, ил гаме белән үрелеп бирелүе ягыннан тормышчан һәм көнитешкә якын. Шуңа язучының әсәрләренә әдәбият белгечләре, тәнкыйтьчеләр генә түгел, киң катлам укучылар да битараф калмый: бәя-мөнәсәбәтләрен матбугат битләрендә чагылдыра киләләр. «Таң җиле» (1992) арада иң күп игътибарны җәлеп иткән роман булып чыга. 1993 ел дәвамында «Казан утлары» журналы әлеге әсәр белән бәйле «Безнең тормыш. Безнең әдәбият» дигән темага зур сөйләшү дә алып бара. Роман татар әдәби барышында югары бәя ала: «Чор әдәбиятының энҗе бөртеге булган әлеге роман сайланган теманың һәм күтәрелгән мәсьәләләрнең актуальлеге белән дә, әдәби эшләнеше һәм тәэсир көче буенча да, авторның образлар тудыру осталыгы ягыннан да аерым урын тота» [3: 11].

Әсәр үзәгендә гап-гади татар авылында гомер итүче Нуриасма исемле карчык тора. Язучы әлеге образга бәйле тормышны күп яктан колачларга омтыла. Анда кеше һәм җәмгыять, кеше һәм аның вөҗданы, авыл, табигать, милләт мәсьәләләре заман биеклегеннән бәяләнә.

Романның төенләнеше үлем вакыйгасына бәйле башланып китә. Авылның бер дигән ир-егете Рәмзи урманга утынга барган җирдә фаҗигале төстә һәлак була һәм язучы әлеге күренешкә бәйле әсәрне ялган һәм дөреслек, вөҗдан һәм намуссызлык каршылыкларына, яшәү мәгънәсе кебек мәңгелек фәлсәфи сорау-уйлануларга нигезли. Бөтен авыл Рәмзинең үлеменә турыдан-туры гаепле булучыларны ялган күрсәтмә биреп яклаганда, бары Нуриасма хакыйкатьне саклаучы бердәнбер кеше булып кала. Хикмәт исерек килеш руль артына утырган Гарифҗан, аңа күрсәтмә биргән колхоз рәисе Хөснуллинда гына түгел. Нуриасма авылдашлары арасыннан башланган шушы ялганның ил күләмендәге ялганга килеп тоташуын аңлый. Шулай итеп, Нуриасма дөреслеге власть һәм халык арасындагы ялганны ачып бирүче ачкычка әверелә.

Әсәрдә Нуриасманың тормыш юлын аның хәтерендә кабат яңартып, совет власте төзелгәннән алып 1990 еллар ахырына кадәрге ил тарихына бәя бирелә. Үзенең һәм үзе кебек миллионлаган халыкның власть тарафыннан алданып яшәвенен аңлау героиняны үкенечле хис-тойгыларга китерә. «Әле югарыдан ук килгән олы ялган – бөтен халыкны һәр минут, дистә еллар буе агулап килгән олы ялган бар бит» [4: 89]. Колхозга алдап кертү, коммунизм белән алдау, «чабата кашлар»ның тормышның яхшырасына халыкны өметләндереп яшәтүләр артта калсын да ди, дип фикер йөртә героиня, «Ә хәзер ни үзгәрде? Иң югары мөнбәрләрдән торып: «Азатлык алыгыз, һәр милләтне чәчәк аттырыйк», – дип һәр тумыш көн авызларыннан төкерек чәчтеләр, ә үзләре кораллы гаскәр, танклар белән шул сөйләгәннәренә каршы торалар. Ялганлаган саен кызарып та карамыйча тагын ни йөзең белән халык, ил каршына чыгарга мөмкин?! Моның өчен нинди вөҗдан, нинди намус кирәк?! Ник болай? Кайчанга кадәр? Халык ничек түзә? Нуриасмалар моны күпмедер аңлап та яшәделәр ләбаса! Әмма элекке ялганнарны аклап яңа ялганнар уйлап чыгарыла торды. Ә югарыдан төшкән һәр сүз изге иде, аңа ышанмыйча ярамый иде. Әз генә түзик, тиздән барысы да үзгәрәчәк, әйбәтләнәчәк дигәнгә кемнең җаны эремәсен соң?! Менә хәзер катлы-катлы пәрдәләрен астан да, өстән дә умыра башлагач, бу коточкыч хәлгә гаҗәпләнергә генә калды. Ә ялган үзе, аңа төртеп

күрсәтеп торуга карамастан, кимемәде, көчәйде генә. Ялганлаучылар тагын да хәйләкәррәк була бара» [4: 89–90]. Әгәр ялган бер гаилә, бер авыл кешеләре арасындагы мөнәсәбәтләрне боза икән, димәк, милләтләр арасын да бутый, илләрне тарката. Шулай итеп, героиняның ил һәм җәмгыять турындагы уйланулары автор карашлары белән кушыла.

Романда тормыш-яшәешнең төрле катламнары яктыртыла. Дөреслекне яшәү принцибы итеп алган Нуриасманы язучы ана-бала, ир-хатын, көндәше һәм авылдашлары белән мөнәсәбәттә ача. Язмышның нинди генә сынаулары килсә дә, ул һәркем өчен аклык-сафлык үрнәге булып кала. Нуриасма белән Сәгыйдулла, гаилә корган вакытта ук, намус пакьлеген изге канун итеп саклауны максат итеп куялар. Үзе аңлаган дөреслеккә омтылу һәм бернинди ташламаларсыз яшәве Нуриасманың үзенә генә түгел, аның гаиләсенә – балаларына да авырга килә. Язучы төрле тормыш вакыйгаларында героиняның гел туры юлдан баруын, кайчакта үз балаларына каты бәгырьле дә булуын сурәтли. Әлеге вакыйгалар фәлсәфи-психологик уйланулар белән үрелеп бара һәм укучыга яшәеш турында төрле яклап фикер йөртү мөмкинлеге бирә. Хакыйкатьнең үзе дә бертөрле генә булмыйча, кемнең хаклы, кемнең хаксыз икәнен аера алмаслык тормыш сынаулары чыгып тора. Авторның уңышы да шунда: Нуриасма сынауларны схематик образ сыман ансат кына узмый, ә икеләнү һәм күңел газаплары аша үтеп җиңүгә ирешә.

Нуриасманың дөньяга иҗтимагый-фәлсәфи карашы һәм яшәү рәвеше белән үз чорының типик вәкиле – советчыл аң сеңдерелгән татар карчыгын хәтерләтүен билгеләргә кирәк. Бу бигрәк тә аның каенсеңелесенең алыпсатарлыгына мөнәсәбәтендә ачык чагыла. Шулай ук Нуриасманың дингә карашы үзенчәлекле. Героиняда тупланган рухи-әхлакый кыйммәтләр дин белән уртаклыгы булмаган, кешенең үз мораль йөзенә бәйле гомумкешелек сыйфатлары итеп күрсәтелә.

Ф. Садриев яратып кулланган алымнарның берсе – чагыштыру. Күп очракта бу төп геройның антиподы аша башкарыла. Әсәр героена дөньяга карашы, холкы, яшәү рәвеше, зәвыгы белән капма-каршы сурәтләнгән сәнгати образ фонында автор күрсәтергә теләгән сыйфатлар тагы да ачыграк чагыла. «Таң җиле»ндә Нуриасманың антиподы итеп Мәскәү кодагые бирелә. Мөселман карчыклары янында алардан да уздырып намаз укыган Гыйльменур рус дуслары янында чукына, дуңгыз ите ашап, аракы эчеп утыра. Үзенең күңел дөньясы саф, кешеләргә карата да ихлас Нуриасма кодагыеның бу гамәлләренә өнсез кала. Иман мәсьәләсендәге икейөзлек әсәрдә гафу ителмәслек түбәнлек буларак бәяләнә: Нуриасма Гыйльменурны үләр алдыннан да кичерми.

Ф. Садриев бала тәрбияләүдә милли-табигый мохитнең әһәмиятен югары бәяли. Нуриасманың олы улы Фәрит белән килене Нәсимә Себердә яшәгәндә туганнан бирле сәламәтлеккә туймаган Маратны ничек кенә дәвалап карасалар да файдасы булмый. Аптырагач, табип киңәше белән баланы әниләренә кайтарып торырга булалар. Маратның әбисе белән таңнан торып кичкә кадәр хуҗалык эшләрендә кайнашуын, мал-туар, тавык-чебеш арасында йөрүен, яшьтәшләре белән агач башларына менеп уйнавын, су керергә йөрүләрен сурәтләп, язучы чын табигый яшәү бары авылда гына дигән фикеренә тугры кала: малай савыгу гына түгел, теле ачылып, өлкәннәргә тапкыр-тапкыр җаваплар да бирә башлый. Марат белән чагыштыру өчен әсәрдә шул ук Гыйльменурның оныгы Руслан китерелә. Чама белән Марат яшьләрендәге әлеге малайны әти-әниләре «дөрес» тәрбияләү максатыннан көндәлек катгый режимга көйләгәннәр, рәхәтләнеп уйнау, күңел ачу хокукларыннан, үзләренең иркә-назларыннан

мәхрүм иткәннәр. Мондый тәрбиянең нәтиҗәсе итеп язучы Русланның абыйсын китерә. Әбисе сүзләренә караганда, ул үскәндә акыллы гына бала булган, үсмер яшькә җиткәч, начар юлга кереп, өйгә кайтмый йөри башлаган. Шулай итеп, романда шәхес тәрбияләү мәсьәләсендә авыл һәм шәһәр мохитын бер-берсенә каршы кую һәм авылны өстенлекле итеп күрсәтү бар.

Гомумән, Ф. Садриев иҗатында авыл прозасы традицияләре дәвам иттерелә. «Таң җиле»ндә, сайланган тормыш ситуациясенә бәйләп, мәет күмү йолалары җентекләп сөйләп бирелә, кыз каршылау, туйга әзерлек күренешләре бәян ителә. Язучы табигатьне, кешеләрнең үзара мөгамәләләрен яратып сурәтли. Читтән кайткан һәр кешесен үз баласыдай якын күреп, ачык йөз белән каршылау (Гыйзденисаттинең Фәритләр белән исәнләшүе), кайтучыларның исә олысын-кечесен күчтәнәчләр белән сөендерүе (Үзбәкстаннан Сәлмән абзый алып кайткан калач тәме турындагы хатирә), күптән киткәннәрне хәтта балаларның да танып, хәтерләп торуы (Фәрит һәм кечкенә кызчык әңгәмәсе) авыл җирлегендә генә очрый торган матур гадәтләр буларак күрсәтелә. Бер-берсенә кереп хәл белешеп, шатлыгын да, михнәтен дә бергә күтәреп яшәгән авыл хатыннары Маһинур, Разия, Гыйздениса, Мосаллиялар турында язучы соклану катыш әрнү белән яза. Бөтен сәламәтлекләрен, гомерләрен колхоз эшенә багышлап та, тормыш авырлыгына зарланмыйча, булганына канәгать булып, кешеләргә яхшылык эшләүдән тәм табып яшәгән буын киткәч, алмашка кем калыр? Нуриасма уйлары аша романга татар авылы мохитенең үз йөзен югалта баруына борчылу-сызлану килеп керә.

Язучы тормыш, яшәү һәм үлем турындагы фәлсәфәне бер ноктага җыя: ике туйга әзерлек берьюлы бара. Ике хатын-кыз – ике юл башында: Нуриасма үлгәннән соңгы истәлекләре итеп кемгә камзул, кемгә яулык, кемгә намазлык бирәсен әйтеп калдыра, Зөбәрҗәт килен бүләге өләшә. Гаять тетрәндергеч мизгелләр булса да, бу гайре табигый хәл кебек кабул ителми. Моның сәбәбе – Нуриасманың үлемне тыныч күңел белән каршы алуында. Хәл белергә кергән Гыйзденисатти тынычландыргыч салмак тавышы белән Аллаһ биргән гомер, һәркемнең шуны үтүе, кыскамы ул, озынмы – тәмен, кадерен белеп яшәү кирәге турында сөйли. «Үлем турында сөйләсә дә, Гыйзденисаны тыңлавы рәхәт иде. Аның сөйләвендә чишмәнең мәңгелек челтерәве төсле тынычландыргыч моң, бернинди бизәкләргә төрелмәгән гадилек, сафлык, ачыклык бар иде... Тормыш белән үлем, төш белән өн аның өчен үзара тыгыз бәйләнештә торучы, күп очракта хәтта аерылгысыз әйберләр, яшәешнең ниндидер бер серле мизгелендә без белмәгән гайре көчләр тәэсирендә бер-берсенә әвереләләр иде» [4: 145]. Шулай итеп, әсәрдә үлем – юкка чыгу, бетү булып түгел, ә тормышның башкаларда дәвам итүе кебек бирелә.

Роман символик детальләргә гаять бай. Язучы күбрәк кояш, таң, җил, нур, аклык символларына игътибар бирә. Нурлы, якты, балкучы, югары, бөек мәгънәләрен белдергән Нуриасма исеме дә очраклы сайланмаган. Ф. Садриевның мәртәбәле, хөрмәтле, алдагы буыннарга да үрнәк булып торырлык гомер юлы үтүче героинясын, Ф. Бәширов әйткәнчә, символ дәрәҗәсенә җиткерә. «Романның икенче өлешендә Нуриасма конкрет персонаж булудан битәр, гореф-гадәтләрне буыннардан-буыннарга тапшырыла килә торган яшәү кануннарын, халыкның акылын, тәҗрибәсен үзендә туплаган символ-образ булып күзаллана. Ул образда татар халкының гамәл-хыяллары да, язучының милләт язмышы турындагы уйланулары да гәүдәләнеш алган» [1: 21].

Образ-символлар турында сөйләгәндә, укучы игътибарын берничә кат җәлеп иттергән кызыклы деталь турында да әйтеп китәргә кирәк. Ул – Марат киеп йөргән тузып беткән иске чалбар. Нәсимә аны берничә тапкыр ташларга

җыенса да, я Нуриасма, я Фәрит тотып кала. Әлеге чалбарның хикмәте соңыннан гына ачыклана: аны кечкенә чакта Фәрит үзе киеп йөргән икән. Ә аңа әнисе сугыштан киеп кайткан әтисенең гимнастеркасыннан теккән булган. Әсәрдә Сәгыйдулла – Фәрит – Марат чылбыры ир-ат символы буларак килгән чалбар аша күрсәтелә. Нуриасма шушы буыннар бәйләнешен тәэмин итүче, саклаучы хатын-кыз – ана архетибы буларак та алга баса.

Кеше күңелендә матурлыкны күрә һәм тоя белү сәләте тудыру, үстерү – Ф. Садриев иҗатының максаты. Гүзәллек орлыклары бала күңеленә кече яшьтән үк салынырга тиеш дип саный язучы. Ә матурлыкның чыганагын ул табигатьтә, аерым алганда, аның басу-кырларында, болыннарында күрә. «Таң җиле» романында баланы алып, гаилә белән кырга чыгу, арыш серкәсен очыру тавышларын тыңлау күренешләре сурәтләнә. Язучының эстетик дөнья пространствосында кыр, басу сакраль мәгънәгә ия матурлык идеалы булып тора. Хикмәт – аның кырны Кеше – Табигать – Хезмәт төшенчәләрен берләштерүче символ буларак кабул итүендә. Кыр кошы – сабан тургаеның да әсәрләрендә еш очравы шуның белән аңлатыла.

Ф. Садриев әсәрләренең теле, сүз белән сурәт ясау осталыгы турында аерым билгеләп үтү мөһим. «Тел-стильнең үтә дә нәфислеге, нәзакәтлеге, нечкәлеге; хис-кичереш дөньясының мәгърур музыкаль симфонияләрдәге шикелле бөек бер гармония һәм драматизм белән агышы; вакыты-вакыты белән югары романтиканың, ә кайчак иң-иң трагик аһәңнәр өскә калкып кеше рухиятенең гаять киң диапазонда һәм тирәнлектә-биеклектә чагылуы – болар барысы да бергә проза әсәрләренен шигърият белән якынайта, алар арасындагы чикне җуйдыр. <...> Ф. Садриев прозасының кайбер урыннары (бергәк тә геройларның эчке кичерешләрен биргәндә, яисә табигать күренешләрен тасвирлаганда, яки автор үзе хисләнеп лирик кичерешләргә кереп китсә) нәкъ менә шундый – зур күләмле әсәрдән аерып шигъри әсәр кебек кулланырлык дәрәҗәдә сәнгатьледер» [2: 92] дип яза Мансур Вәлиев.

Шулай итеп, «Таң җиле» романы күпкатламлы булуы, ягъни кешенең рухи дөньясын төрле яссылыкта (заман, хакыйкать, табигать, мәхәббәт, үлем һ.б.) карап, фәлсәфи гомумиләштерүләр ясый. Лирик аһәң, символик сурәтләр әсәрнең эмоциональ көчен куәтли. Сәнгати камиллек һәм мәгънәви бөтенлек романны татар әдәбиятының иң югары әсәрләре рәтенә куя.

## ӘДӘБИЯТ


1. Бәширов Ф. Исә җилләр... // Фәрит Бәширов. Сөйлә, каләм! Әдәби уйланулар, тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 21 б.
2. Вәли-Барҗылы М. Намуслы кешеләр // Мәйдан. – 2011. – № 3. – 92 б.
3. Заһидуллина Д. Таң җилләре кебек // Яңа дулкында (1980–2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык). – Казан: Мәгариф, 2006.– 11 б.
4. Садриев Ф. Таң җиле: Роман.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1993.– 89 б.


# ИЗУЧЕНИЕ ТВОРЧЕСТВА ГАБДУЛЛЫ ТУКАЯ НА УРОКАХ РОДНОЙ (ТАТАРСКОЙ) ЛИТЕРАТУРЫ: МЕТОДИЧЕСКИЕ ТРАДИЦИИ И СОВРЕМЕННЫЕ КРИТЕРИИ


**К. Б. Гарипова, Г. Б. Мухаметзянова**

*МБОУ «Суксинская ООШ» Высокогорского муниципального района Республики Татарстан, Россия; МБОУ «Кшкловская начальная общеобразовательная школа – детский сад» Атнинского муниципального района Республики Татарстан, Россия*

klaragaripova@yandex.ru, kshlau@mail.ru

# THE STUDY OF GABDULLA TUKAI'S CREATIVITY AT THE LESSONS OF NATIVE (TATAR) LITERATURE: METHODOLOGICAL TRADITIONS AND MODERN CRITERIA

**K. B. Garipova, G. B. Muhametzyanova**

*Suyksu Comprehensive School of the Vysokogorsky municipal district of the Republic of Tatarstan, Russia; Kshklovo primary general educational school – kindergarten of the Atninrsky municipal district of the Republic of Tatarstan, Russia*

klaragaripova@yandex.ru, kshlau@mail.ru

В статье рассматриваются особенности изучения творчества классика татарской литературы Габдуллы Тукая уроках родной (татарской) литературы. На материале произведений поэта, включенных в образовательные программы, выделяются основные критерии анализа лирических произведений. Авторами статьи определяются идейно-проблематические и поэтические особенности произведений Тукая, на которые следует уделять внимание при изучении творчества поэта.

**Ключевые слова:** татарская литература, методика преподавания родной литературы, Габдулла Тукай, идея-проблематика, поэтика.

The article discusses the peculiarities of studying the creativity of the classic of Tatar literature Gabdulla Tukai in the lessons of native (Tatar) literature. Based on the material of the poet's works included in educational programs, the main criteria for the analysis of lyrical works are highlighted. The authors of the article determine the ideological, problematic and poetic features of Tukai's works, which should be paid attention to when studying the poet's work.

**Key words:** Tatar literature, methods of teaching native literature, Gabdulla Tukay, idea-problematics, poetics.

# МӘКТӘПТӘ ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИҖАТЫН ӨЙРӘНҮДӘ МЕТОДИК ТРАДИЦИЯЛӘР ҺӘМ ЗАМАНЧАЛЫК

**К. Б. Гарипова, Г. Б. Мөхәмәтҗанова**

Мәктәптә туган телдә (татар) әдәбият укыту программаларында, дәреслек-хрестоматияләрендә Г. Тукайның тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнүгә сәгатьләр күп карала. Аның әдәби мирасына зур урын бирелү, һичшиксез, дөрес.

Соңгы елларда әдәбият укытуда, бигрәк тә XX башы әдәбиятын өйрәтүдә, укытучыларга галимнәребез тарафыннан зур ярдәм күрсәтелә. Тукай иҗатын өйрәнүгә яңача караш туу әдәбият укытучысы алдына зур бурычлар куя. Әлеге иҗатны мөмкин кадәр тулырак, күпкырлырак төстә укучыга җиткерү юлларын эзләү бара. Шагыйрьнең иҗтимагый карашлары белән янәшә фәлсәфи, милли, дини күзаллау да укучыга җиткерелергә тиеш, шулай ук Тукай шигырьләрен анализлаганда, «чорга хас иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-мәдәни мохитне күзаллау белән бергә үреп бару зарур» [4: 154].

Тукай фәнен мәктәптә укыту мәсьәләсе тирәсендә XX гасыр башында ук эзләнүләр башлана. Гаяз Исхакый әдәбият дәресләрендә Г. Тукай иҗатын өйрәнүнең максатын һәм әһәмиятен болай аңлый: беренчедән, бала күңелендә Тукайга ихтирам тәрбияләү; икенчедән, шагыйрь мирасы белән мөмкин кадәр тулысынча танышу; өченчедән, әсәрдән рухи азык алу; дүртенчедән, тәрҗемәи хәле, шигырьләре үрнәгендә балаларны тормышка әзерләү.

Ул Тукайны сабый баланың дусты, яшүсмернең фикердәше, тормышка аяк баскан егетнең таянычы, кирәк чакларда көрәштәше буларак карый. «Мәктәптә бала Тукай берлән үсәргә тиеш. Тукай берлән егет булып мәйданга

чыгарга тиеш. Тукай берлән «Җырлый-җырлый үләрмен үлгәндә дә, дәшми калмам Газраилне күргәндә» дип, батырларча тормышның тартышуына атларга кирәк». Укучыны, тормыш авырлыгына карамыйча, татар халкының якты киләчәге өчен каһарманнарча көрәшкә әзерләү Тукай дәресләренең төп бурычы төсендә билгеләнә. Автор фикерен: «Тукай яңа буынның үзен-үзе аңлавында, үзеннән-үзе дөньяга караш карауны ясавын – үзенең тирә-юнен тануында беренче роль тотачак шагыйребез, әдибебез, мөхәрририбез», – дип төгәлли. Ә инде мәктәп-мәдрәсәләрнең вазифасы, мөгаллим-мөгаллимәләрнең бурычы – ул биргән җимешләрдән файдалана алу, ул биргән җимешләрне мөмкин кадәр күбрәк тарату. Ана теленә, әдәбиятка яшәү өмете биргән шагыйрь иҗатының үлемсезлеге яше-карты күңелендә халык шагыйре буларак буыннан-буынга күчәргә тиеш дигән фикер Г. Исхакыйның «Милли җитешсезлегебез» (1916) дигән публицистик мәкаләсендә янә бер кат раслана [1: 23].

Мәктәптә татар әдәбиятын укыту үзгәреш кичергән чорда хезмәтнең әһәмияте тагын бер кат арта, чөнки ул күтәргән мәсьәләләр бүгенге көнебездә дә актуаль яңгырыйлар, шагыйрь иҗатын мәктәптә өйрәнү өлкәсендә әйтелгән фикерләре, киңәшләре хәзер дә әһәмиятен югалтмаган. Шулай да Тукай иҗатын өйрәнүдә бүгенге көн галимнәребезнең үз фикерләре бар. Мәктәптә бөек шагыйребез иҗатын өйрәнгәндә, бу хезмәтләрне дә файдалану укыту-тәрбия эшен тагын да нәтиҗәле итә. Укучыларны фикерләргә өйрәтү, мөстәкыйль белем тупларга күнектерү – бүгенге көн укытучысы алдына куелган төп бурычларның берсе, «Ул укучыны һәрдаим уйланырга, эшләргә һәм фикерләшергә этәрергә тиеш» [3: 151]. Тукай шигъриятенең офыклары киң, әгәр укучы өстәмә рәвештә шөгыльләнмәсә, бай мирасның бик аз өлеше генә аның күңеленә кереп калачак. Югары сыйныф укучылары белән семинар дәресләр оештыру, шагыйрь иҗатының төрле юнәлешләрен колачлаган темаларга чыгышлар әзерләү укучыларның белем дәрәҗәсен арттыра. Түбән сыйныфларда Тукайның балалар өчен язылган шигырьләрен өйрәнү күздә тотылса, хәзер шагыйрьнең милләт, кеше, дин хакындагы фәлсәфи уйланулары чагылган шигырьләре белән таныштыру үзәккә куела.

Г. Тукай иҗат мирасында фәлсәфи шигырьләр шактый күп һәм төрле. Шагыйрьне кеше, гомумән кешегә хас сыйфатлар, аларның нинди нәтиҗәләргә китерүе, тормыш кануннары кызыксындыра. Фәлсәфи шигырьләренең күбесе үткән/бүгенге оппозициясенә корылганнар. Алар барысы да диярлек тормышны ике: лирик герой үзен бәхетле дип санаган һәм бәхетле булу мөмкин түгеллеген аңлаган баскычларга бүлә. Шуның ярдәмендә экзистенциализм (латинчадан; «яшәү» дигән мәгънәне аңлата, философиядә һәм әдәбиятта кешенең яшәештәге урынын билгели, тормышны курку һәм борчылу халәте буларак билгели торган агым) фәлсәфәсе белдерелә.

Г. Тукайның «Бәйрәм һәм сабыйлык вакыты» шигырендә лирик герой Алладан бәйрәм көнне генә бала чагына кайтаруын үтенә. Кеше бала чагында гына чын бәхетле була ала дигән фикер яшәешнең бер кануны төсле тәкъдим ителә: «Хозур ла соң инсан өчен бу хәл, бу яшь!» [5: 67].

Тукайның иҗат мирасында дин фәлсәфәсен чагылдырган шигырьләр байтак. Аларның кайберләре Коръәннән мәгълүм фикерләрне кабатлап килә. Мәсәлән, «Тәәссер» (1908) шигырендә сүз Аллага ышануның кеше күңеленә тынычлык, сафлык китерүе, авыр вакытларны җиңеләйтүе хакында бара. «Ана догасы» (1909) шигырендә улына Алладан бәхет сораучы ана образы тудырыла. Бары тик ана кеше генә баласы өчен шулай ялварып сорый ала. Бала кеше моны аңына сеңдерергә тиеш.

Тукайның һәр иҗат җимеше укучыларны тормышка әзерләүдә зур чыганак булып тора. Аның шигырьләрен тирәнтен аңлау һәм анализлау өчен, балалар кече яшьтән үк лирик әсәрләрне анализлау ысулын үзләштерергә тиеш, ә моңа әдәбият укытучысының тырыш, белемле, эзләнүчән, яңалыклар белән даими танышып баруы нәтиҗәсендә генә ирешеп була. Д. Ф. Заһидуллина мөһәррирлегендә дөнья күргән «Әдәби әсәргә анализ ясау» методик кулланмасында әдәби әсәрдәге бөтенлекне тәэмин итә торган төп төшенчәләрне: образлар системасын, сюжетны, композицияне, психологизмны, тема һәм идеяләр дөньясын, хронотопны, стильне тикшерү Габдулла Тукайның «Өзелгән өмет» шигыре үрнәгендә бирелә [2].

Соңгы елларда Габдулла Тукайның мәхәббәт лирикасын өйрәнүнең әһәмияте арта бара. Бүгенге көндә мәхәббәтнең олы хис булу дәрәҗәсе кимегән чакта, Тукайның шәхси үрнәге һәм мәхәббәт лирикасы бу хиснең саф, чиста булуын расларга ярдәм итә. Югары сыйныф укучыларына, сыйныфтан тыш уку өчен, Р. Харисның «Тукайның мәхәббәт төшләре» поэмасын тәкъдим итү урынлы булыр. Сыйныфтан тыш чара итеп сәхнәләштергән очракта тәэсир көче тагын да арта. Без моңа инандык. Балалар, шулкадәр бирелеп, шагыйрь образын тудыралар, алай гына да түгел, әзерлек барышында өстәмә мәгълүматлар белән танышып, күпме яңа белем туплыйлар. Һәр елны мәктәптә Г. Тукайның туган көнен билгеләп үтү, Туган тел айлыгы кысаларында шигырь конкурслары үткәрү Бөек шагыйребезнең иҗатын тирәнрәк өйрәнергә ярдәм итә. Укучыларны сәнгатьле сөйләү конкурсларына әзерләгәндә, моңарчы сәхнәдән яңгырамаган шигырьләрен сайларга тырышабыз. Югары сыйныф укучылары белән Г. Тукай иҗатында кеше һәм тормышка кагылышлы фәлсәфи күзаллау булдырган шигырьләрне өйрәнәбез. Шагыйрь, кеше тормышын ике чорга аерып, балачакны – бәхетле, өметләр белән яши торган вакыт кебек бәяли. Яши-яши кешенең өметләре өзелә һәм ул тормышның чиклелеген, үлем белән төгәлләнәчәген аңлауга килә. Кеше өчен чикләнгән, караңгы, авыр тормышта кеше булып яшәүнең бердәнбер юлы – көрәш. Көрәш дигәндә, күңел-җанның югарыга омтылышын саклау, милләтне алга җибәрү өчен тырышу, мәхәббәтне эзләү, иҗат эше ярдәмендә башкаларга фикерне җиткерергә омтылу күздә тотыла. Болар кешене караңгылык, битарафлык упкынына төшүдән саклый торган кыйммәтләр, яшәү максаты. Мәктәптә Г. Тукай биографиясен һәм иҗатын яңача өйрәнү бурычы куела. Әдәбият укытучысы, һичшиксез, бу бурычны тормышка ашырырга тиеш.

## ӘДӘБИЯТ


1. Гыйләҗев Т. Әдәби мирас: тарих һәм заман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 206 б.

2. Заһидуллина Д. Ф., Ибраһимов М. И., Әминева В. Р. Әдәби әсәргә анализ ясау: Урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары өчен кулланма. – Казан: Мәгариф, 2005. – 111 б.

3. Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. Әдәбият дәресләрендә коммуникатив компетенция формалаштыру // Правовые основы функционирования государственных и региональных языков в условиях дву- и многоязычия (мировой опыт реализации языковой политики в федеративных государствах): Материалы международной научно-практической конференции. – Казань: ИЯЛИ, 2019. – С. 150–153.

4. Надыршина Л. Р., Ханнанова Г. М. Г. Тукай шигъриятен мәктәптә өйрәтү: милли мотивларны анализлау // Правовые основы функционирования государственных и региональных языков в условиях дву- и многоязычия (мировой опыт реализации языковой политики в федеративных государствах): Материалы международной научно-практической конференции. – Казань: ИЯЛИ, 2019. – С. 153–155.

5. Тукай Г. Сайланма әсәрләр: шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – 262 б.

# ФОРМИРОВАНИЕ НАЦИОНАЛЬНОГО САМОСОЗНАНИЯ УЧАЩИХСЯ НА УРОКАХ РОДНОЙ (ТАТАРСКОЙ) ЛИТЕРАТУРЫ
## (на примере творчества Д. Гарифуллина)

**Ф. И. Габидуллина**
*Елабужский институт (филиал) ФГАОУ ВПО «Казанский (Приволжский) федеральный университет», г. Елабуга, Россия*
farida-vip@mail.ru

# FORMATION OF NATIONAL SELF-CONSCIOUSNESS OF STUDENTS IN THE LESSONS OF NATIVE (TATAR) LITERATURE
## (on the example of D. Garifullin's creativity)

**F. I. Gabidullina**
*Yelabuzhsky Institute of Kazan (Privolzhsky) Federal University, Yelabuga, Russia*
farida-vip@mail.ru

Статья посвящена проблеме формирования национального самосознания учащихся на уроках родной (татарской) литературы. Она тесно связана с формированием личности ученика. В процессе анализа литературного произведения, с помощью методических приемов осуществляется воздействие на мысли и чувства учеников. Через самостоятельную деятельность учащихся, содержательное обсуждение, сопоставление вопросов истории и современности делаются выводы о ценностях Родины и родной земли, о понятиях нации и свободы личности.
**Ключевые слова:** личность ученика, национальное самосознание, родная литература, анализ, прием, ценности.

The article is devoted to the problem of formation of national self-consciousness of students in the lessons of native (Tatar) literature. It is closely related to the formation of the student's personality. In the process of analyzing a literary work, with the help of methodological techniques, the thoughts and feelings of students are influenced. Through the independent activity of students, meaningful discussion, comparison of issues of history and modernity, conclusions are drawn about the values of the Motherland and native land, about the concepts of nation and individual freedom.
**Key words:** student's personality, national identity, native literature, analysis, reception, values.

# ӘДӘБИЯТ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ УКУЧЫЛАРДА МИЛЛИ ҮЗАҢ ФОРМАЛАШТЫРУ
## (Д. Гарифуллинның әдәби иҗаты мисалында)

**Ф. И. Габидуллина**

Укытуның яңа стандартлары уку-укыту процессының эчтәлеген һәм формасын үзгәртү аша укучының шәхесенә йогынты ясауны, аның бүгенге катлаулы дөньяда үз-үзен табып яши алуын күздә тота. Укучы шәхесе күп төрле компонентларга бәйле, ягъни ул күп тапкыр кабатлаулы эш-гамәлләр аша формалаша [3: 78]. Укучыларның дөньяга ачык карашын булдыруда туган тел һәм әдәбият мөһим урын алып тора. Дәресләрдә өйрәнелә торган әдәби әсәрләрдә халыкның күпгасырлык акылы, тәҗрибәсе, тормышны аңлавы, кабул итүе чагылыш таба. Шуларны өйрәнү барышында укучылар төрле гыйбрәтле тари-

хи сәхифәләр, аерым кешеләр тормышына бәйле хәл-күренешләр белән танышa, аларны бәяли, билгеле бер нәтиҗәләр ясый. Әлеге мәкаләдә Д. Гарифуллин әсәрен өйрәнү барышында укучыларга йогынты ясау, милли үзаңнарын үстерү, баету юллары, алымнары күрсәтелә.

Татар әдәбияты бай булып, анда классик әдипләр белән бергә, әдәби иҗат белән шөгыльләнүче икенче-өченче рәт авторлар әсәрләре дә урын ала. Болай дип атау һич тә аларның иҗатын түбәнсетү түгел, чөнки нәкъ менә шундый авторлар әдәбиятны яңадан-яңа тема-мотивлар, эзләнүләр белән баета. Сарман районында яшәп иҗат итүче Д. Гарифуллин – шундый әдипләрнең берсе. Аның иҗаты шактый бай булып, проза һәм лирик әсәрләрдән тора. Соңгы вакытта төбәк язучыларын өйрәнүгә игътибар артты. Аерым авторларны я өстәмә дәресләрдә, я сыйныфтан тыш уку дәресләрендә өйрәнүнең уңышлы тәҗрибәләре бар. Без түбәндә Д. Гарифуллинның «Норильлаг тоткыны» әсәрен өйрәнүнең бер юлын тәкъдим итәбез.

Дәрес җитди әзерлек алып баруны, укучыларның әсәрне укып килүләрен, фикер алышырга әзер булуларын таләп итә. Дәреснең шәхескә юнәлтелгән нәтиҗәсе милли үзаң формалаштыру белән бәйле. Дәреснең актуальләштерү этабында укытучы Д. Гарифуллин турында мәгълүмат биреп китә. Моны өйдә әзерләнеп килеп, бер-ике укучы да эшли ала.

Уку мәсьәләсен куюавтор иҗаты белән кызыксындыруны, укучыларны укылган әсәргә бәйле җитди уйлану-эзләнү процессына алып керүне күздә тота. Мөһим урынны шәхси фикер белән уртаклашу алып тора. Милли үзаң нәкъ менә теге яисә бу мәсьәләгә бәйле үз фикереңне булдыруны алга куя.

Уку мәсьәләсен чишү дәреснең төп өлешен били. Укытучы алдында җитди сорау-биремнәр ярдәмендә укучыларны әңгәмәгә, эзләнүгә тарту бурычы тора. Өйрәнелә торган әсәргә бәйле түбәндәге сорау-биремнәрне куярга була: 1. Әсәрдә нинди вакыйгалар сурәтләнә? Алар турында моңа кадәр укыганыгыз бар идеме? 2. Әлеге вакыйгаларның тарихи нигезе нидән гыйбарәт? 3. Әсәрнең төп герое кем? Аның турында текстта нинди мәгълүмат бирелә? 4. Тексттагы хикәяләүче һәм аның янындагыларга нинди бәя бирелә? 5. Әсәр синдә нинди хис-тойгылар, уй-фикерләр уятты?

1. Әсәрдә нинди вакыйгалар сурәтләнә? Алар турында моңа кадәр укыганыгыз бар идеме? Әлеге сорауга бәйле төп вакыйгалар искә төшерелә. Язучының «Норильлаг тоткыны» хикәясендә Сталин хакимияте оештырган репрессия тоткыннарының ачы язмышы сурәтләнә. Вакыйгалар сугыштан соңгы елларда бара. Нәрсә соң ул Норильлаг? Әлеге лагерь – шәхес культы елларындагы кешелексез тарихыбыз сәхифәләрен үз эченә сыйдырган урыннарның берсе. И. Сәлаховның «Колыма хикәяләре», А. Гыйләҗевнең «Йәгез, бер дога!» әсәрләреннән безгә хезмәт һәм төзекләндерү лагерьлары тормышындагы аянычлы кайбер яклар ачылган иде инде.

Бу урында укучыларга компьютердан файдаланып, Норильлаг турында мәгълүмат тупларга кушыла. Табылган мәгълүмат берләштерелә. Әлеге лагерьдагы тормыш кырыслыгы белән аерылып тора. Моңа кадәр сәнагать объектларын поляр түгәрәк артында төзү тәҗрибәсе дөньяда гомумән булмый. Норильлаг тоткыннары үтә начар, кешелексез шартларда әлеге эшне башкаралар: аларны Норильск комбинаты төзү өчен кул кораллары һәм палаткалар белән генә тәэмин итеп мәңгелек бозлык шартларында эшкә куалар. Бөек Ватан сугышы елларында, Википедия чыганакларына караганда, биредә 7223 кеше вафат булган. Үлемнең төп сәбәбе – тоткыннарның ашату эше бик начар куелышында [6]. Интернет-ресурсta мондый мәгълүмат та

бар: «тиешле 800 грамм ипи урынына лагерь тоткыннары 700 грамм ипи алалар. Чүпрәне санамаганда, бернинди витаминнар да бирелми, әле хәтта анысы өчен дә тиешле ипинең 50 граммын һәм 30 сум акчаны тотып калалар. Киемнәр җитми, ә бирелгәннәре берничә срок файдаланыла. Нәтиҗәдә йөрәккан авырулы тоткыннар саны арта, дистрофия, үпкә авырулары таралыш ала. Моннан кала теләсә кайсы тоткын кыйнаулардан, котыртылган этләрнең тешләүләреннән, «коралны дөрес кулланмау» нәтиҗәсендә вафат була ала – барлык бу алымнар конвой офицерлары һәм солдатлары тарафыннан кечкенә генә килешмәүчәнлек күрсәтелгәндә дә кулланылалар» [6].

2. Әлеге вакыйгаларның тарихи нигезе нидән гыйбарәт? Бу сорау үткәннәрне искә төшерүне таләп итә. Димәк, бергәләп чор үзенчәлекләре ачыклана. Әлеге әфәтнең тарихи нигез бар, билгеле. Автор бары шуларга таяна. Гомумән, тарихилык – Д. Гарифуллин иҗаты һәм эшчәнлегенең үзенчәлекле ягы ул. «Тарихилык ул – язучының үз әсәрендә документаль, хроник, мемуар чыганакларга, тарихи легенда һәм мифларга нигезләнеп кайсы да булса дәверне, ерак яки якын үткәнне тудыруы, әсәр тукымасына тарихи персонажларны, чынбарлыкта яшәгән шәхесләрне кертүе, кайбер очракларда сюжет нигезе итеп тарихи вакыйгаларны һәм фактларны файдалануы» [4: 61]. Бу уңайдан танылган рус язучысы С. Залыгинның әдәбият белән тарих бәйләнеше турындагы фикерләре кызыклы: «Әдәбият һәм художник – кеше турында, ә тарих кешелек турында яза. Һәм без һәр икесенең бәйләнешләрын эзлибез» [4: 63]. Шул рәвешле, вакыт мөмкинлек бирсә, фикер алышуны дәвам итәргә була.

3. Әсәрнең төп герое кем? Аның турында текстта нинди мәгълүмат бирелә? Әсәрнең төп герое – танылган язучы Сөббух Рафыйков. Укучыларны мөстәкыйль эшчәнлеккә тарту максатында С. Рафыйков турында берничә укучыдан материал әзерләп килүне оештыру да уңышлы. Укучылар чыгышы тыңлана һәм фактлар гомумиләштереп дәфтәрләргә языла. Иң элек Сөббух Рафыйковның ни рәвешле «Норильлаг тоткыны»на әверелү тарихын карыйк. Әлбәттә, монда шәхеснең гаебеннән бигрәк тарихи фактлар зуррак роль уйный. Дошманнар, көнләшүчеләрнең төрле әләкләре аркасында иркеннән мәхрүм ителгән фән, мәдәният эшлеклеләренең, атаклы шәхесләрнең санын ул елларда дистәләп түгел, йөзләп санарга булыр иде. «Җинаятьләр кодексы»ның дәһшәтле 58 нче маддәсе буенча гаепләнеп хөкем ителгән меңнәрчә шәхесләр арасында С. Рафыйков та була. Язучының «гаебе» турында геройның эчке монологы рәвешендә әсәрдә мондый мәгълүмат бирелә: «Ә бит әллә нинди гаепләр тактылар. «Имеш, мин ун троцкийчы буржуаз милләтчедән торган контрреволюцион оешмада булганмын», – дип әйтеп куйды ул үз-үзенә. «Мин хәзер дә белмим андый оешма булганлыгын», дип өстәде. «Галимҗан Ибраһимовка язылган котлау хатында да контр нәрсә юк! Юбилее белән генә котладык, Октябрьнең XX еллыгы белән тәбрикләдек, шул гына!» Сөббух кулындагы ипигә сөйли иде бу вакытта. Ул авыр сулап куйды да кружкага тагын шәраб салды. «Башларым ГУЛАГка китәрлек гаебем нәрсәдә иде соң минем?» [1: 9].

4. Тексттагы хикәяләүче һәм аның янындагыларга нинди бәя бирелә?

Әлеге сорауга килү җиңелдән түгел. Укытучы укучыларның үзләрен активлыкка тарта, аларның шәхси фикерләрен әйтүгә, хәтта бәхәскә тарту мөһим. Фикер алышу мондый мәгълүматларга бәйле алып барыла. Әлбәттә, хакимият башында утыручыларның мантыйгы ул чорның күп кенә зыялылары өчен сәер һәм хикмәтле тоела. Билгеле, XX гасырның төп лозунгы-шигаре

көрәш идеясеннән гыйбарәт. Ләкин инкыйлаб җилләре күптән тынган, Бөек Ватан сугышында җиңү яуланганнан соң кем белән һәм нәрсә хакына көрәшергә кирәк? Кеше үзе яшәгән җәмгыять белән нигә көрәшергә тиеш? Ни өчен зыялы кешеләрнең күбесе халык дошманы булып чыга? Әлеге һәм башка сораулар Сөббух Рафыйковны гына түгел, бик күпләрне борчый. Һәм әнә шул зыялылар илдәге хакимиятнең кешелексез эш-гамәлен теге яки бу рәвештә фаш итәләр дә. Хикәядә Д. Гарифуллин, ретроспекция алымын файдаланып, героен үткәннәрне искә төшерергә мәҗбүр итә һәм төп геройның «гаеп»ләре шактый күп булуы ачыклана.

Укучылар әсәрдән өзекләр табып укыйлар. Текст буенча эшләүгә вакыт җәлләмәскә кирәк. Укучы язучы сүзенең асылына тирәнрәк төшенсен. Менә әсәрдән өзекләр: «Сөббух шәхес культы чорының үлеш-бетеш сәясәтенә нәфрәтен белдерә. Аш табынында Банат апасы аларны «шомлы сүзләр»дән туктата туктатуын. Әмма Галимҗанны озата чыккач, шактый гына төшереп алган Сөббух йөрәк ярсуына чыдый алмый: чирәмгә ятып совет властен сүгә, чит илне мактап ташлый, илдә мондый власть озак яшәмәс, ди» [1: 9]. «Гаеп» дип атарлык башка фактлар да искә төшә башлый: кемгәдер Фәтхи Бурнашны кысалар, дигән ул; шагыйрь Мансур Крымовны үзенең остазы дип таныган; Татарстан язучылары җитәкчесе Ләбиб Гыйльмановның халык дошманы булуына шик белдергән һ.б. Нәтиҗәсе – шул еллар өчен типик: төнлә килгән «кара козгын» машинасы аны еракка алып китә.

Билгеле, фикер алышу төрле юнәлештә булырга мөмкин. Укытучы исә әлеге елларның каршылыгын ача. Кешеләрнең пропагандага ышанырга мәҗбүр булулары турында сөйли.

Д. Гарифуллин хикәясендә сәяси тоткыннарның язмышы бөтен трагизмы белән сурәтләнә. Мәсәлән, тоткыннар азат ителгәч, алар «чит элемент», кирәксез, төрмәдә утыру белән тапланган кеше буларак кабул ителәләр. Моның ачысын үз вакытында Хәсән Туфан да, Аяз Гыйләҗев тә татып карыйлар. Сөббух Рафыйковка да бу күренешнең шаһиты булырга туры килә. Д. Гарифуллин бу хакта язмаса да, китапта язучының авылдашы Н. Гарифҗанованың әрнү тулы шигыре теркәлә. Н. Гарифҗанова, эпиграф рәвешендә «Төрмә, сөргеннәрне үтеп исән кайткан С.Рафыйковны авылы танымаган, кул бирмәгән...» дип язып куя. Еллар аша ул Сөббух Рафыйковка мөрәҗәгать итә: *«... Әйе, Сөббух абый, гафу сорыйм, / Менә күпме шаһит каршында...»* [1: 9].

5. Әсәр синдә нинди хис-тойгылар, уй-фикерләр уятты? Дәреснең иң җитди өлешендә укучылар, укыганнарына нигезләнеп, нәтиҗә ясыйлар. Әһәмияте шунда, укучылар үткәндәге тарихыбыз сабакларын бәяләү аша милләтнең алдынгы шәхесләрен шул рәвешле юкка чыгару сәясәтенә юл куярга ярамаганын аңласыннар иде. Шәхси фикерләр буенча сөйләшү вакыт мөмкинлек биргән кадәр дәвам иттерелә.

Дәреснең рефлекция өлешендә укучылар әсәргә анализ ясау юлын эзлекле сөйләп, гомуми нәтиҗәгә киләләр. Өй эшенә эссе язарга бирелә: «Сталин репрессияләре фаҗигасе һәм аның нәтиҗәләре».

Шулай итеп, әлеге дәрестә Д. Гарифуллин әсәрен анализлау юлы һәм, укучыларны актив эшчәнлеккә тарту максатында, фронталь эшләү, мөстәкыйль биремнәр үтәү, компьютердан файдалану алымнары күрсәтелде. Боларның әсәрдәге вакыйгалар аша укучыларда милли үзаң формалаштыруга хезмәт итүе билгеләнде.

ӘДӘБИЯТ

1. Гарифуллин Д. Норильлаг тоткыны. – Яр Чаллы: «Яр Чаллы» типографиясе, 2003. – 80 б.

2. Заһидуллина Д. Милли үзаңны үстерү мәсьәләләре // Мәгариф. – 2008. – № 5. – Б. 5–8.

3. Закирҗанов Ә. М., Гафиятуллина Э. Х. Хәзерге әдәбият дәресе: тәҗрибә аша нәтиҗәлеләккә // Правовые основы функционирования государственных и региональных языков в условиях дву-и многоязычия (мировой опыт реализации языковой политики в ивных государствах): международная научно-практическая конференция, 11 декабря 2019 года, г.Казань: сб. материалов / сост.: Г. Н. Мухарлямова, Д. М. Абдуллина, М. М. Шакурова, Л. М. Гиниятуллина. – Казань: ИЯЛИ, 2019. – Б. 78–81.

4. Историки и писатели о литературе и истории // Вопросы истории. – 1988. – № 6. – С. 60 – 63.

5. Википедия. Д. Гарифуллин. – URL: https: //tt.wikipedia.org/wiki/ Дамир_Гарифуллин; Д. Гарифуллин: «Татарның газапларын, горурлыгын дөньяга танытырга кирәк». – URL: https://www.azatliq.org/a/25424321.html Мөрәҗәгать итү вакыты 08.10.2021.

6. Норильлаг. Темное прошлое города. – URL: https: //diletant.media/articles/43730941/. Мөрәҗәгать итү вакыты 08.10.2021.

## ФОРМИРОВАНИЕ ЧИТАТЕЛЬСКОЙ ДЕЯТЕЛЬНОСТИ НА УРОКАХ РОДНОЙ ЛИТЕРАТУРЫ

**Г. И. Гизеева, Е. Г. Чегаева**

*МБОУ «Основная общеобразовательная школа № 17 имени Героя Советского Союза Н. А. Катина Зеленодольского муниципального района Республики Татарстан», Россия*

Gizeeva@mail.ru, alenkachegaeva@gmail.com

## FORMATION OF READING ACTIVITY IN THE LESSONS OF NATIVE LITERATURE

**G. I. Gizeeva, E. G. Chegaeva**

*Municipal budgetary educational institution «Basic secondary school No. 17 named after Hero of the Soviet Union N.A. Katina Zelenodolsk municipal district of the Republic of Tatarstan», Russia*

Gizeeva@mail.ru, alenkachegaeva@gmail.com

Читательская деятельность способствует развитию познавательных функций ученика. Особенности чтения как речевого занятия делают его очень эффективным средством обучения, расширяются знания о действительности, формируются и закрепляются нравственно-духовные качества, что способствует полноценному развитию обучающихся как личности.

**Ключевые слова:** чтение, речь, читательская деятельность, родная литература, обучающийся, интеллект.

Reading activity contributes to the development of the student's cognitive functions. The peculiarities of reading as a speech lesson make it a very effective means of teaching, knowledge about reality expands, moral and spiritual qualities are formed and consolidated, which contributes to the full development of students as a person.

**Key words:** reading, speech, reading activity, native literature, student, intellect.

Чтение является основным средством обучения, инструментом для понимания мира, развития интеллектуального потенциала ребенка.

Выражение «умение читать» охватывает широкий спектр определений: от умения вкладывать слоги в слова до умения не только читать текст, но и его осознание, эмоциональная реакция на каждое действие героя, беспокойство о нем.

Трудности формирования читательской деятельности выходят за рамки школьной программы. Успешность обучающихся как личности в целом, зависят от таких основных факторов как культура чтения, способности усваивать максимум информации из прочитанного. Правильная и осознанная читательская деятельность способствует достижению следующих целей, поставленных образованием:

– создание творческого человека, обладающего некоторым научным потенциалом;

– освоение учащимися базовых общеобразовательных знаний, способствующих развитию их познавательных навыков и умений в процессе освоения образовательных программ школы;

– знакомство с национальной, мировой культурой, с традициями своей страны, с самобытностью культурных и исторических особенностей с учетом национального мировосприятия;

– формирование у обучающихся гражданской и нравственной позиции, ориентированной на национальные ценности и глобальные гуманитарные науки в целом.

Формирование и развитие читательской деятельности на уроках родной литературы во многом определяет успехи обучающихся. Чтение – это важный инструмент образования, при помощи которого можно влиять не только на ум, но и нравственность учеников.

Чтение – неиссякаемый источник обогащения знаний, универсальное средство развития познавательных и речевых навыков учащегося, его творческих способностей, мощное средство воспитания нравственных качеств.

Продуктивность работы с разнообразными текстами зависит от методов семантической обработки, которые читатель использует для понимания. Любая учебная деятельность основана на правильном, беглом и главное осознанном чтении. Необходимость формирования и совершенствование читательской деятельности на уроках родной литературы который помогает улучшить качество чтения в школьном возрасте, обосновано современностью, так как ученикам необходимо воспринимать огромное количество информации.

Чтение – это сложная психологическая деятельность, прежде всего процесс смыслового восприятия письменной речи и ее понимания. Каждый текст является лишь условием умственной деятельности: то, что объективно содержится в тексте, может принимать субъективную форму в сознании читателя, и эта субъективная форма существования является результатом его собственной умственной деятельности.

В настоящее время уровень качества чтения является низким, и, следовательно, важность этого процесса остается неизменной, что обуславливает актуальность формирования читательской деятельности на уроках родной литературы.

Уроки родной литературы помогают ученикам познавать и углублять знания о традициях и самобытности своего народа, читать книги авторов на родном языке, рассказывающие о жизни родного народа. Такие писатели гораздо ближе, то, что они описывают, понимается практически сразу, а зарубежные

произведения можно полностью понять только тогда, когда изучишь историю и особенности другой страны.

Изучение литературы коренных народов важно для формирования личности каждого человека, поскольку произведения национальных писателей затрагивают не только вечные проблемы, но и вопросы, важные для данной страны.

Изучение прозы соотечественников тем более ценно, что эти авторы являются представителями определенного региона данной страны. С помощью литературы о Родине углубляется чувство любви к ней. А любовь к Родине – важная нравственная черта каждого человека. В этом ценность отечественной литературы.

Чтение является одним из средств улучшения учебного процесса для различных уровней образования, от начальной до средней школы. Школа закладывает фундамент для всестороннего развития детей. Основную роль в этом процессе играет читательская деятельность, которая способствует формированию успешности обучающегося.

В школе дети учатся читать согласно литературным программам чтения, которые учитывают их психофизические особенности и направлены на исправление и компенсацию нарушений речевого развития.

Правильная и красивая речь также является предпосылкой для общего и полноценного развития детей и их уровня чтения. Чем насыщеннее и правильнее речь ребенка, тем легче ему выражать свои мысли, чем больше у него способности познавать окружающую действительность, тем значительнее и полнее отношения с окружающими, тем активнее его умственное развитие. Вследствие этого важно позаботиться о своевременном формировании детской речи, ее чистоте и правильности, ритме, богатстве интонации, чему способствует читательская деятельность на уроках родной литературы.

Читательская деятельность на уроках родной литературы способствует воспитанию у детей богатой и нравственно ориентированной духовной личности через ее приобщение к культурному наследию, формирование этнокультурной идентичности у детей школьного возраста, что занимает важное место в воспитании молодого поколения, способствует творческому развитию личности и повышает уровень чтения для каждого учащегося.

## ЛИТЕРАТУРА


1. Авдеева А. В., Молькова М. В. Формирование читательской компетенции младших школьников // Молодой ученый. – 2015. – № 22.1 (102.1). – С. 44–46.
2. Акимова А. Г. Читательская культура молодежи: мифы и реальность // Электронный источник. Режим доступа: http://lib.1september.ru/2006/08/16.ht
3. Галкина Л. П. Формирование читательского интереса младшего школьника как педагогическая проблема // Научное сообщество студентов XXI столетия. Гуманитарные науки: сб. ст. по мат. XLV междунар. студ. науч.-практ. конф. – № 8 (45). URL: https://sibac.info/archive/guman/8(45).pdf (дата обращения: 09.10.2021)/
4. Доскарина Г. М. Исследование в действии: Способы и приемы повышения уровня читательской грамотности учащихся / Г. М. Доскарина, А. С. Сабитова // Молодой ученый. – 2016. – № 10.4. – С. 19–21/
5. Шифрина Д. В. Новые подходы к литературному образованию младших школьников в свете современных требований // Проблемы и перспективы развития образования: материалы Междунар. науч. конф. – Пермь: Меркурий, 2011. – С. 192–195.

# ПРИМЕНЕНИЕ РАЗНЫХ ТЕХНОЛОГИЙ НА УРОКАХ РОДНОГО ЯЗЫКА В НАЧАЛЬНОЙ ШКОЛЕ

**Ч. Х. Гилязиева**

*МБОУ «Арская НОШ № 3 – детский сад», г. Арск, Россия*
tchulpan00@mail.ru

# THE USE OF DIFFERENT TECHNOLOGIES IN THE LESSONS OF THE NATIVE LANGUAGE IN ELEMENTARY SCHOOL

**Tsch. H. Gilyazieva**

*Municipal budgetary educational institution «Arskaya primary secondary school No. 3 – kindergarten», Arsk, Russia*
tchulpan00@mail.ru

Данная статья посвящена анализу технологий, проименяемых на урокоах роднога языка. Особое внимание уделяется работе в начальной школе. Рассматриваются такие технологии, как компьютерные, игровые, здоровьесберегающие, личностно-ориентированные.
**Ключевые слова:** родной язык, начальная школа, техгологии, речевые навыки.

This article is devoted to the analysis of technologies used in native language lessons. Special attention is paid to work in primary school. Such technologies as computer, gaming, health-saving, personality-oriented are considered.
**Key words:** native language, elementary school, technical sciences, speech skills.

Родной язык является средством овладения знаниями, изучения всех учебных дисциплин в школьном и последующем образовании. Обучение родному языку помогает решать задачи нравственного воспитания. Ребенок усваивает через язык нормы морали, нравственные установки, которые при целенаправленном воспитании, становятся эталонами его собственного поведения, отношения к окружающему миру, к себе.

Успешное обучение возможно только в том случае, если учителю удается пробудить интерес к изучаемому предмету и не только пробудить, но и систематически поддерживать его. В связи с этим возникает задача использования различных технологий при организации учебного процесса.

При проведении уроков родного языка я стараюсь использовать такие педагогические технологии как: компьютерные, игровые, здоровьесберегающие, личностно-ориентированные технологии.

Применение ИКТ является одним из важных и новых средств в учебном процессе. Использование его способствовало появлению новых информационных технологий. Компьютерные технологии позволяют реализовать основные методы обучения родному языку: показ, объяснение, оценка знаний.

Использование ИКТ на уроках родного языка помогает:

– наглядно представить обучения изучаемым языковым явлениям;

– формировать речевые навыки на изучаемом языке;

– контролировать знания, определенной степени формирования умений и навыков.

Применение ИКТ на уроках родного языка имеет следующие положительные стороны:

– индивидуализация содержания учебного процесса, быстрое усвоение объемного материала;

– возрастает познавательная активность учащихся;

– за счет экономии времени возрастает эффективность урока;

– учет психологических особенностей детей и объективная оценка знаний;

– меняется характер работы учителя.

Следующая форма – это групповая работа. Главное педагогическое правило – не разделять учеников на сильных и слабых, а организовать взаимообучение детей методом совместно-групповой учебной деятельности. Задача данной формы: включить каждого ученика в деятельность, обеспечивающую формирование и развитие познавательных потребностей. Разрабатывается такое задание, и такая методика при котором ученик обязательно справляется с работой. Класс разбивается на 2–3 группы. Дети в группах организованы с разным уровнем развития. Группы получают задания. Задания выполняют все, при этом идет опрос друг друга, сильный ученик помогает слабому ученику. Таким образом, все ученики все полезное время потратили на достижение главной цели урока.

Большое значение на уроках уделяю здоровьесберегающей технологии. Задачи этой технологии: помочь ученику преодолеть усталость, неудовлетворенность. У учащихся развита способность улавливать эмоциональный настрой учителя, поэтому с первых минут урока, с приветствия нужно создать обстановку доброжелательности, положительный эмоциональный настрой. На уроках использую простейшие упражнения для глаз, физкультминутки, различные упражнения.

Игровую технологию использую при освоении понятий, изучении темы, объяснении нового материала и его закреплении, при обучении устным видам речевой деятельности.

Задачи игровой технологии: активизация коммуникативной деятельности учащихся, правильное распределение ролей между детьми, поскольку они имеют разный уровень речевой подготовки, создание ситуации взаимопомощи, активного устно-речевого общения, эмоциональное состояние учащихся, что может повлиять на качество усвоения материала и результат игры.

При организации уроков родного языка можно использовать нетрадиционные виды уроков такие как – урок-путешествие, урок-игра. Во время игры учащиеся более свободно ориентируются в предложенной ситуации, могут свободно импровизировать. У них появляется живой интерес к уроку. В ролевой игре можно работать в паре, в составе группы.

Личностно – ориентированные технологии главной задачей являются не только дать определенную сумму знаний, но и развивать у них интерес к учению, к творческой работе, стремиться использовать полученные знания самостоятельно, учитывать индивидуальный подход, построить учебный процесс в форме диалога с учеником.

Одним из путей такой новизны я вижу разработку и применение различных видов дидактического материала, создание которого позволяет восполнить ограниченность в заданиях учебников, разнообразить формы обучения, повышающие творческую активность учащихся. При этом учащиеся приобретают умения и навыки. Ученики не замечают, что учатся, познают, запоминают новое, проявляют творчество.

Таким образом, использование новых технологий на уроках родного языка в начальной школе, формируют интерес к предмету, активизируют познавательную и мыслительную деятельность, творческие способности, раз-

вивают наблюдательность. Такие яркие уроки помогают детям легко и быстро усвоить учебный материал.

Основным результатом своей деятельности, я считаю, получение детьми прочных знаний, умений, навыков по родному языку. Умение их применять на практике. Обучение будет успешным, если знания, умения, навыки усваиваются учащимися в строгой последовательности, постепенно в порядке вырастающей трудности и сложности с ним, чтобы школьник поднимался по ступеням. При изучении любого языка мира человек старается научиться его коммуникативной деятельности. Исходя из принципов коммуникативной методики, содержание должно соотноситься с возрастными особенностями учащихся.

ЛИТЕРАТУРА

1. Мухаметзянова А. Х. Методическое пособие по ФГОС для учителей татарского языка и литературы: Учебное пособие. – К.ТРМУИ, 2015. – 105 с.

2. Шакурова М. М. Методика преподавания татарского языка: Учебное пособие. – Казань: Магариф, 2014. – 47 с.

3. Применение педагогических технологий на уроках в начальной школе. https://mega-talant.com/biblioteka/primenenie-pedagogicheskih-tehnologiy-na-urokah-v-nachalnoy-shkole-kak-sredstvo-povysheniya-kachestva-obucheniya-88753.html

## ПРОБЛЕМНЫЕ СИТУАЦИИ НА УРОКЕ КАК ОСНОВА ПРОБЛЕМНОГО ОБУЧЕНИЯ

**Л. Г. Гилязова, Г. В. Хадиева**

*Институт развития образования Республики Татарстан, Россия*
glg4@yandex.ru

## PROBLEM SITUATIONS IN THE CLASSROOM AS THE BASIS OF PROBLEM-BASED LEARNING

**L. G. Gilyazova, G. V. Khadieva**

*Institute of Education Development of the Republic of Tatarstan, Russia*
glg4@yandex.ru

Современное образование требует от педагога не только трансляции готовых знаний, но и умения научить учащихся понимать и разбираться в теме самостоятельно. Одной из технологий достижения такого результата является проблемное обучение. При проблемном обучении учитель создает проблемную ситуацию, направляет и организует поиск решения. У учащегося развивается творческий подход к познанию учебного материала, развиваются мыслительные способности.
**Ключевые слова:** проблемное обучение, проблемная ситуация, универсальные учебные действия, методы обучения, творческая деятельность.

Modern education requires from the teacher not only the translation of ready-made knowledge, but also the ability to teach students to understand and understand the topic independently. One of the technologies to achieve such a result is problem-based learning. With problem-based learning, the teacher creates a problem situation, directs and organizes the search for a solution. The student develops a creative approach to learning the educational material, develops thinking abilities.
**Key words:** problem-based learning, problem situation, universal learning activities, teaching methods, creative activity.

# ПРОБЛЕМАЛЫ УКЫТУНЫҢ НИГЕЗЕ БУЛАРАК ДӘРЕСТӘ ПРОБЛЕМАЛЫ СИТУАЦИЯЛӘР

**Л. Г. Гыйләҗева, Г. В. Һадиева**

Федераль белем бирү стандартлары *(алга таба ФДББС)* таләп иткәнчә, укытучы уку бурычларын укучыларны актив эшчәнлеккә тарта, укуга мотивация тудыра торган уку ситуацияләренә (*алга таба УС)* күчерә белергә тиеш. УС укучыны алдагы эшчәнлеккә кызыктыра, дөрес оештырылган ситуациядән укучыларның уку бурычын куя алу-алмаулары хәл ителә.

Мәктәптә универсаль уку гамәлләре (*алга таба УУГ)* үстерүнең технология, метод һәм ысуллары арасында билгеле бер УУГ үстерүгә караган уку ситуацияләре зур урын алып торалар. Алар предмет эчтәлегендә төзелгән булырга мөмкин һәм предметтан тыш характерга ия булалар.

Проблемалы укыту укучы алдына тормышта кирәк булган әһәмиятле мәсьәләләрне хәл итү бурычын куя. Бу исә укучыда аз гына вакыт эчендә дөрес юнәлеш ала белү, эзләнү өчен үзендә булган белем һәм күнекмәләрне туплый алу, ышанычлы һәм төгәл юл сайлый белү кебек сыйфатларны формалаштыра.

Проблемалы укыту элементларын Сократның эвристик әңгәмәләрендә, Жан Жак Руссоның дәрес эшкәртмәләрендә, шулай ук К. Д. Ушинский хезмәтләрендә күрергә мөмкин. Проблемалы укытуның идея һәм принципларына караган фәнни-тикшеренү эшләре фикерләүнең психология юнәлешендә психиатрлар С. Л. Рубиштейн, Д. Н. Богоявленский һәм Н. А. Менчинский тарафыннан эшләнде. Ә мәктәп укыту системасында аны куллану турында М. А. Данилов һәм М. Н. Скаткин кебек дидактлар язып чыктылар, педагог-галимнәр М. И. Мәхмүтов, И. Я. Лернер күп шөгыльләнделәр [5].

Федераль белем бирү стандартларын тормышка ашыру этабында предметны өйрәнүгә мотивлаштыра белү бик мөһим. Танып белү активлыгын стимуллаштыруның бер ысулы булып дәрестә проблемалы ситуация санала. Югарыда әйтелгәннән тыш, бу метод күзәтүчәнлекне, логиканы, чит кешенең фикеренә игътибарлы булуны, дискуссия алып бара белүне үстерә. ФДББС таләп иткәнчә, укытучы уку бурычлары аша укучыларны актив эшчәнлеккә тарта, укуга мотивация тудыра торган уку ситуацияләренә күчерә белергә тиеш. Уку ситуацияләре укучыны алдагы эшчәнлеккә кызыктыра, дөрес оештырылган ситуациядән укучыларның уку бурычын куя алу-алмаулары хәл ителә.

Мәктәптә УУГ үстерүнең технология, метод һәм ысуллары арасында билгеле бер гамәлләрне үстерүгә караган УС зур урын алып торалар. Алар предмет эчтәлегендә төзелгән булырга мөмкин һәм предметтан тыш характерга ия булалар.

Уку ситуацияләре – дәреснең дифференциацияләнгән өлеше, ул махсус нәтиҗәләр алу өчен кирәкле шартлар комплексын үз эченә ала. Ул – укыту процессының үзенчәлекле берәмлеге, анда балалар укытучы ярдәмендә үзләренең эш-хәрәкәтләрен белдереп, аны тикшерәләр, төрле укыту гамәлләре башкарганда, үзгәртеп формалаштыралар яки үзләренең тасвирламасын тәкъдим итәләр, өлешчә истә калдыралар. УС – дәреснең үзенчәлекле нәтиҗәләргә ирешү өчен кирәкле шартлар комплексын үз эченә алган дифференциацияләнә торган өлеше. [1]

Уку ситуацияләре проблема (каршылыклар) һәм аны хәл итү ысулын үз эченә ала, укытучы, балалар алдына проблема куеп, куелган мәсьәләнең асылын үзе аңларга, шулай ук, балаларга ничек җавап бирергә һәм укучыларга

проблемаларны хәл итү, фикер йөртү алгоритмын төзүдә буталмаска ярдәм итәргә әзер булырга тиеш. УС булдыру проблемалы укыту процессыннан гыйбарәт. Ул диалог ярдәмендә белемнәрне иҗади үзләштерүне тәэмин итә. Әлеге метод белем бирү системасын үстерергә, белемнең югары сыйфатын, интеллектның һәм иҗади сәләтләрнең нәтиҗәле үсешен, актив шәхес тәрбияләүне тәэмин итә.

УС булдыру юлы белән укыту методы түбәндәгеләргә юнәлтелгән: проблемаларны ачыклау, проблемаларны хәл итү юлларын сайлау, мәгълүмат белән эшли белү, башка кешеләрне тыңлау һәм аңлау, төркемдә эшли белү.

Уку ситуацияләре формалаштырганда укытучының бурычы – УС булдыру, уку материалын сайлап алу, оештыру ысулын билгеләү, балаларның мөмкин булган гамәлләрен фаразлау, уку бурычларын ситуациягә күчерү.

Дәрестә УС бер яки берничә булырга мөмкин, дәрес билгеле бер тәртиптә бер-бер артлы төрле УС торырга мөмкин һәм ул конкрет укучыга юнәлгән була. Һәр УС өчен эш чаралары була: укучыларның эчке (белем һәм күнекмәләр) һәм тышкы (дәреслекләр, күрсәтмәлелек, төрле типтагы приборлар һ.б.) эш чаралары. УС укучылар укытучы ярдәмендә үзләренең эшчәнлек предметларын билгелиләр, төрле характердагы уку эшчәнлекләре кулланып, аны өйрәнәләр, табалар, үзгәртәләр, яңадан формалаштыралар яки үзләренең фикерләрен, эшләрен тәкъдим итәләр, өлешчә – истә калдыралар [4: 18].

УС дәреснең максатларын куйганда, регулятив УУГ (дәреснең максатларын кабул итү, аңлау, бурычларны формалаштыру) өстендә эш бара. Уку бурычларын кую аркылы планлаштыру эшчәнлеге җайга салына. Шул ук вакытта танып белү УУГ дә (анализ, синтез, гомумиләштерү) тормышка ашырыла. УС өстендә эшләү өчен эчтәлеккә логик-дидактик анализ үткәрергә кирәк, чөнки максатлар эчтәлек нигезендә формалашалар. Эчтәлек үз эченә белем, күнекмәләрне генә түгел, ә универсаль күнекмәләрне дә, тәҗрибәне дә, иҗади эшчәнлекне дә кертә. Мәсәлән:

– укучыларда танып белү мотивы булу, белергә омтылыш булу, конкрет уку максаты булу;

– укучыларда предмет буенча башлангыч (база) белем, күнекмәләр булу;

– мөстәкыйль эшләргә сәләтле булу;

– укучыларның фикер йөртү конструкциясен үзгәртүгә сәләтле булуы.

УС барлыкка килү өчен түбәндәге кагыйдәләр исәпкә алынырга тиеш:

– укучы яңа белемнәр ачарга тиеш;

– проблемалы бирем укучы «ачарга» тиеш булган яңа белемне (теманы) үз эченә алырга тиеш;

– укучы үти алмаган практик бирем нигезендә яңа теманы өйрәнү ихтыяҗы туарга тиеш.

ФДББС шартларында урта мәктәптә УС типологиясенә ситуация-проблема, ситуация-иллюстрация (цитата, тормыштан алынган факт, тарихи яки фәнни факт һ.б.), ситуация-бәя һәм ситуация-тренинг кебек төрләр керә [2: 18].

УСнең максаты – укучыларга үзләрен иҗади яктан тормышка ашырырга һәм билгеле бер сыйфаттагы үз продукциясен алырга мөмкинлек бирә ала торган мохит тудыруда. Дәрестә «укытучы-укучылар» үзара хезмәттәшлегенең продуктив эшчәнлеге генә нәтиҗәләр бирәчәк. УС баланың яшен, уку предметының үзенчәлеген, укучыларның УУГ формалашу чараларын исәпкә алып төзелә.

УС ярдәмендә укыту нәтиҗәсендә биш универсаль компетентлык үсеш ала: 1) тикшеренү сәләте; 2) нәтиҗәле коммуникацияләргә һәм үзара

хезмәттәшлекне оештыруга сәләт; 3) карар кабул итү сәләте; 4) кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру сәләте; 5) эшчәнлекнең яңа төрләрен даими үзләштерү сәләте.

УС теләсә нинди предметлы эчтәлектә һәм теләсә нинди белем бирү баскычында кулланыла ала. Әлеге методика укучыны гына түгел, укытучыны да үстерә. Укытучы иҗади шәхес, коммуникатив лидер буларак үсә, ул хәзерге шартларда катлаулы педагогик бурычларны уңышлы хәл итәргә сәләтле.

Тел дәресләренең нәтиҗәлелеге – укучыларның телдән һәм язма сөйләменең үзара бәйләнеше ничек итеп рациональ рәвештә үзгәрүенә, фикердән сөйләмгә күчкәндә барлыкка килә торган кыенлыкларны бетерү өчен шартлар тудыруына турыдан-туры бәйле. Телдән һәм язма сөйләмне кабул итә белү телдән һәм язма сөйләмне төзү осталыклары белән бергә формалаштыра торган сөйләмгә комплекслы өйрәтүнең иң нәтиҗәлесе булып тора.

ӘДӘБИЯТ

1. Андреев В. И. Педагогика / В. И. Андреев. – Казань: Центр инновационных технологий, 2014. – 605 с.

2. Добротина И. Г. Современные модели уроков русского языка в 5–9 классах/ И. Г. Добротина. – М.: Просвещение, 2014. – 192 с.

3. Матюшкин А. М. Проблемные ситуации в мышлении и обучении/ А. М. Матюшкин. – М.: Педагогика, 2015. – 186 с.

4. Новикова Э. Б., Берандзе М. З. Инновационные методы обучения/ Э. Б. Новикова, М. З. Берандзе // Кейс-метод Педагогические науки. – 2014. – № 3 (66). – С. 18–19.

5. Хуҗиәхмәтов Ә. Н. Педагогика / Ә. Н. Хуҗиәхмәтов. – Казан: Мәгариф, 2004. – 543 б.

# ТЕОРЕТИЧЕСКИЕ ОСНОВЫ ЯЗЫКОВЕДЧЕСКИХ КОНЦЕПЦИЙ ФИЛОЛОГИЧЕСКОГО (ЛИНГВИСТИЧЕСКОГО) АНАЛИЗА ТЕКСТА

**Л. М. Гиниятуллина, М. М. Шакурова**

*Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова*
*Академии наук Республики Татарстан, Россия*
gin_liluk@mail.ru, mshakurova@inbox.ru

# THEORETICAL FOUNDATIONS OF LINGUISTIC CONCEPTS OF PHILOLOGICAL (LINGUISTIC) TEXT ANALYSIS

**L. M. Giniyatullina, M. M. Shakurova**

*Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov*
*of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, Russia*
gin_liluk@mail.ru, mshakurova@inbox.ru

Статья посвящена проблемам изучения теоретической основы лингвистического анализа текста в русском и татарском языклзнании. Особое внимание уделяется строению текста и средствам связи между абзацами текста. Подчеркивается необходимость анализа текста в функциональ-лингвистическом, текстуальном (структурно-семантическом) и функционально-коммуникативном направлениях.
**Ключевые слова:** текст, стилистика, синтаксическое целое, лингвистический анализ, художественная литература.

The article is devoted to the problems of studying the theoretical basis of linguistic analysis of the text in Russian and Tatar linguistics. Special attention is paid to the

structure of the text and the means of communication between paragraphs of the text. The necessity of text analysis in functional-linguistic, textual (structural-semantic) and functional-communicative directions is emphasized.
**Key words:** text, stylistics, syntactic whole, linguistic analysis, fiction.

## ТЕКСТКА ФИЛОЛОГИК (ЛИНГВИСТИК) АНАЛИЗ ЯСАУДА ТЕЛ КОНЦЕПЦИЯЛӘРЕНЕҢ ТЕОРЕТИК НИГЕЗЛӘРЕ

**Л. М. Гыйниятуллина, М. М. Шәкүрова**

Әдәби әсәр теленә бәйле мәсьәләләрне өйрәнү, стилистика мәсьәләләре, стилистика һәм синоним арасындагы нисбәт рус тел белемендә А. А. Потебня, А. М. Пешковский, Л. В. Щерба, В. В. Виноградов, А. Н. Гвоздев, А. И. Ефимов, В. П. Сухотин, Г. Я. Солганик, И. И. Ковтунова, И. Р. Гальперин, Ю. М. Лотман, А. И. Горшков, Н. А. Николина, Л. Г. Бабенко һ.б., татар тел белемендә С. Кукляшев, К. Насыйри, В. Н. Хангилдин, Х. Р. Курбатов, В. Х. Хаков, Ш. Ханбикова, М. З. Зәкиев, С. М. Ибраһимов, Ф. С. Сафиуллина, Г. Ф. Саттаров, И. Б. Бәширова, Р. С. Абдуллина, М. М. Шәкүрова, А. Ф. Йосыпов һ.б. хезмәтләренә таяныла.

XX гасырның 20-30 елларында рус тел белемендә текст, стиль мәсьәләсе зур кызыксыну уята. Бу өлкәдә А. М. Пешковский, Л. В. Щерба, В. В. Виноградов, Г. О. Винокур, Б. В. Томашевский, А. И. Ефимов кебек тел галимнәренең хезмәтләре дөнья күрде. Әлеге галимнәрнең хезмәтләрендә әдәби форманы эчтәлектән аерып өйрәнү, стиль төшенчәсе (Г. О. Винокур, В. В. Виноградов, М. М. Бахтин һ.б.), синонимика (А. М. Пешковский, А. И. Ефимов) кебек проблемалар яктыртыла. 1922 елда Л. В. Щербаның «Опыты лингвистического толкования стихотворений» дигән хезмәтендә рус теле элементларын бирүдә мәгънәви төсмерләрне бирү нюанслары (сүзләр, төрле конструкцияләр, басым, ритм һ.б.) турында фикерләр бар.

Филологик текстны өйрәнүнең синтаксик аспектын Г. Я. Солганик, И. И. Ковтунова, А. И. Овсянникова, Л. Г. Бабенко һ.б. җентекләп тикшерә. Соңгы елларда Н. М. Шанский филологик анализны уку-укыту барышында лингводидактик алым буларак та тикшерә: текст белән танышу, анализ (уку-анализлау), синтез (уку-текстны җыю), текстны анализлауда интерпретаторның роле һ.б. [10: 153].

И. Р. Гальперин текстның лингвистик ягын өйрәнә, текстка тулы билгеләмә бирә: текст ул – төгәлләнгәнлеккә ия булган, язма документ буларак объективлашкан һәм шуңа хас рәвештә әдәби эшкәртелгән сөйләм процессының нәтиҗәсе, үзара лексик, грамматик, логик, стилистик чаралар белән бәйләнгән берәмлекләр тезмәсеннән төзелгән әсәр, синтаксик берәмлек. Ул текстның категорияләрен икегә бүлә (семантик категорияләр, структур категорияләр) һәм текстка гына хас булган билгеләрне күрсәтә: чикләнгәнлек, информативлык, билгеле бер жанрга карау, тәмамланганлык һ.б. И. Р. Гальперин текстны күләм-прагматик һәм контекст-вариатив дигән төрләргә бүлә, текстта сөйләмнең өч төрле актын билгели: автор сөйләме, чит сөйләм һәм уртак сөйләм [3: 18].

Г. Я. Солганик текст эчендәге чылбырлы бәйләнешне (тәмамлык – ия; хәл – ия; тәмамлык – тәмамлык; ия – тәмамлык, ия – ия) һәм параллель бәйләнешләрне (бертөрле грамматик төзелештәге җөмләләрне) тикшерә [8: 238].

Л. Г. Бабенко әдәби текстны тикшергәндә төрле үзенчәлекләргә туктала, төп геройны үзәккә куя, прагматиклык, концептуальлек, эчке һәм тышкы бәйләнеш, текстны интерпретацияләүне алга чыгара. Соңгы елларда әдәби

текстка лингвистик анализ ясауга караган хезмәтләр арасында Л. Г. Бабенко, Ю. В. Казаринның «Лингвистический анализ художественного текста» (2003) дигән хезмәте аеруча игътибарга лаек. Авторлар текстның семантик кырын һәм аңа анализ ясауга җентекләп тукталалар: текстның семантикасын өйрәнү аспектлары, концептуаль, денотатив, эмотив кырлары яңача анализлана [1: 49].

Текст эчендә текст булуга – интертекстуальлеккә Л. А. Новиков та игътибар итә. Авторлар, әсәрне тагын да җанландырып җибәрү максатыннан, әлеге алымны бик яратып кулланалар. Галим әсәр атамаларының мәгънәви аермаларына җентекләп туктала һәм аларның текст эчендәге функцияләрен күрсәтә [5: 23]. Мәсәлән, Галимҗан Гыйльманның «Фронтовиклар» парчасында фронтовик карт белән танышып кына калмыйбыз, аның ап-ак чәчле малай турындагы хикәясе дә безне үзенә җәлеп итә.

Әдәби әсәрдән алган өзекләр ХХ гасыр башы татар әдәбиятын тирәнрәк өйрәнү белән бергә, әсәрләрнең лексик үзенчәлекләрен дә тикшереп-карап үтүнең мөһимлеген, тарихи-мәдәни белешмә бирүнең, гомумән, комплекслы өйрәнү зарурилыгын ассызыклау өчен тикшерелә. Текст мәсьәләсе белән бәйле фикерләр Һ. Максуди, Г. Ибраһимов, Г. Алпаров, Җ. Вәлиди, Х. Бәдигый, Х. Курбатов һ.б. хезмәтләрендә урын алган. Соңрак И. Б. Бәширова шигъри һәм прозаик әсәрләрдә сүз белән сурәт ясауның төрле алымнарын бирә [2: 14].

В. Х. Хаков исә ХХ гасыр башларында иҗат ителгән әсәрләргә һәм публицистик язмаларга лексик-семантик һәм лингвистик-стилистик анализ ясый [9: 62]. С. Ш. Поварисов әдәби әсәрнең телен өйрәнә, сурәтләү чараларын, грамматик формаларны тикшерә [6: 44]. Ф. С. Сафиуллина текст теориясен, татар әсәрләренең текст буларак оешу закончалыкларын өйрәнә [7: 49]. И. М. Низамов татар сөйләменең массакүләм коммуникация системасындагы ролен тикшерә [4: 41].

Текстның төзелешенә килгәндә аны өч өлешкә бүлеп тикшерәләр: хикәяләүче текст, хөкем йөртүче һәм тасвирламалы текст. Когезия аерым җөмләләр, абзацлар арасындагы бәйләнешне белдерә. Мәсәлән, Г. Гыйльмановның «Фронтовиклар» парчасында 12 абзац, 453 җөмлә, 2621 сүз бар. Абзацлар үзара бик тыгыз бәйләнгәннәр һәм уңышлы итеп бүленгәннәр. Аларның өчесе генә диалог рәвешендә башланган, ләкин 7–11 нче абзацлар бер үк кешенең туры сөйләмен – фронтовикның хатирәләрен чагылдыра. Абзацларны башлап җибәрүдә бертөрлелек күзәтелми, автор төрле чаралардан мул куллана:

Ә мин бу көнне бик кыю идем. Уйлап та тормыйча, карт ветеранның сугыш юлларында тап булган иң истәлекле хатирәсе хакында сорадым.

Әңгәмәдәшем шунда ук уйчанланып, басылып калды. Әмма бу сорау аның өчен бөтенләй үк көтелмәгән түгел иде.

Малай... – дип куйды ул, соравым артыннан ук. – Ап-ак чәчле малай...

Инде мин җитдиләндем. Ничек инде – малай?.. Әллә соравымны аңламадымы?

Ап-ак чәчле! Беләсеңме, ап-ак... Ә күзләре... һәм ул сөйләп китте. (Г. Гыйльманов «Фронтовиклар»).

Аерым алганда, бәйләүче чара буларак түбәндәге сүз төркемнәре кулланыла:

исем: әңгәмәдәшем; Малай...;

сыйфат: ап-ак ...;

алмашлык: без...; мин...; кая ул...;

рәвеш: бүген...;
теркәгеч: ә ...;
кисәкчә: инде ...

Димәк, бер абзацны икенчесенә бәйләгәндә мөстәкыйль сүз төркемнәре белән беррәттән каршы куючы теркәгечләр дә күпләп кулланыла, шушы ук вазифаны башкара [11: 82].

Ф. Әмирханның «Кадерле минутлар» әсәреннән алынган өзектәге абзацара бәйләнешләргә тукталып үтик [12: 43]. Өзек 16 абзацта бирелә, шуларның дүртесе диалог формасында башланып китә, ләкин, безнең фикеребезчә, 7 нче абзацны, шул ук диалогик сөйләмне игътибарга алып, икегә бүлеп кую уңышлырак булыр (ягъни «– Беләсез, әфәнделәр! Язның бу мин сөйли торган...» дип башланган өлешне сигезенче абзацка чыгару кулайрак). Өзек күбесенчә монологик сөйләмнән торса да, мондагы диалог өлешләре Рәшат белән мәҗлестәге дуслары арасында бара:

Эчпошыргыч сүзләрдән мәҗлес халкы үзе дә туйган иде инде. Кызыклырак бер мәсьәлә ачылмасмы өмете белән Рәшатны шул кадерле минутларын сөйләргә кыстый башладылар.

Рәшат, әйле-шәйле бераз торганнан соң, йомшак креслоларның берсенә киерелебрәк кырын ятты, пенснесен уңгайлап куйды да сөйләргә тотынды:

– Кадерле минутларымның берсен, иң әүвәлгесен, әфәнделәр, мин сезгә сөйлим:

Мин әле ул вакытта унсигез генә яшьтә идем. Бу көнге шикелле хәтеремдә, май числосының унҗидесе, кичкә кырын иде. Артык ямьле, гаҗәеп аяз көннең якты, җылы, тыныч һәм хуш [яхшы, гүзәл] исле кичен мин Ботанический бакчадан ерак түгел бер җирдә, Кабан күле читенә ясалган бер агач күпер өстендә каршы алдым. (Ф. Әмирхан. «Кадерле минутлар»)

Абзацара бәйләнеш:

1 нче > 2 нче: Рәшатны (...) кыстый башладылар > Рәшат (...) сөйләргә тотынды;

2 нче > 3 нче «кадерле минутлар») > 4 нче: фикер күчеше;

4 нче > 5 нче: «агач күпер» үзара бәйләп килә;

Күргәнебезчә, зур күпчелектә абзацара бәйләнеш фикер күчеше ярдәмендә бирелә, әмма кайбер абзацларның бәйләнеше шактый үзенчәлекле бирелә. Тексның башлам өлеше (динамик башламнар, тематик башламнар, тасвирлама башламнар һ.б.), төп өлеше һәм бетем өлеше (микротеманы йомгаклау) була. Ф. Әмирханның «Кадерле минутлар» әсәре диалог формасында башланып китә. Биредә абзацара бәйләнешләр җентекләп карала (зат алмашлыклары, теркәгечләр, кереш сүзләр, исемнәр, рәвешләр бик актив кулланыла), текстның сүзлек составы ачыклана, морфологик, синтаксик һәм пунктуацион үзенчәлекләре күрсәтелә. Болар ярдәмендә герой-персонажларның эчке кичерешләрен, психологик моментларын, рухи дөньяларын тирәнрәк итеп ачып була.

Әдәби текстның төп берәмлекләрен аеруда өч юнәлешкә таянырга кирәк:

1) функциональ-лингвистик юнәлеш, ягъни текстны тел структурасы ягыннан анализлау;

2) текстуаль (структур-семантик) юнәлеш (авторга хас булган үзенчәлекләрне дә истә тоту);

3) функциональ-коммуникатив юнәлеш (автор һәм адресат) [13: 130].

Текст теориясендә континуум вакыт һәм урын төшенчәләре белән турыдан-туры бәйле. Г. Гыйльмановның «Фронтовиклар» парчасында

автор-хикәяләүче сөйләмендә фигыльнең билгеле һәм тәмамланмаган үткән заманнары өстенлек итә, ә фронтовик сөйләмендә аларга хәзерге заман формасы да өстәлә һәм хатирәләрне күз алдына китереп бастырырга ярдәм итә.

Вакыт һәм урын төшенчәләре белән турыдан-туры тыгыз бәйләнгән ретроспекция һәм проспекция дә текстның үстерелешендә мөһим роль уйный. Ретроспекция – укучыны алдагы эчтәлеккә юнәлтә торган, текстагы тел материалын берләштергән грамматик категория: укучы хәтерендә элек әйтелгәннәрне торгызу һәм аларны контекстта уйлап карау өчен мөмкинлек бирү. Проспекциядә сөйләнә торган вакыйгаларның киләчәккә таба юнәлтелгән булуы шарт.

Текстның бай сүзлек хәзинәсендә төрле-төрле мәгънә төсмерләре бирүдә, стиль үзенчәлекләре барлыкка китерүдә фразеологизмнар, синонимнар, тел-сурәтләү чаралары, чагыштырулы төзелмәләр, сүзтезмәләр синонимлыгы, актив һәм пассив төзелмәләр, тиңдәш кисәкләрнең стилистик кулланылышы һәм аларның тоткан урыны гаять зур, абзацара бәйләнешләр, текстның хисси-халәт кырын билгеләү бик мөһим. Алар сөйләмнең төгәллегенә, нәфислегенә һәм сәнгатьчә яңгырашына ирешүдә әһәмиятле чара булып торалар, текстта эчтәлекне төгәл һәм дөрес чагылдыруга ярдәм итәләр, телдән файдалану мөмкинлекләрен арттыралар.

## ӘДӘБИЯТ


1. Бабенко Л. Г., Казарин Ю. В. Лингвистический анализ художественного текста. Теория и практика: Учебник практикум / Л. Г. Бабенко, Ю. В. Казарин. – М.: Флинта: Наука, 2003. – 496 с.

2. Бәширова И. Б. Сәнгатьле чәчмә әсәрләр теле: Татар прозасында хикәяләү стильләренең үсеше һәм аның әсәр теленә тәэсире / И.Б. Бәширова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. – 96 б.

3. Гальперин И. Р. Текст как объект лингвистического исследования / И. Р. Гальперин. – М.: Наука, 1981. – 140 с.

4. Низамов И. М. Уем тел очында / И. М. Низамов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – 288 б.

5. Новиков Л. А. Филологический анализ художественного текста. – М.: Академия, 2003. – 272 б.

6. Поварисов С. Ш. Тел – күңелнең көзгесе / С. Ш. Поварисов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – 160 б.

7. Сафиуллина Ф. С. Текст төзелеше: Югары уку йортлары өчен дәреслек-кулланма / Ф. С. Сафиуллина. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1993. – 263 б.

8. Солганик Г. Я. Синтаксическая стилистика: Сложное синтаксическое целое / Г. Я. Солганик. – М.: Высш. школа, 2003. – 214 с.

9. Хаков В. Х. Татар әдәби теле (стилистика) / В. Х. Хаков. – Казан: Татар. кит. нәшр, 1999. – 304 б.

10. Шанский Н. М. Фразеология современного русского языка / Н. М. Шанский. – М.: Высшая школа, 1985. – 160 с.

11. Шәкүрова М. М. Лингвистик анализ / М. М. Шәкүрова, М. Р. Шәехов // Мәгариф. – 2008. – № 10. – Б. 82 – 87

12. Шәкүрова М. Әдәби әсәрне өйрәнүгә комплексы якын килү (Ф. Әмирханның «Кадерле минутлар» хикәясе мисалында) / М. Шәкүрова, М. Барабанова // Милли мәдәният. – 2010. – № 21. – Б. 43 – 47

13. Шәкүрова М. М., Гыйниятуллина Л. М. Әдәби әсәргә лингвистик анализ ясау (татар әдәбияты һәм фольклоры мисалында) / М. М. Шәкүрова, Л. М. Гыйниятуллина. – Казан, 2018. – 147 б.

## НРАВСТВЕННО-ЭКОЛОГИЧЕСКОЕ ВОСПИТАНИЕ НА УРОКАХ ЛИТЕРАТУРЫ

**Р. Ф. Давлетова**
*МБОУ «Тойгильдинская основная общеобразовательная школа» Муслюмовского муниципального района Республики Татарстан, Россия*
rushaniya44@mail.ru

## INDIVIDUAL-ECOLOGICAL REVIEW ON LITERATURE LESSONS

**R. F. Davletova**
*Muslyumovsky Municipal District Municipal Budget General Education Institution «Toigelde Basic Secondary School», Russia*
rushaniya44@mail.ru

В статье проводится сравнительный анализ системы образования в стране, развитие и традиции народной педагогики.
**Ключевые слова:** народная педагогика.

The article gives comparative analysis of the education system in the country, its development and the tradition of folk pedagogy.
**Key words:** folk pedagogy.

## ӘДӘБИЯТ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ӘХЛАКЫЙ-ЭКОЛОГИК ТӘРБИЯ БИРҮ

**Р. Ф. Дәүләтова**

Заман алга бара дип чын күңелдән сөенәбез. Ләкин тирә-як мохит моңардан зыян гына күрүен онытып җибәрмәскә тиешбез. Кешелекнең табигать белән бәйләнеше – хәзерге заманның актуаль мәсьәләләреннән санала. Промышленностьнең үсүе табигатьнең тигезлеген югалтуга китерде: сулыкларның, һава, җир өслегенең пычрануы кеше сәламәтлегенә куркыныч яный, бигрәк тә балаларга. Күп кешеләрдә экологик белемнәр һәм экологик культура җитеп бетми. Һичшиксез, бу укыту-тәрбия эшенең җитешле дәрәҗәдә булмавы – илебез халкына, табигатькә карата дөрес караш формалаштыра белмәү нәтиҗәсе.

Әхлакый-экологик белем һәм тәрбия бирүдә әдәби әсәрләрнең әһәмияте зур. Язучыларыбыз, беренчеләрдән булып, табигатьне саклау турында чаң сукты. Әйләнә-тирә дөньяны, кеше сәламәтлеген, аның рухын, телен саклау аларны иң борчыган һәм дулкынландырган проблемага әйләнде. Нәфис сүз, сәнгать чаралары ярдәмендә кешедә югалып бара торган иң изге әхлакый-рухи кыйммәтләрне торгызу, Җир-анага игелек, хөрмәт хисләрен уяту, кешелекнең экологик һәлакәт каршында торуын да искәртергә кирәк иде.

Дәреслекләрнең эчтәлегенә игътибар итсәк, әсәрләрдә экологик тәрбия бирү яктыртыла. Мәсәлән, Әхмәт Халидовның «Урман сакчылары», Фирдәвес Гарипованың «Су кадере», Клара Булатованың «Ана сүзләре», Сибгат Хәкимнең «Яшь юкә», Габдулла Тукайның «Бала белән күбәләк», «Яшь агач» укучыларда экология проблемасы турында белү генә түгел, аны чишү юлларын эзләү теләге уята. М. Кәрим «Озын-озак балачак», Г. Сабитов «Ярсулы яз», Г. Бәширов «Туган ягым – яшел бишек», Ә. Баянов «Сәяхәтнамә» әсәрләрендә кеше һәм табигать мөнәсәбәтләре, табигатьне саклау мәсьәләләре үткен итеп куела.

Г. Тукай күп кенә шигырьләрендә җәнлекләрне, кошларны, бөҗәкләрне яратырга, аларга мәрхәмәтле, шәфкатьле булырга өнди, үзенең шигъри бизәкләре белән табигатьнең гүзәллеген ача. Табигатьне саклау – милләтебезне, туган телебезне, гореф-гадәтләрне, рухи һәм тарихи байлыкларны саклау белән тыгыз бәйләнгән. Чөнки туган тел, әдәби һәм тарихи мирас газиз җиребездә барлыкка килгән. Шуңа күрә балаларны татар халкының рухи тамырлары, ерак бабаларыбызның яшәү рәвеше, һөнәрләре белән таныштыру, аларда милли горурлык тәрбияләү мөһим. Табигатьнең матурлыгын, серлелеген Тукаебыз үзенең җаны, саф күңеле, йөрәк җылысы салынган шигъри юллары белән укучы күңеленә кертүче, ныгытучы, мәңгеләштерүче.

Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;
Аулыбызның ямен, су тәмен беләм,
Шуңа күрә сөям җаным-тәнем белән.

(Г. Тукай. «Туган авыл») [4: 64]

«Су анасы», «Шүрәле» әсәрләрендә баланы гаҗәеп табигать дөньясына алып керә. Матурлык дөньясын тою балаларда гүзәллеккә омтылу хисе уята. Бу әсәрләр аша балаларда кешегә, аның акылына, зирәклегенә, хәйлә катнаш тапкырлыгына, кыюлыгына, батырлыгына соклану хисе уяна. Ә хисләр, хыяллар дөньяны танып белүнең башлангычы ул.

Урман татар халкының тормышында да зур урын алып тора. Тукай урманнарның гүзәллегенә соклана. Ул яхшы белә: урман саф һава чыганагы да, бетмәс-төкәнмәс байлык та. Кырлай урманнарының матурлыгы, сихри тылсымы аның күңелендә мәңгелеккә уелып калган. Шагыйрь үзенең «Исемдә калганнар» әсәрендә «Бу Кырлай авылы минем дөньяга иң элек күзем ачылган урыным», – дип юкка гына язмагандыр. Шагыйрь фикеренчә, урман – саулык, байлык сандыгы.

Табигать турындагы белемнәр халык авыз иҗатында да киң чагылыш тапкан, әкият, мәкаль, әйтем, сынамыш һәм табышмакларда күп кенә экологик мәгълүмат бирелгән. Бу чыганакның төп өстенлеге шунда: белемнәр балаларга мавыктыргыч рәвештә җиткерелә.

Дәресләрдә халык авыз иҗатының бар төре булган табышмакларны еш кулланабыз. Аларның күбесе еш очрый торган табигать күренешләренә багышланган «Ак яулыгым төшеп калды...», яки табигый җисемнәргә хас үзенчәлекләр турында «Җәен соры, кышын ак, аңа шулай яхшырак». Табышмаклар балаларда зирәклек, күзәтүчәнлек кебек сыйфатлар тәрбияли, дәресне җанландыра, укучыларның активлыгын күтәрергә ярдәм итә. Табышмакларны теләсә кайсы дәреснең уңайлы моментын табып файдаланырга мөмкин. Аларны кулланып кроссвордлар, төзергә була.

Халык авыз иҗатының икенче бер төре – мәкаль. Кыска, ләкин хикмәтле сүзләр белән халык бик тирән мәгънәле фикерләрне бер буыннан икенче буынга җиткергән; шуңа күрә күпчелек аны «ата-баба сүзе» дип йөрткән. Мәкальләр арасында табигатькә багышланган һәм экологик тәрбияне күз алдында тотканнарын сайлап, дәресләрдә куллану, аларның асылын укучыларга җиткерү дәреснең нәтиҗәлелеген күтәрә, аларга игелекле эшләр башкарырга омтылыш уята. Мәсәлән, «Суга сусаган – чишмә әрчегән», «Агач утырткан – ага булган», «Кул пычранса, су белән юарсың?» һәм башка шундый мәкальләрдән файдаланабыз.

«Кешенең борынгыдан килгән гуманлы карашларына, гореф-гадәтләренә, еллар буена сыналып килгән тормыш тәҗрибәсенә хилаф килердәй, аны рухи,

әхлакый яктан рәнжетердәй башабаштаклык ахыр чиктә табигатькә дә зарар булып төшә», – дип язган халык язучысы Г. Бәширов. [2: 45] Димәк, яшь буында табигатькә сакчыл караш тәрбияләүне кешедә гасырлар буе тупланган, аңа хезмәт аша сеңгән гомумкешелек әхлак сыйфатларын, тирә-юньгә кешенең элеккеге мөнәсәбәтен эзләү белән тыгыз бәйләргә кирәк.

ӘДӘБИЯТ


1. Гафаров И. Ә. Туган як мирасы. – Казан, 2004.
2. Галимуллин Ф. Эзләнү вакыты. – Казан: Мәгариф нәшрияты, 2005.
3. Заһидуллина Д. Ф. Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы: метод. кулланма. – Казан: Мәгариф, 2000.
4. Тукай Г. Сайланма әсәрләр. Шагыйрь турында истәлекләр. – Казан: Татарстан Республикасы «Хәтер» нәшрияты (ТаРИХ), 2002. – 511 б.
5. Хаков В. Х. Татар әдәби теле тарихы. – Казан, КДУ нәшрияты, 1993.
6. http://www.docme.ru/doc/1062018/gimnaziya-N-155.-sbornik---2015.poslednij


## ИННОВАЦИИ И МЕТОДЫ В ПРЕПОДАВАНИИ РОДНОГО (ТАТАРСКОГО) ЯЗЫКА


**И. Г. Давлетшина**

*Государственное автономное общеобразовательное учреждение «Полилингвальный комплекс «Адымнар – путь к знаниям и согласию» г. Казани, Россия*
ilmira2504@yandex.ru


## INNOVATIONS AND METHODS IN TEACHING NATIVE (TATAR) LANGUAGE


**I. G. Davletshina**

*State autonomous educational institution «Multilingual complex «Adymnar – the way to knowledge and consent» of Kazan, Russia*
ilmira2504@yandex.ru



Хорошее владение двумя государственными языками как средством общения – веление сегодняшнего дня: оно необходимо для успешной учебы, интеллектуального и нравственного становления детей раннего возраста. Бесспорным является положительное влияние двуязычия на развитие памяти, умение понимать, анализировать и обсуждать явления языка. Обучение детей татарскому языку в начальной школе – одна из самых сложных методических задач. Применение инновационных компьютерных технологий позволяет значительно сократить время на развитие языковых и речевых средств, коммуникативных навыков, словесно-логического мышления. Компьютер помогает повысить уровень заинтересованности детей в изучении татарского языка, обеспечивая наглядность, контроль, большой объем информации, являясь стимулом в обучении. Использование нестандартных методических приемов способствуют развитию любознательности, активности и творческих способностей каждого ребенка.


**Ключевые слова:** Туган (татар) теле, татар теле үстерү мохите булдыру, инновацион технологияләр кулану, индивидуаль эш башкару, кызыксындыру системасын куллану, балаларны үз эшчәнлекләрендә уңышларга җәлеп итү.



Good command of two state languages as a means of communication is the imperative of today: it’s necessary for successful study, intellectual and moral development of young children. The positive influence of bilingualism on the development of

memory, the ability to understand, analyze and discuss the phenomena of language is indisputable. Teaching children the Tatar language in primary school is one of the most difficult methodological tasks. The use of innovative computer technologies can significantly reduce the time for the development of language and speech means, communication skills, verbal and logical thinking. The computer helps to increase the level of interest of children in learning the Tatar language, providing visibility, control, a large amount of information, being a stimulus in learning. The use of non-standard teaching methods contributes to the development of curiosity, activity and creativity of each child.

**Key words:** Creating a native (Tatar) language, creating an environment for the development of the Tatar language, using innovative technologies, performing individual work, using a system of incentives, attracting children to success in their activities.

## «ТУГАН (ТАТАР) ТЕЛ»НЕ УКЫТУДА ИННОВАЦИОН ТЕХНОЛОГИЯЛӘР

**И. Г. Дәүләтшина**

Мәгариф системасында иң актуаль проблемаларның берсе – икенче телне үзләштерү мәсьәләсе. Бүгенге көндә Республикада телне өйрәнүдә яңа вәзгыять шартларында шәхес буларак формалашу ике милли мәдәният, гореф-гадәтләр, сөйләм һәм этик нормалар йогынтысында башкарыла.

Аралашу чарасы буларак, ике дәүләт телен дә яхшы белү бүгенге көннең фәрманы булып тора. Ике дәүләт телен аңлап белү, уңышлы укытуның зарурлыгы кече яшьтәге балаларның интеллектуаль һәм әхлакый үсеше өчен кирәк. Икетеллелекнең хәтер үсешенә уңай йогынтысы, тел күренешләрен аңлый белү, анализлый һәм тикшерә белү бәхәссез булып тора. Психологлар тарафыннан икенче телгә кече яшьтән өйрәтә башлау иң уңай вакыт дип танылды. Кече яшьтәге балаларга барысы да кызык, аларны теләсә нинди уенга җәлеп итәргә, гадәти курчак яки йомшак аю күрсәтеп кызыксындырырга мөмкин. Балалар үзләре, аларның якыннары, дуслары һәм танышлары сөйләшә торган телне өйрәнүләре, белүләре һәм хөрмәт итүләре хәзерге көндә бик мөһим.

Балаларны башлангыч мәктәптә татар теленә өйрәтү – иң катлаулы методик бурычларның берсе. Балаларны татар теленә өйрәтүдә, беренчедән, аларда туган якка мәхәббәт, табигать һәм аңа карата сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү мөһим. Икенчедән, шәһәрнең, республиканың, илнең тарихи үткәненә кызыксыну тудыру. Шулай ук патриотик хисләр, үткәнгә һәм бүгенгегә кече Ватанга карата горурлык һәм хөрмәт тәрбияләү, татар халкының кызыклы тарихи вакыйгалары, хезмәт эшчәнлеге, мәдәнияте, көнкүреше һәм бәйрәмнәре белән таныштыру.

Бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән тел – ул халкыбызның зирәклеген, гореф-гадәтләрен, рухи байлыгын меңнәрчә еллар буе үз эченә туплаган кыйммәтле хәзинә. Һәр халык өчен туган теле – иң кадерле һәм иң изге байлык. Бу байлыкны саклап калу һәм үз балаларыбызга тапшыру – һәркемнең бурычы. Укытучылар һәм ата-аналарның тырышлыгы балансланган вакытта гына яхшы нәтиҗәләргә ирешеп була.

Әмма безгә ата-аналарның татар теленең әһәмиятен (өстәвенә, рус телле генә түгел, татар милләтеннән булган ата-аналар да), Татарстан Республикасының булачак гражданнары – кече яшьтәге балаларның әхлакый-патриотик хисләрен тәрбияләүдә туган проблеманы аңлап бетермәү белән очрашырга туры килде. Үткәрелгән анкеталаштырудан соң, барлык ата-аналар да Татар-

стан Республикасында ике тел барлыгын белмәүләре, балаларны татар теленә өйрәтүгә тәнкыйди караулары турында ачыкланды, әмма бөтен ата-аналар да балаларының башка милләт кешеләре белән тигез итеп аралашырга, туган якны хөрмәт итәргә тиешлеге белән килештеләр. Шулай ук рус телле укытучыларның татар телен белмәү проблемасы да барлыкка килде.

Уку-укыту методик комплектларын гамәлгә кертүнең максаты балаларны Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә ирекле аралашуга өйрәтергә юнәлтелгән. Билингвизм (икетеллелек) – ике телне бер үк вакытта ирекле белү һәм сөйләм аралашуы шартларына бәйле рәвештә аларны бертигез куллану.

Башлангыч мәктәптә белем һәм тәрбия бирү буенча федераль дәүләт белем бирү стандартларына таянып, без – укытучылар, безнең мәктәптә, ата-аналар белән эшләүнең актив формаларын кулланабыз. Аларны инновацион эшчәнлек белән таныштыру максатында, лекторияләр, консультацияләр, мастер-класслар, презентацияләр, дискуссияләр, ата-аналар белән очрашулар аша заманча мәгълүмат технологияләре кулланып, актив эш алып барабыз. Ата-аналарга үз балаларына татар теле лексикасын үзләштерүдә һәм сөйләм материалын кесә сүзлекләре, карточкалар аша беркетүдә ярдәм итәргә, «Татарча сөйләшәбез», «Сәлам» проектлары диалоглары аша, «Карале һәм истә калдыр» дискларын тыңлап өйрәтүне оештыру мөһим [3: 84].

Алдан ук ата-аналар белән эшләү безнең полилингваль комплексның икетеллелек үсешенә ярдәм итте, бүгенге көндә ата-аналар татар телен икенче тел буларак өйрәтүне уңай кабул итә, балаларның уңышларын күзәтеп шатлана.

Һәр дәрестән соң балалар белән эш дәверендә алган белемнәрне инновацион ысуллар һәм технологияләр кулланып, уен һәм белем бирү эшчәнлеген кулланып ныгытабыз.

Инновацион компьютер технологияләрен куллану тел һәм сөйләм чараларын, коммуникатив күнекмәләрне, логик фикерләүне үстерүгә вакытны шактый киметергә мөмкинлек бирә. Компьютер балаларның татар телен өйрәнүдә кызыксыну дәрәҗәсен арттырырга ярдәм итә, күрсәтмәлелекне, контрольне җиңеләйтә, белем бирүдә стимул булып тора. Компьютер технологияләрен үзләштерү укытуның уңай мотивациясен көчәйтергә, танып белү эшчәнлеген активлаштырырга, баланың да, укытучының да иҗади эшчәнлеген көчәйтергә мөмкинлек бирә. Компьютер мультфильмнар карауны оештырырга ярдәм итә. Компьютер ярдәмендә слайдлар һәм компьютер дидактик уеннары кулланып, үтелгән материалны беркетәбез. Аудиоплеер ярдәмендә балалар аудиоязма тыңлау һәм кушылып җырлау мөмкинлегенә ия.

Уен методикалары, эшчәнлек төрләрен алыштыру, күрсәтмәлелекнең төрле төрләрен куллану, балаларда татар теле белән кызыксынуны сакларга ярдәм итә, ә моннан башка башлангыч этапта чит телгә өйрәтү мөмкин түгел [1: 58].

Баланың бармаклары һәм кул чуклары хәрәкәте аң үсешенә аеруча көчле йогынты ясый. Кешенең баш мие үсешенә мануал (кул) хәрәкәтләренең тәэсире күптәннән билгеле, ә татар телендә бармак гимнастикасы куллану балалар өчен үзенчәлекле уенга әверелә һәм алар белән сүз материалын истә калдыруга уңай йогынты ясый.

Баланың тавыш һәм сүзләрне дөрес әйтүе бик мөһим. Моңа артикуляция методы ярдәм итә.

Татар телендә сөйләшергә өйрәтү – сүзләрне һәм гыйбәрәләрне өйрәнүне генә түгел, башка мәдәни киңлектә яшәүне дә аңлата. Башка телне өйрәнү башка мәдәният, башка халыкның бәйрәмнәре һәм йолалары, әкиятләре, балалар уеннары һәм фольклоры белән танышуны күздә тота.

Татар теленә өйрәтүдә тел тирәлеге булдыруда укытучының роле мөһим.

Милли көнкүреш әйберләре, татар шагыйрьләре һәм язучылары иҗаты белән танышу буенча этнографик почмак, дидактик уеннар, альбомнар, «Без татар телен өйрәнәбез» дигән күчмә папкалар урнаштырылган, шул папкаларга татар теле дәресләрендә өйрәнелә торган материал тупланган.

Укучыларны туган шәһәрләре, Идел буе халыклары мәдәнияте һәм көнкүреше белән таныштыруда системалы һәм максатчан эш алып барыла. Толерантлык тәрбияләүгә «Туган тел көне»ндә оештырылган чаралар ярдәм итә. Татарстан территориясендә яшәүче барлык халыкларның туган ягы, уеннары һәм традицияләре белән танышалар. Укучылар белән бергә туган якны өйрәнү музеена йөрибез, шәһәр буйлап экскурсияләргә барабыз.

Сәламәтлек саклау технологияләрен уку процессына кертү балаларның сәламәтлегендә уңай үзгәрешләргә ирешергә мөмкинлек бирә. Физкультминутлыклар, татар халык уеннарын оештыру балаларның сәламәтлеген ныгытуга ярдәм итә. Укучыларга шулай ук рифмалы, хәрәкәтле җырлар җырлау кызыклы.

Укучыларның белемнәрен ныгыту процессын аңлаешлы, мавыктыргыч һәм кызыклы итү өчен тавыш ассоциацияләре методына өстенлек бирәм. Методның асылы – туган телнең яңгыравыклы сүзләрен истә калган чит телдәге сүзгә тәңгәл сайлап алудан гыйбарәт. Мондый тавыш ассоциацияләре икенче телнең сүзләрен истә калдыруны җиңеләйтә. Бу эштә Р. К. Шаехованың «Раз-словечко, два-словечко» ярдәмлеген кулланам [4: 96].

Стандарт булмаган методик алымнарны куллану һәр баланың кызыксынучанлыгын, активлыгын һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә ярдәм итә.

Таныш әсәрләр буенча театральләштерелгән уеннар телне актив файдалану этабында әһәмиятле, балаларга рәсемнәрне («Чәй эчү», «Хайваннар дәрестә», «Гаилә кич белән» һәм башкалар) җанландырырга тәкъдим ителә – диалог уйлап табарга һәм аны курчак театрының теләсә кайсы төрендә «уйнарга» тәкъдим ителә [2: 60].

Театральләштерелгән уенда балалар шул процесстан ләззәт ала. Шуңа күрә балалар бу уенда һәрчак катнаша. Димәк, яхшы нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин. Белем дәрәҗәсе диагностикасы балаларның татар теле материалын яхшы үзләштерүләрен, куелган бурычларның уңышлы үтәлүен күрсәтә.

Инновацион технологияләр кулланып эшләү рус телле балаларны татар теленә өйрәтүдә уңышка ирешүдә бер яктан татар телен үстерү мохите булдыру, икенче яктан балага шәхси ориентлаштырылган якын килү, кызыксындыру системасын куллану, балаларны үз эшчәнлекләрендә уңышларга җәлеп итү мөмкинлеге бирә.

## ӘДӘБИЯТ

1. Исаева Р. С. Играя изучаем татарский язык. Методическое пособие. – Набережные Челны, 2010. – 58 с.

2. Муяссарова И. Х. Отдохнем чуть-чуть: Физкультминутки и сюжетные игры (на татарском языке). – Казань, 1998. – 60 с.

3. Программа по обучению детей татарскому языку. – Казань: Школа, 2004. – 84 с.

4. Шаехова Р. К. Раз словечко, два словечко…: занимательное обучение татарскому языку. – Казань: Татарское республиканское издательство «ХЭТЕР», 2011. – 96 с.

# РЕЦЕНЗИРОВАНИЕ ТВОРЧЕСКИХ РАБОТ УЧАЩИХСЯ КАК МЕТОД РАЗВИТИЯ УСТНОЙ РЕЧИ

**З. С. Данилова, Р. И. Ашрафуллина**
*«Полилингвальный образовательный комплекс «Адымнар – Алабуга», г. Елабуга, Россия; Муниципальная общеобразовательная средняя школа № 10, г. Елабуга, Россия*
1804000265@mail.ru, rozaliya_nais@mail.ru

# REVIWINQ STUENTS ‘ CREATIVE WORKS AS A METOD OF DEVELOPINQ ORAL SPEECH

**Z.S. Danilova, R. I. Ashrafullina**
*«Polylingual educational complex «Adimar – Alabuga», Elabuga, Russia; Municipal secondary school N 10, Elabuga, Russia*
1804000265@mail.ru, rozaliya_nais@mail.ru

Данная статья посвящена использованию метода рецензирования в обучении письменной речи школьников среднего звена общеобразовательной школы. В ней авторы разрабатывают этапы организации работы, направленной на развитие их умений письменной речи на основе метода рецензирования.
**Ключевые слова**: метод, рецензирование, письменная речь, аргументировать свои мысли, синонимические конструкции.

This article is devoted to the use of the review method in teaching writing to secondary school students. In it, the authors develop the stages of organizing work aimed at developing their writing skills based on the review method.
**Key words:** method, review, written speech, argue your thoughts, synonymous constructions.

# СӨЙЛӘМ ТЕЛЕН ҮСТЕРҮ АЛЫМЫ БУЛАРАК УКУЧЫЛАРНЫҢ ҮЗАРА ИҖАДИ ЭШЛӘРЕН РЕЦЕНЗИЯЛӘҮЛӘРЕ

**З. С. Данилова, Р. И. Ашрафуллина**

Мәктәп шартларында рецензия термины түбәндәгечә аңлатыла: «фәнни хезмәтне, әдәби әсәрне, спектакль, концерт, кинофильмны тикшереп, аңа язма рәвештә бирелгән бәяләмә» [1: 142]. Мәктәп практикасында гадәттә әдәби әсәргә рецензия язу таралыш алган, мондый эш – сочинение-рецензия исеме белән аталып йөртелә. Башка сәнгать әсәрләренә (нәфис фильм, спектакль) рецензияләр тәнкыйтьнең бер төре буларак урын алсалар да, укучылар белән эшләгәндә кулланылмыйлар диярлек. Традицион булмаган рецензияләр рәтендә укучыларның үзара иҗади эшләренә язылган бәяләмәләр дә урын ала. Укучыларның иҗади эшләре дигәндә, без нәрсәләрне күзаллыйбыз соң? Әлбәттә, укучының үзе язган, оригинальлеккә дәгъва итә алган һәр эше дә иҗади булып тора. Бу очракта без укылган әсәр буенча язылган сочинениене генә күзалламыйбыз. Балаларның иҗади үсешенә, креатив фикер йөртүен үстерүгә игътибар биргән укытучы җитәкчелеге, кул астында укучылар эссе, шигырь, сценарий, отзыв, очерк, юлъязма һәм башка бик күп жанрларда үзләрен сынап карыйлар.

Әйтергә кирәк, укучыларның иҗади эшләренә дәреслек авторлары методист-галимнәр да игътибар юнәлтәләр. Мәсәлән, алар тарафыннан тәкъдим ителгән биремнәр арасында түбәндәгеләр бар:

– «Туган авылым», «Туган төбәгем» дигән темаларга иҗади эш башкарыгыз (хикәя, шигырь языгыз, рәсем ясагыз) [4: 109];

– кечкенә генә берәр әсәрне рус теленнән татарчага тәрҗемә итәргә (мәсәлән, А. Чехов хикәяләрен) [4: 109];

– әсәргә нигезләнеп (сүз Ф. Әмирханның «Фәтхулла хәзрәт» повесте турында бара), медицина фәне белән бәйләп, кечкенә фантастик хикәя языгыз [1: 72] һ.б.

Шушы биремнәрне өй эше буларак эшләргә тәкъдим итәргә һәм алдагы дәресне яки дәреснең бер өлешен иҗади эшләрне үзара рецензияләүгә багышларга була. Әлеге рецензияләрнең эчтәлеге күп кенә дәрәҗәдә әдәби әсәргә язылган рецензиянеке белән туры килә. Без әлеге теманы тәфсилле өйрәнгән галимә О. А. Сальникова тәкъдим иткән план буенча эш алып баруны максатка ярашлы дип саныйбыз [2: 87]. Укучыларга эшне түбәндәге план буенча язарга тәкъдим итәбез:

1. Әсәргә характеристика-бәя бирергә.
2. Эчтәлек һәм форманы анализларга.
3. Мөмкин булган очракта, әсәрнең автор иҗатында тоткан урынын билгеләргә.

Әлбәттә, укучы иптәшенең шигыренә (хикәя, эссега) беренче мәртәбә рецензия яза икән, әлеге пункт төшереп калдырыла, әмма эш ел ахырында башкарылып, укучы сыйныфташының берничә иҗади эше белән инде таныш булса, рецензия эчтәлегендә әлеге фикерләр кыйммәтле урын алачак.

4. Әсәргә укучы игътибарын тарту һәм рекомендацияләр бирү.

Л. М. Фридман, И. Ю. Кулагина үзара рецензияләр язу нәтиҗәсендә укучыларның үз эшләренә карата да таләпчәнлек күрсәтә башлаулары турында фикер әйтелә [3: 261]. Безнең фикеребезчә, үзара рецензияләүнең тагын бер мөһим ягы – укучыларның белем һәм тел күнекмәләрен үстерүдә зур мөмкинлекләргә ия булуы. Бу ни рәвешле ачыла соң?

Укучылар үзара иҗади эшләрне рецензияләгәндә, тәнкыйть жанрына хас төрле синонимик конструкцияләрне кулланырга өйрәнәләр. Рецензия язу кебек эшләр даими башкарылганда, укучыларның телдән һәм язма сөйләме мондый модельләр белән шактый байый, алар әсәрне анализлау, сочинение язганда, фәнни конференция өчен мәкалә әзерләгәндә дә иркен куллана башлыйлар. Шундый синонимик конструкцияләрнең кайберләрен таблицада теркәп китик.

| Анализлана торган объект | Кулланыла торган синонимик конструкцияләр |
|---|---|
| Автор | – автор гаҗәеп оста (яхшы) психолог (шагыйрь, әдип) кына түгел, ул әле...<br>– аның әсәрләре (хикәяләре, иҗат җимешләре) .... хисләр (фикерләр, уйлар, омтылышлар) уята |
| Сюжет | – әлеге хикәя .... турында;<br>– үзәк сюжет линиясе түбәндәгеләрне эченә ала: ...<br>– авторның игътибар үзәгендә... |
| Герой | – хикәяләүче герой укучыларга шуны аңлатырга тырыша:...<br>– әсәр геройлары яшәгән дөнья...<br>– төп герой.... |

| | |
|---|---|
| Әсәрдән алынган тәэсирләр | – әсәрдән алынган беренче тәэсир турында шуны әйтәсем килә: ...<br>– беренче карашка... кебек тоела;<br>– әсәр ... белән таң калдыра |
| Тематика һәм проблематика | – автор кагылган проблемалар киңкырлы;<br>– хикәядә ... проблемасына күп урын бирелә;<br>– проблематиканы ... буларак билгеләргә мөмкин булыр иде. |
| Автор позициясе | – автор .....-ны тәфсилле рәвештә анализлый;<br>– автор көтелмәгән нәтиҗәләр ясый: ...<br>– авторның ... турындагы фикерләре кызыклы;<br>– автор ... дип саный (икәнен раслый, икәненә инана) |
| Әдәби терминологияне кертү | – әсәрнең стилен искә алып, ...<br>– әсәрнең композициясен уңышлы дип бәяләргә була;<br>– геройларның сөйләм характеристикалары игътибарны җәлеп итә |
| Тәнкыйди искәрмәләр | – әлбәттә, авторның барлык фикерләре белән килешеп бетеп булмый;<br>– автордан аермалы буларак, мин ... дип саныйм;<br>– кызганычка каршы, автор үз фикерен мисаллар белән дәлилләмәгән. |

Программа һәм дәреслекләрне күзәтү күрсәткәнчә, укучылар рецензия төшенчәсе белән бишенче сыйныфта ук танышалар һәм дәреслек авторлары тәкъдим иткән биремнәрнең берсе болай яңгырый: «Үз илемдә» шигыренә, үз фикерегезне белдереп, кечкенә генә рецензия языгыз» [4: 105]. Бишенче сыйныф укучысы өчен бу – шактый катлаулы бирем. Эшнең күләмен «кечкенә генә» итеп билгеләү дә кайбер авырлыкларны җиңәргә ярдәм итми, чөнки нинди генә күләмдә язылмасын, эш рецензиягә куела торган таләпләр, аңа хас лексика һәм синтаксик конструкцияләрне кулланып язылырга тиеш була. Әлеге факт әзерлек эшен күпкә алдан башлау әһәмиятен аңларга ярдәм итә. Без мондый әзерлек эшен укучыларның дәрестә бирелгән җавапларны үзара телдән рецензияләүдән башларга тәкъдим итәбез. Әлбәттә, бу рецензияләр кыска булачак, әдәби әсәр, иҗади эшкә карата язылган бәяләмәдән аерылып торачак, әмма укучылар, бердән, фикерләрен дәлилле итеп җиткерергә өйрәнәчәкләр, икенчедән, рецензияләргә хас конструкцияләрне телдән сөйләмнәрендә куллана башлаячаклар. Көтелгән «рецензия»ләр түбәндәгечә әйтелергә мөмкин: «*Миңа (укучының исеме ) җавабы ошады, ул әсәрнең идеясен дөрес аңлаган, фикерен аңлаешлы, төгәл итеп җиткерде. Әмма киләчәктә мин аңа фикерен белдергәндә, әсәрдәге цитаталарга да мөрәҗәгать итәргә киңәш бирер идем*» яисә «*(укучының исеме) җавабы дөрес, әмма ул фикерен аңлаешлы итеп җиткерә алмады, дип саныйм. Җөмләдә сүз тәртибен бутау, монотон тавыш белән сөйләү аның фикерен аңлап бетерергә комачау итә*».

Беренче мәртәбә укучыларның иҗади эшләренә үзара рецензия язу дәресенә укытучы аеруча җитди якын килергә тиеш. Ничек оештырырга соң мондый дәресне? Без түбәндәге алым һәм юлларны тәкъдим итәбез. Мисал өчен, укучыларга Фатих Әмирханның «Фәтхулла хәзрәт» повестенә нигезләнеп, медицина фәне белән бәйләп язылган кечкенә фантастик хикәяләренә бер-

берсенә бәяләмә язарга тәкъдим ителә, ди. Укучыларның хикәяләре бер-берсе белән алышына. Укытучы партадашларга бер-берсенең эшләрен укырга тәкъдим итә, караламаларда балалар хикәядә ошаган һәм ошамаган урыннарны билгеләп баралар, алга таба мондый билгеләр бәяләмә язганда аларга кирәк булачак. Укытучы сорау куя: «Сезгә иптәшегез эшендә нәрсә аеруча ошады?». Укучыларның җаваплары якынча түбәндәгечә формалашырга мөмкин, дип фаразларга була:

*– Миңа Ирекнең хикәясе сюжеты белән ошады, ул кызыклы, көтелмәгән;*

*– Миңа Әлфиянең теле ошый, аның хикәясе җиңел укыла, көчле тәэсир калдыра һ.б.*

*– Минем уйлавымча, Гөлшатның хикәясе исеме белән үк игътибарны җәлеп итә.*

Аңлашылганча, укучылар ирексездән фикерләрне дәлилләргә кирәклеген тоеп эш итәләр: ошаган якны атап кына калмыйлар, фикерләрен аңлаталар да. Турыдан-туры язу эшенә керешкәнче, укучылар түбәндәгеләрне дә искә төшерәләр: рецензия – әсәргә анализ һәм бәя бирүне күздә тота; бирелгән бәя объектив булырга тиеш; бәя әсәргә анализ нигезендә ясала; анализдагы фикерләр цитаталар ярдәмендә раслана.

Эш тәҗрибәсе күрсәткәнчә, укучылар фикерләрен өземтәләр ярдәмендә дәлилләүне еш кына төшереп калдыралар, бу хакта оныталар. Моны кисәтү максаты белән таблица белән эш оештырырга була. О. А. Сальникова таблицаны ике баганадан төзергә тәкъдим итә: 1) «миңа нәрсә ошады»; 2) өземтә [2: 124]. Безнең фикеребезчә, чын тәнкыйтьчеләр кебек үк, укучылар тексттагы кимчелекләргә дә игътибар бирергә тиешләр.

| Миңа нәрсә ошады? | Өземтә | Миңа нәрсә ошамады? | Өземтә |
|---|---|---|---|
| Әсәрнең идеясе | | | . |
| Әсәрнең исеме | | | |
| Метафора, чагыштыруларның мул кулланышы | | | |
| Хикәянең ышандыру көче | | | |

Һәр укучы үзе рецензия язачак әсәр өстендә шундый эш алып барганнан соң, укучылар үзара рецензияләү эшенә керешәләр. Рецензия язылганнан соң, алар тикшерелә. Алдагы дәреснең бер өлеше рецензияләрне редакторлауга багышлана.

Нәтиҗә ясап, шуны ассызыклыйсыбыз килә: укучыларның үзара иҗади эшләрен рецензияләүләре татар теленнән лексик, грамматик күнекмәләрен камилләштерә, сөйләм телен баета, әдәбият буенча белемнәрен гамәлдә кулланырга өйрәтә.

## ӘДӘБИЯТ

1. Мотыйгуллина Ә. Р., Ханнанов Р. Г., Вәлиуллина Р. Һ. Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен өйрәнүче укучылар өчен). 8 нче сыйныф. Ике кисәктә. 2 нче кисәк. – Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. – 143 б.

2. Сальникова О. А. Обучение рецензированию как способу выражения аргументированной оценки: дис. … канд. пед. наук. – М., 1998. – 224 с.

3. Фридман Л. М., Кулагина И. Ю. Психологический справочник учителя. – М.: Просвещение, 1998. – 288 с.
4. Хәсәнова Ф. Ф., Сафиуллина Г. М., Гарифуллина М. Я. Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 5 нче сыйныф. Ике кисәктә. 1 нче кисәк. – Казан: Мәгариф – Вакыт, 2014. – 143 б.

# МЕТОДИКА ФОРМИРОВАНИЯ ПРОФЕССИОНАЛЬНОЙ КОМПЕТЕНТНОСТИ ПЕРЕВОДЧИКА НА ПРИМЕРЕ ПЕРЕВОДОВ ПОЭЗИИ ДЭРДМЕНДА

**И. А. Еникеев**
*Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан, Россия*
eniki07@mail.ru

# METHODOLOGY FOR THE FORMATION OF PROFESSIONAL COMPETENCE OF A TRANSLATOR ON THE EXAAMPLE OF TRANSLATIONS OF DARDMENDS POETRY

**I. A. Enikeev**
*Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, Russia*
eniki07@mail.ru

В статье рассмотрены критерии формирования профессиональной компетентности переводчика. Выводы основаны на теоретических исследованиях ученых и анализе переводов поэзии Дэрдменда. Формирование компетенции имеет множество аспектов. Переводчик должен сочетать культурологическую подготовку с грамотным лингвистическим анализом. Уметь проследить динамику лексических и синтаксических конструкций в творчестве писателя. Определить частоту употребления грамматических форм.
**Ключевые слова:** Перевод, дискурс, компетентность, грамматическая форма, синтаксические конструкции, лексика, аксиология, поэзия, Дэрдменд

The article discusses the criteria for the formation of the professional competence of a translator. The conclusions are based on theoretical studies of scientists and analysis of translations of Dardmends poetry. Competence building has many aspects. The translator must combine culturological training with competent linguistic analysis. To be able to trace the dynamics of lexical and syntactic constructions in the writers work. Determine the frequency of the use of grammatical forms.
**Key words:** translation, discourse, competence, grammatical form, syntactic constructions, axiology, vocabulary, poetry, Dardmend.

Проблема художественного перевода является важным фактором культурной и межъязыковой коммуникации. А в ситуации взаимного перевода флективных и агглютинатативных языков, в частности, русского и татарского, она имеет специфические особенности. В монографии А. В. Штанова «Технология перевода и методика преподавания (компетентностный подход)», посвященной взаимодействию русского и турецкого языков, отмечается, что «перевод, находясь на стыке разных культур, языковых и ассоциативно-понятийных систем, разворачиваясь между представителями разных лингвокультур, а также отражая в себе особенности окказионального и ситуативного характера,

имеет ряд принципиальных характеристик, отличающих его от монолингвальной коммуникативной ситуации» [11: 3–4]. В отечественном переводоведении, начиная с 1974 года широко применяется теория языковых спектров, предложенная М. Д. Литвиновой. Суть этой фундаментальной лингвистической идеи заключается в том, что «каждое явление в конкретном языке (это относится к морфологии, лексике, синтаксису, категориям – части речи, виды сказуемых, наклонения, залоги, приставки) имеет определенную среднестатистическую частоту употребления. Совокупность этих частот и была названа «спектром языка». Каждый автор имеет свой спектр – частоту употребления различных «кирпичиков» текста. Но у авторов обычно нарушен какой-то один регистр» [7: 14]. Например, русские авторы редко употребляют временные предложения и то, в основном, с союзами **когда** и **пока**, а со сложными союзами такие предложениями встречаются в 10 раз реже. Спектр языка писателя «меняется на протяжении жизни: частота определенных лексических единиц и синтаксических конструкций разная в начале и конце творчества. Спектр языка меняется на протяжении истории народа – носителя языка. Имеется однако некоторый «ствол», который сохраняется многие столетия (в английском языке это временные предложения с союзами **befor** и **after**), а для русского языка характерны примыкания и бессоюзия» [7: 14]. В связи с этим «ошибки переводчиков происходят не только от непонимания текста или полноты замысла автора, но еще и от несоблюдения частоты употребления конструкций, существующих как в языке оригинала, так и в языке, на который делается перевод» [7: 13]. Буквализмы при переводе также могут рассматриваться как нарушение русских частотных норм. Поэтому «статистическая характеристика помогает составить наглядную характеристику языка, употребляемого в текстах разных исторических эпох, разных авторов, в разных жанрах и даже в составляющих художественного произведения: экспозиция, описания, диалоги. Этим явлением можно пользоваться, сознательно ориентируясь на исторически отработанную частотность элементов языка и речи в процессе перевода, а также оценивая степень отступления от норм изящной словесности» [7: 15].

В настоящее время в качестве основного метода формирования профессиональной компетентности переводчиков выступает когнитивно-дискурсивный анализ текста. Исследователи С. А. Бойко и С. К. Гураль отмечают, что «в рамках лингвокогнитативного подхода и анализа художественных текстов работа над ними рассматривается как когнитивная и коммуникативная деятельность, раскрывающая особенности его восприятия и интерпретации. Этот подход отвечает задачам и целям современного обучении переводу иноязычных художественных текстов» [1: 61]. Желательно, чтобы переводчик художественной литературы имел дело не с подстрочником, а оригинальным текстом. Только через чтение иноязычных текстов «можно увидеть как передается в дискурсе значение, выявить когнитивные единицы, формирующие концептосферу, а также изучить структуру текста» [1: 64]. Предложенный дискурсивный подход учитывает «экстралингвистические характеристики, обусловливающие конкретный дискурс, а именно: исторические, социальные, культурные, ситуативные характеристики, влияющие на создание перевода» [1: 65]. Помимо этого существует и текстовый подход в обучении переводу, когда для адекватного перевода единиц текста переводчик должен научиться воспринимать текст как целостное смысловое образование, созданное по определенному замыслу автора. В процессе данной методики анализа переводчик учится выявлять компоненты когнитивной и дискурсивной базы иноязычного лингвокультурного сообщества и это помогает выстроить диалог межкультурного

взаимодействия. В результате происходит «формирование навыков освоения эффективных стратегий нахождения вариантов разрешения проблемно-практических ситуаций в последующей переводческой деятельности» [1: 63].

На практике это означает, что переводчик должен знать культуру другого народа, его обычаи и традиции, знать литературный контекст и творчество переводимого писателя. Желательно разбираться в его синтаксических, лексических и грамматических предпочтениях. В сфере практикующих русско-татарских переводчиков ближе всех к осмыслению этих сложных теоретических проблем подошла В. Думаева-Валиева, осуществившая последний по времени перевод поэтического наследия Дэрдменда. В своей статье «Роль русского перевода в освоении творчества Дэрдменда и Тукая» она пишет «что язык наших классиков очень сложен и сильно затрудняет возможность наслаждения высоким строем их мыслей и образов, а иногда нуждается даже в расшифровке» [2: 66]. Она приводит пример из стихотворения Г. Тукая о Пушкине, где выдвигает идею о том, что перводчик должен учитывать все значения татарских слов в процессе перевода, дабы не попасть в конфузную ситуацию: «Это двустишие «Альхам» пока не было объяснено правдоподобно, адекватно теме, ситуации. Сложность коренилась в том, что словарь соотносит **хаинанә** с **хыянәт** (преступление), хотя словарь Махмутова дает второе значение этого слова: вероломный. Перевод стихотворения, на который удалось выйти, возможен только с этим значением. Такой перевод предполагает более глубинный, чем на первый взгляд, смысл этих строк. Нельзя бесцеремонно толковать Пушкина, пусть «альхам» и поддается произвольному толкованию!» [2: 67]. Переводчик пишет, что наличие арабизмов и тюркизмов старотатарского языка «в классической поэзии для современного читателя является, к сожалению, непреодолимым препятствием для восприятия ее несомненных шедевров. На старотатарском языке практически непрочитанными оставались все ранние стихотворения Тукая» [2: 67]. Аутентичный русский перевод должен точно воспроизводить музыку стихотворения, размер, особенности рифмовки, лексику, стиль. Применительно к Дэрдменду она пишет о важности выбора ключевого смысла в тексте, чтобы «прихотливый, архаичный слог этого утонченного ценителя национального языка, истории, родной природы с его щемящей болью за их судьбу не пропал при переводе, но проступил как фотография при проявке» [2: 71]. В процессе переводов Думаева-Валиева открыла для русских читателей полемику между Тукаем и Дэрдмендом в стихотворениях «Стихоплету» и «Поэту», показав, что слово время в строке Тукая являлось намеком на созданную Дэрдмендом газету «Вакыт»: «Как могло случиться, что в строке «Сам все время признаешься ты в бессилии свое» слово «время» вышло в печати в скобках. Именно в скобках, а не в кавычках. И как, при отчетливых, дифференцированных правилах пунктуации, читатели повсюду «угадали» в этом намек на газету «Время»! [5: 8].

Приведенные примеры показывают как важно переводчику знать историко-философский, религиозный и литературный контекст эпохи для точного понимания смысла произведения. Тем не менее переводчик не полностью раскрыл смысл полемики Тукая и Дэрдменда, остановившись на этапе творческих амбиций двух гениев. Противостояние здесь было более глубинным, здесь столкнулись светские, модернистские устремления Тукая и многовековой пласт суфийско-религиозной литературой, стоявшей за Дэрдмендом. Фактор религиозного дискурса практически не учитывается при переводе поэзии Дэрдменда. На этом момент в переводоведениии обратили внимание Литвишко О. М. и Милетова Е. В., которые особо подчеркнули,

что в смысловом поле перевода «религиозный дискурс как русско, так и иноязычный, является аксиологически нагруженным пространством, в пределах которого находят свою практическую реализацию ключевые духовные и нравственные ценности, характерные для каждой религиозной культуры» [8: 69]. Они рассматривают его как совокупность речевых актов реализующих общение коммуникантов и базирующихся на ритуалах и обрядах, нацеленных на приобщение человека к вере в Бога или сверхъестественные силы. Особенно наглядно проблема религиозного дискурса видна на примере переводов стихотворении Дэрдменда «Бүзләрем мана алмадым». Пожалуй это единственное стихотворение Дэрдменда, где переводчики не пришли к смысловому консенсусу. В настоящее время опубликованы пять переводов с разными названиями: «Не отбелил на саван бязи», «Я не соткал белой ткани», «Не перекрасить савана» и одинаковое название у Н. Беляева и Р. Бухараева – «Не сумел я окропить савана». Все переводчики переводят строки «кәфнем бүзләр**ен** мана алмадым» и «бүзләр**ем** мана алмадым» как синонимичные предложения, не обращая внимания на несовпадение окончаний: ен // ем. В данном случае за ним стоят разные грамматические формы слова, а значит разные смыслы. Не принималось во внимание явное нарушение ритма и музыкального строя стиха в последней спорной строфе, которая в отличии от всех остальных состоит из 7 строк. Совершенно не учитывался религиозно-суфийский контекст творчества Дэрдменда, а ведь это стихотворение опубликовано вместе с другим произведением «Наставление» на одной странице журнала «Шура» в 1908 году. И в последнем очень много суфийских образов. Дэрдменд в своем творчестве нередко использовал игру слов и разных смыслов одного слова. Все переводчики ухватились за первое значение «белая ткань». Но у слова **бүз** есть и устаревшие значения: пепельная масть лошади, а также молодой, норовистый [9: 274]. А слово **ману** имеет смыслы: покрывать, хлестать кнутом, бить [10: 18]. Кстати последний смысл актуализирован Дэрдмендом в более позднем стихотворении «Наставлении» (1913), где он сравнивает мир с норовистым конем, которого надо обуздать. Причем это не просто конь, а суфийский символ человеческого эго – нафса, которое надо усмирить.

Помимо суфийского контекста здесь может скрываться полемика, адресованная конкретным лицам, потому что здесь использованы риторические формы самооправдания. Примеры таких стихов имеются в творчестве поэта [3]. Также не учитывается фактор изафет и возможность пропуска или сокращения слов. В любом случае здесь требуется тщательный лингвистический анализ не только этого произведения, но и творчества Дэрдменда в целом. Обращают на себя внимание и совершенно разный контекст переводов Р. Бухараева [4: 68] и Р. Кутуя [6: 86]. Бухараев в свойственной ему манере стилизации и синтеза восточной культуры с западной позиционирует себя как двойника лирического героя Дэрдменда. Поэтому его перевод очень субъективен. Рустем Кутуй наоборот вводит в перевод драматический сюжет исторического масштаба – степь, войны, тюркские цивилизации. Фактически он создает новое произведение на русском языке. Исходя из приведенных примеров и теоретических положений, разрабатываемых в переводоведении, можно сделать выводы о том, что формирование профессиональной компетентности переводчика это сложная проблема, имеющая множество аспектов. Очень важно сочетать культурологическую подготовку с умением грамотного языкового анализа не только предлагаемого текста, но и творчества писателя в целом, умением проследить динамику его лексических и синтаксических конструкций, часто употребляемых грамматических форм.

ЛИТЕРАТУРА

1. Бойко С. А., Гураль С. К. Основные подходы, методы и принципы обучения переводу на основе когнитивно-дискурсивного анализа текста // Вестник ПНИПУ. Проблемы языкознания и педагогики – 2015. – № 1 – С. 61–75.

2. Думаева-Валиева В. С. Роль русского перевода в освоении творчества Дердменда и Тукая // Дәрдемәнд мирасы һәм хәзерге заман. – Казан: ИЯЛИ, 2009. – С. 66–72.

3. Дэрдменд. Стихи. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1970. – 95 с.

4. Дәрдемәнд. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 160 с.

5. Дэрдменд. Стихотворения. – Татар. кн. изд-во, 2009. – 160 с.

6. Дэрдменд: вольный перевод с татарского Рустема Кутуя. // Казань – 1999. – № 12 – С. 85–87.

7. Литвинова М. Д. Методика преподавания художественного перевода в филологических вузах. Критерий оценки переводов // Мосты. Журнал переводчиков – 2019. – № 3 (63) – С. 13–15.

8. Литвишко О. М., Милетова Е. В. Религиозный дискурс как аксиологически маркированное пространство // Вестник ПНИПУ. Проблемы языкознания и педагогики – 2019. – № 2 – С. 65–72.

9. Татарско-русский словарь в двух томах. Том 1. – Казань: Магариф, 2007. – 726 с.

10. Татарско-русский словарь в двух томах. Том 2. – Казань: Магариф, 2007. – 726 с.

11. Штанов А. В. Технология перевода и методика преподавания (компетентностный подход): монография. – М.: МГИМО-Унивеситет, 2011. – 250 с.

## ОБРАЩЕНИЕ КАК САМОСТОЯТЕЛЬНЫЙ КОМПОНЕНТ ПРЕДЛОЖЕНИЯ

**А. М. Зайнуллина**

*МБОУ «Гимназия № 36», Казань, Россия*

Aygul_zaynull@mail.ru

## APPEAL AS AN INDEPENDENT COMPONENT OF THE SENTENCE

**A.M. Zaynullina**

*Municipal budgetary educational institution «Gymnasium № 36», Kazan, Russia*

Aygul_zaynull@mail.ru

Обращение – самый массовый и самый яркий этикетный признак. И в русском, и в татарском языках обращение может повторяться. Причем в обоих языках обращение произносится с особо сильной интонацией, когда оно занимает начальное положение в предложении. Как в русском, так и в татарском языках обращения служат или для привлечения внимания слушателя, собеседника, или употребляются только для модальных целей. Таким образом, обращения русского и татарского языков по значению и по структурным показателям, средствам выражения во многом одинаковы.

**Ключевые слова:** обращение русского и татарского языков, речевой этикет, татарская речь.

Address is the most popular and the most striking feature of etiquette. In Russian and Tatar languages address can be repeated. And in both languages address is pronounced with an especially high tone? when it takes the initial position in the sentence. In Russian and Tatar languages addresses serve to attract the attention of the listener or a company, or are used only for modal purposes. Thus addresses of Russian and Tatar languages by meaning, by structural indicators, by means of expression are largely the same.

**Key words:** Russian and Tatar languages addresses, speech etiquette, tatar speech.

Немаловажных целей в общении человеку помогает достичь речевой этикет. Под речевым этикетом следует понимать выработанное обществом правила речевого поведения, обязательные для членов общества, национально специфичные, устойчиво закрепленные в речевых формулах, но в то же время исторически изменчивые.

Правила речевого поведения регулируются речевым этикетом – сложившейся в языке и речи системой устойчивых выражений, применяемых в ситуациях установления и поддержание контакта. Это ситуация обращения, приветствие, прощание, извинения, благодарности, поздравления, пожелания, сочувствие и соболезнования, одобрения и комплемента, приглашения, предложения, просьбы совета и многое другое. Речевой этикет охватывает собой все, что выражает доброжелательное отношение к собеседнику, что может создать благоприятный климат общения.

Обращение – это название лица, предмета или явления к которому обращена речь говорящего. В обращении, во-первых, устанавливается адресат речи, во-вторых, при помощи интонации – отношении говорящего ко всему высказыванию.

И в русском, и в татарском языках обращения бывают нераспространенные и распространенные. Нераспространенные обращения в обоих языках выражаются формами именительного падежа существительного, а также субстантивированных прилагательных, причастий, местоимений, значительно реже – порядкового числительного и очень редко – количественного числительного.

Обращение в обоих языках может терять свое основное лексическое значение. Например, в русском языке в обращении к женщине (в просторечии) может употребляться слово брат, в татарском языке – малай («мальчик»). А также, например, в татарском – в обращении к чужому человеку – «туган», «агай-эне» и т.п.

Обращения в обоих языках могут состоять из нескольких следующих друг за другом слов, соединенных между собой способом сочинения. И в русском, и в татарском языках обращение может повторяться. В рамках предложения обращение в обоих языках может занимать любое место и всегда обособляется. Причем в обоих языках обращение произносится с особо сильной интонацией, когда оно занимает начальное положение в предложении.

Как в русском, так и в татарском языках обращения служат или для привлечения внимания слушателя, собеседника, или употребляются только для модальных целей. В первом случае немногие из них могут употребляться без эмоциональной окраски, во втором же случае все они носят ярко выраженный эмоционально – экспрессивной характер.

Таким образом, обращения русского и татарского языков по значению и по структурным показателям, средствам выражения во многом одинаковы. И поэтому неслучайно, что в переводах с русского языка на татарский обращения оригинала очень часто передаются соответствующими элементами: «Ну, куда же ты, миленький, убегаешь?» – «Я инде, сөеклем, кая качасың?» (Н. Остр.)

Обращение русского языка, повторяемое через частицу «а», при переводе на татарский язык приобретает вспомогательное слово «дим»: «Мать, а мать!» – «Әни, әни, дим!». Порядок расположения обращений в предложении в двух языках также не всегда совпадает.

Установление контакта при общении начинается с приветствий, которые зависят от участников. Приветствие «Әссәламәгаләйкем!» и ответ «Вәгаләй-

кемәссәлам!» употребляются в речи стариков, хотя могут иметь место и среди молодежи. Здороваются татары за руку, пожимая обе руки. Подавать только одну руку считается неуважением. Более всего употребительно «Исәнмесез!» (Здравствуйте!). Приветствие Хәерле иртә! Хәерле көн! Хәерле кич! (Доброе утро! Добрый день! Добрый вечер!) употребительны в официальной обстановке, среди интеллигенции. Рукопожатие при этом необязательно. Несколько просторечными и фамильярными являются приветствия Нихәл? (Как дела?), Саумы? (букв. Здоров ли?), Саумысыз? (букв. Здоровы ли вы?), Сәлам! (Привет!). Среди студенчества под влиянием русской речи в шутливом стиле употребляется Чао! Салют! Привет!

К близким знакомым, родным обращение – всегда на «ты». Вежливая форма обращения на «вы» распространилась под влиянием русской речи и приобрела нормативность при обращении к знакомым людям, при соблюдении субординации между собеседниками, как выражение уважительного отношения.

Своеобразием для татарской речи является обращение к родственникам с использованием термина родства: апа (сестра), абый (старший брат), энем (младший брат), апам (сестра моя), сеңлем (сестренка), җизни (дядя), балдыз (свяченица). Раньше гораздо чаще использовались такие обращения к близким родственникам, как «чибәр апа» (красивая сестра), «алма апа» (яблоко+сестра), «шикәр апа» (сахар+сестра), «бәләкәй абый» (маленький брат), «ерак әби» (далекая бабушка) и др.

Обращение детей к своим дедушке и бабушке сохранилась в форме әби, бабай, дәү әни, дәү әти (в диалектах есть формы зур әни-зур әти, карт әти-карт әни).

Татары выработали целую систему обращений к любимым, близким людям, отличающиеся доброжелательностью, эмоциональностью: кадерлем – дорогой мой, сөеклем – милый мой, алтыным – золото мое, күгәрченем – голубка моя, былбылым – соловей мой, аккошым – лебедь мой, акыллым – умный мой, җаным – душа моя, җанкисәгем – чистица моей души, бәгерем (букв. печень моя) – дорогой, бәгыркәем – дорогой мой и т. д.

У татар широко были распространены прозвища, которые давались исходя из этнической характеристики, своеобразия социальной и внешней характеристики личности, особенностей его поведения, речи, одежды, профессии, характера жилища, курьезов связанных с человеком, и т. д. Много прозвищ по названиям животных и птиц: Аю Вәли, Саескан Сафура, Төлке Гата, Тавык Гафур и т. д. Прозвищами больше наделяются мужчины, чем женщины. Прозвищами употребляются часто перед именами лиц.

Беседа происходит сидя, беседовать стоя считается немного неприличным. Обычно татары не начинают сразу деловую часть беседы. Как правило, она проходит за столом, за чаем, что является признаком уважения и гостеприимства. За неинформативной частью беседы следует деловая часть, где излагается цель визита говорящего. Разговор завершается благодарностью за угощение, пожеланием хозяевам благополучия. Когда уходит гость, он обычно просит извенения в форме «Гаеп итеп калмагыз» (букв. «Не обессудьте»), на что хозяин отвечает «Үзегез гаеп итеп китмәгез» («Сами не уходите с осуждением»).

Общение проходит в форме диалога, где большую часть роль играют вопросы неинформативного характера, для того чтобы завязать разговор, частицы для поддержания и продолжения разговора, модальные слова. При прощании татары произносят хуш – хушыгыз (прощай – прощайте), сау бул –

сау булыгыз (букв. Будь здоровым – будьте здоровыми), исән бул – исән булыгыз (букв. будь живым – будьте живыми).

Речь татар старшего поколения небогата жестами и мимикой. Можно отметить следующие жесты татар: кивок головой направо – налево – отказ; кивок оловой сверху вниз – согласие; рукой вперед – указание; похлопывание руками по бедрам – уивление, потрясение; движение ладонью от себя – отвергающий жест; рукой к себе – приглашение и т. д. Раньше девушки во время посиделок мимикой бровей обьяснялись с парнями, пощелкивали суставами пальцев, чтобы привлечь к себе внимание.

Татарская речь очень эмоциональна, что достигается частично употреблением междометий, особенно женщинами.

Речевой этикет – важный элемент всякой национальной культуры. В языке, речевом поведении, устойчивых формулах общения сложился богатый народный опыт, неповторимость обычаев, обычаев, образа жизни, условий быта каждого народа. Речевой этикет представляет собой совокупность словесных форм учтивости, без которых просто нельзя обойтись.

ЛИТЕРАТУРА

1. Сафиуллина Ф. С., Галиуллин К. Р. Русско-татарский разговорник. – Изд. 2, испр. и доп. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1991.

2. Введенская Л. А. Культура речи. «Серия» Учебники, учебные пособия. – Ростов н/Д: Феникс, 2002.

3. Культура устной и письменной речи делового человека: пособие, учебник / под ред. Н. С. Водина. – 9-е изд., испр. – М.: Флинта; Наука, 2002. – 314 с.

4. Казарцева, О. М. Культура речевого общения: теория и практика обучения / учеб. пособие для студентов / О. М. Казарцева. – 5-е изд. – М.: Флинта; Наука, 2003. – 496 с.

## ИЗУЧЕНИЕ ЛИТЕРАТУРЫ ЭПОХИ ПРОСВЕЩЕНИЯ НА УРОКАХ РОДНОЙ (ТАТАРСКОЙ) ЛИТЕРАТУРЫ

**А. М. Закирзянов**

*Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова*
*Академии наук Республики Татарстан, Россия*
Alfat_zak@mail.ru

## THE STUDY OF LITERATURE OF THE ENLIGHTENMENT ERA IN THE LESSONS OF NATIVE (TATAR) LITERATURE

**A. M. Zakirzyanov**

*Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov*
*of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, Russia*
Alfat_zak@mail.ru

Статья посвящена проблемам изучения литературы просветительства на уроках родной (татарской) литературы. Особое внимание уделяется подготовке к проведению обзорных уроков по данной теме, приемам работы с учениками в раскрытии целей и задач урока. Повышению эффективности в процессе изучения материала служат такие приемы и средства, как работа в группах, использование компьютера, а также самостоятельная работа учащихся.

**Ключевые слова:** эпоха Просвещения, татарская литература, этапы урока, методика, прием, результат.

The article is devoted to the problems of studying the literature of enlightenment in the lessons of native (Tatar) literature. Special attention is paid to the preparation for conducting review lessons on this topic, methods of working with students in revealing the goals and objectives of the lesson. Methods and means such as working in groups, using a computer, as well as independent work of students serve to stimulate and increase efficiency in the process of studying the material.
**Key words:** the Age of Enlightenment, Tatar literature, lesson stages, methodology, reception, result.

## ДӘРЕСЛӘРДӘ МӘГЪРИФӘТЧЕЛЕК ЧОРЫ ӘДӘБИЯТЫН ӨЙРӘНҮ

**Ә. М. Закирҗанов**

Татар әдәбиятының күпгасырлык тарихы булып, ул эзлекле рәвештә үсеп-үзгәреп тора. Ил-халык тарихы белән тыгыз бәйлелектә сүз сәнгате гаять катлаулы һәм каршылыклы юл үтә. Шуңа нисбәтле аның тарихын аерым дәверләргә, чорларга, этапларга бүлеп өйрәнү кабул ителгән. Әдәбият үсешендә «Мәгърифәтчелек чоры әдәбияты» исеме белән кереп калган дәвер җитди урын алып тора. Әдәбият фәнендә ул XIX йөзнең икенче яртысы һәм өлешчә XX йөз башы белән билгеләнә [3: 209]. Әлеге чор урта гасырлардан Яңа заман әдәбиятына күчеш буларак та бәяләнә. Шунлыктан бу еллар әдәбиятында сан һәм сыйфат үзгәрешләрен билгеләү, үз чиратында, үткәннең традицияләрен барлау һәм җитди яңачалыкны ачыклауга хезмәт итә. Мәкаләнең актуальлеге әнә шулар белән билгеләнә. Төп максат булып мәгърифәтчелек чоры әдәбиятының үзенчәлекләрен ачыклау һәм әдәбият дәресләрендә аларны укучыларга җиткерү алым-юлларын билгеләү тора.

Татар һәм рус телләрендә белем бирә торган мәктәпләрдә шактый аз санда вакыт бирелеп, әлеге тема гадәттә күзәтү дәресендә өйрәнелә. Бу дәрестә алда өйрәнеләчәк аерым авторлар иҗатына җирлек әзерләнә, шуңа да аны җитди әзерлек белән үткәрү сорала [1: 85]. Дәреснең планлаштырылган нәтиҗәләрен болай күрсәтеп булыр иде. Метапредмет нәтиҗәсе мәгърифәтчелек әдәбиятының гомум сүз сәнгате тарихындагы урынын билгеләүне күздә тота; предмет нәтиҗәсе исә XIX йөзнең икенче яртысында, тәгәлрәге соңгы чирегендә урын алган әдәби процесска күзәтү ясауны, аның сыйфат-билгеләрен аерып чыгару белән бәйле. Шәхескә караган нәтиҗә әлеге чор әдәбиятына кызыксыну тудыруга нигезләнә.

Дәреснең укучыларны кызыксындыру һәм актуальләштерү этабында үткәннәр искә төшерелә. Игътибар үзәгендә сүз сәнгатенең чорлар аша үтеп тә үзенә хас үзенчәлекләрен саклап калуы һәм яңа сыйфатлар белән баюы тора. Укучылар әлеге дәвамлы күчешне ачык аңлап калган очракта гына яңа чор үзенчәлеген дөрес кабул итә. Укучылар белән бергә мондый сораулар ачыклана: 1. XIX йөзнең беренче яртысында булган тарихи-иҗтимагый вакыйгаларны санап чыгыгыз. 2. Казан университетының татарлар тормышындагы роле турында ниләр беләсез? 3. Татарча китапларның басылу тарихы сезгә танышмы? Укучыларның әзерлегенә бәйле, аерым эшне өйгә дә бирергә була. Бер-ике укучының максатчан әзерләнеп сөйләвен оештыру да үзен аклый. Болар турында фикер алышып, укытучы материалны түбәндәгеләр белән тулыландыра.

Белгәнебезчә, XVI йөз уртасында Казан ханлыгы рус дәүләте тарафыннан яулап алынгач, татар халкы коточкыч матди һәм рухи югалтуларга дучар була. Авыл-шәһәрләр белән бергә, мәчет-мәдрәсәләр, алардагы бай әдәбият, мирас юкка чыгарыла. Халыкның бер өлеше читкә күчеп китә, калганнары да милли һәм социаль изүгә дучар була. Халык ислам диненә сыенып кына

үзен саклап кала ала. Шундый шартларда әдәбият торгынлыкка кереп, ул ике гасырдан артыкка сузыла. Бары XVIII гасыр ахырында гына татар халкында үзен табу, барлау, алга таба хәрәкәт итү күренешләре пәйда була. Бу, билгеле, чит илләргә чыгу, сәүдә эшенең акрынлык белән булса да үсеше, кайбер хокуклар бирелү белән бәйле. XIX йөзнең беренче яртысында җитди тарихи һәм иҗтимагый вакыйгалар була: рус-француз сугышы, декабристлар восстаниесе, Казанда университет ачылу, татарча китаплар чыга башлау һ.б. Болар халыкның иҗтимагый-фикере үсешенә уңай йогынты ясый. Бу чорда татар мәдәнияте үзәкләре буларак Оренбург, Җаек, Уфа таныла һәм шул төбәкләрдә Ә.Каргалый, Ш.Зәки, Һ.Салих кебек шагыйрьләр үсеп чыга. Татар әдәбияты өч юнәлештә үсеш кичерә: дини-әхлакый, дини-суфыйчыл, дөньяви. Билгеле, алар барысы да ислам дине, Коръән тәгълиматы белән тыгыз бәйле була. Әнә шундый шартларда гасыр уртасына таба яшәештә башка халыклар белән кызыксыну, үрнәк алу, белем-мәгърифәткә омтылу көчәя бара.

Үткән материалны кабатлау, тулыландыруга таянып, уку мәсьәләсе куела. Дәреснең максаты-бурычлары ачыклангач, чорга күзәтү ясала. Төп материал түбәндәге сорауларга җавап эзләү белән бәйле: Мәгърифәтчелек хәрәкәте нәрсә ул? Аның сәбәп-шартлары, үзенчәлекләре нидән гыйбарәт? Мәгърифәтчелек хәрәкәте белән әдәбиятның бәйләнешен ачыклагыз? Мәгърифәтчелек әдәбияты төшенчәсенең асылын билгеләп, төп көчләрен атарга?

Материал шактый катлаулы һәм күләмле, шуңа да укытуның төрле технологияләрен, алым-формаларын куллану сорала. Максатка нигезле педагогик технологияләрнең берничә төрен файдаланып була, бу укытучының эш стиленә бәйле. Иң мөһиме, укытучы һәм укучыларның программалаштырылган, системага салынган эшчәнлеген оештыру [6: 37–40]. Аерым алганда, беренче сорауга җавапны дәреслек ярдәмендә табу эше оештырыла. Төркемнәрдә эшләү дә аклый. Аерым сораулар төркемнәргә бирелә, алар исә дәреслектәге материалга нигезләнеп, җавап әзерли.

1. Мәгърифәтчелек хәрәкәте нәрсә ул? Аның сәбәп-шартлары, үзенчәлекләре нидән гыйбарәт?

Бу чорда татарларның мәркәзе ролен Казан шәһәре үти башлый. Ул сәнәгать, фән, мәгариф үзәгенә әверелә, шуңа татарлар да шунда туплана башлый. Капитал мөнәсәбәтләре үсү алдынгы карашлы эшчеләр булуны таләп итә. Татар дөньясында уяну хәрәкәте башлана, ягъни яшәешне заман таләпләренә нигезләнеп кору максатында мәктәп-мәдрәсәләрдәге уку-укыту процессын үзгәртү башлана. Шул ук вакытта ислам динен бертөрле, берьяклы аңлатулар да каршылыкка керә. Мәдәни тормыштагы үзгәрешләрдә алгы планда мәгърифәт мәсьәләләре тора. Шуңа да бу хәрәкәтне Мәгърифәтчелек хәрәкәте дип атый башлыйлар. Әлеге киң мәгънәдәге төшенчә, бер яктан, мәктәп-мәдрәсәләрне үзгәртеп коруны, дин белән бергә дөньяви фәннәр укытуны һәм башка халыклар мәдәниятендәге казанышларны өйрәнүне күздә тота [4: 112]. Мәгърифәтчелек, идеология буларак, яңалык өчен мәйданны чистартучы фәлсәфи, этик һәм эстетик карашлар системасы ул [2: 10–12]. Әлеге хәрәкәтнең актив вәкилләре булып К. Насыйри, Ш. Мәрҗани, М. Акъегетзадә, З. Бигиев, Р. Фәхретдин, Ф. Кәрими, Г. Чокрый, М. Акмулла һ.б. тора. Аларга Г. Исхакый, Г. Камал, М. Гафури, Ш. Камал кебек әдипләр килеп кушыла, беренче әсәрләрендә уку-укыту, әдәп-әхлак мәсьләләләрен алгы планга куеп язалар.

2. Мәгърифәтчелек хәрәкәте белән әдәбият бәйләнешен билгеләгез?

Мәгърифәтчел карашлар әдипләр тарафыннан күтәреп алына. Алар аң-белемле, әдәпле, тәрбияле кеше тормышта да бәхетле була дигән карашны яклап чыгалар. Шул рәвешле әдәбият мәгърифәтчел карашларны тарату,

халыкка җиткерү вазифасын үти башлый. А. Юзиев фикеренчә, җәмгыятьтә мәгърифәтчелек әхлакый һәм фәлсәфи идея буларак тарала башлый [7: 144]. Әдәбиятта мәгариф белән бәйле мәсьәләләр үзәккә куела, ул исә ислам дине, кеше шәхесе, башкалар тәҗрибәсен өйрәнү һ.б. белән үрелеп бара.

Әлеге сорауга бәйле укучыларга мөстәкыйль эш бирелә. Ул өстәмә материалны үзлектән укып, план төзү яисә кыскача конспект ясау була ала.

3. Мәгърифәтчелек әдәбияты төшенчәсенең асылы һәм төп көчләре.

Татар мәгърифәтчелек әдәбиятының төп көчләре булып М. Акъегетзадә, З. Бигиев, Г. Ильяси, Ф. Халиди, Р. Фәхретдин, Ф. Кәрими, М. Акмулла санала. Аларның иҗаты әлеге яңару идеяләре белән сугарылган. Киң планда мәгърифәтчелек әдәбиятының төп үзенчәлекләре булып түбәндәгеләр тора. 1) Иске типтагы мәдрәсәләрне тәнкыйтьләү һәм иске карашлы дин әһелләренең, шулай ук мөгаллимнәрнең эш-гамәлләрен фаш итү. М. Акъегетзадәнең «Хисамеддин менла»сындагы Бикбулат хәзрәт, З. Бигиевның «Зур гөнаһлар»ындагы Нәкас мулла, Ф. Кәриминең «Шәкерт илә студент»ындагы Шәкерт образлары искелек тарафдарлары буларак фаш ителеп, хурлыкка калдырыла. 2) Әдәби әсәрләрдә яңача белем бирүче уку йортлары үрнәк итеп куела. Дини гыйлем кешенең рухы өчен булса, дөньяви гыйлем яшәеш өчен кирәк дигән фикер яклана. Аның матур үрнәге булып М. Акъегетзадә, Р. Фәхретдин Ф. Кәрими һ.б. әдипләрнең геройлары тора. 3) Бу типтагы әсәрләрдә яхшылык һәм начарлык капма-каршы көчләр рәвешендә сурәтләнә. Бу исә аларның асылын тирәнрәк ачуга хезмәт итә. Нәтиҗәдә начарлык кире кагыла, ә белем-мәгърифәткә бәйле карашлар күтәреп кеуела. М. Акъегетзадә, З. Бигиев, бераз соңрак Р. Фәхретдин, Ф. Кәрими, Г. Чокрый, Акмулла иҗатларында яхшылык җиңүе әдәби сурәтләрдә, гыйбрәтле мисалларда раслана. «Кешелек җәмгыятенең эволюциясен алар кеше шәхесенең аеруча мөһим сыйфатларыннан булган әхлакый камиллеге белән бәйләп карыйлар» [5: 32], – дип яза Ә. Сибгатуллина. 4) Әдәби әсәрләрдә төп конфликт буларак искелек – яңалык, наданлык – гыйлемлелек алга чыга. Ул исә геройларның ачык күренеп торган ике лагерьга бүленүенә китерә. Нәтиҗәдә искелек тарафдарлары җиңелә, яңалыкны яклаучылар җиңеп чыгып, бәхетле яшәешкә ирешә. Беренчеләрдән буларак әлеге сәнгати алым М. Акъегетзадәнең «Хисаметдин менла» әсәрендә чагыла һәм алга таба исемнәре югарыда аталган барлык әдипләр иҗатында урын ала. 5) Әдбиятның иң зур яңалыкларыннан берсе – табигый кеше образының үзәккә куелуы. Әсәр геройлары реаль чынбарлыктан алына.

Укучыларда кызыксыну уяту, нәтиҗәлелекне үстерү максатында компьютердан файдалану да уңышлы. Әлеге сорауга компьютердан файдаланып җавап әзерләргә бирелә. Аерым укучыларга теге яисә бу язучы турында мәгълүмат тупларга бирелә. Аларның җаваплары тыңлану барышында, сыйфатбилгеләр дәфтәргә языл барыла. Әнә шул рәвешле төп сорауларны ачыклау аша уку мәсьәләсенең чишелешенә киленә. Дәрес ахырында рефлекция буларак үткәннәр гомумиләштереп кабатлана. Өй эшенә өч төрле бирем тәкъдим ителә. Аның берсе дәреслектәге материалны уку, сорау-биремнәргә җавап әзерләү белән бәйле, икенчесе мәгърифәтчелек әдәбияты үзенчәлекләрен күрсәтеп карточкалар әзерләү була ала. Өченче сорау итеп мәгърифәт, әхлак идеяләренең һәр чор әдәбиятында урын алуы турында бер-ике әсәргә нигезләнеп эссе язу бирелә ала.

Шулай итеп, әдәбият тарихында үзенчәлекле этап булып торган Мәгърифәтчелек чоры әдәбиятын өйрәнү җитди әзерлек таләп итә. Дәрес күзәтү төсендә булып, материалны системалы гомумиләштереп бару сорала. Аерым этапларда укучыларның мөстәкыйль эшчәнлеген оештыру да үзен аклый.

Төркемнәрдә эшләү, компьютердан файдалану кебек алымнар үзара җаваплылыкны, шәхси инициативаны үстерүгә ярдәм итә.

ӘДӘБИЯТ

1. Габидуллина Ф. И. Нетрадиционные уроки внеклассного чтения // Воспитательный потенциал семейного чтения в эпоху цифровизации и глобализации: материалы Международной научно-практической конференции (19–20 сентября 2019 г.). – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2019. – С. 85–89.

2. Исхаков Д. Феномен татарского джадидизма: введение к социокультурному осмыслению. – Казань: Иман, 1997. – 80 с.

3. Надыршина Л. Р. XX йөз башы татар поэмаларында мәгърифәтчелек идеяләре // Просветительское движение у тюркских народов и творчество Абая: материалы Международной научно-практической конференции, посвященной 175-летию со дня рождения казахского поэта, просветителя, общественного деятеля Абая (Ибрагима) Кунанбаева (14 декабря 2020 года). – Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 2020. – С. 209–211.

4. Очерки истории татарской общественной мысли. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2000. – 191 с.

5. Сибгатуллина А. Т. В поисках человека (концепция личности в поэзии XIX века). – Елабуга: Изд-во ЕГПИ, 2001. – 142 с.

6. Технологии и методики обучения литературе: учеб. пособие / под ред. В. А. Кохановой. – М.: ФЛИНТА: Наука, 2011. – 248 с.

7. Юзеев А. Татарская философская мысль конца XVIII-XIX вв. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2001. – 192 с.

## ОБЫЧАИ, ПРАЗДНИКИ, ТРАДИЦИИ ТАТАРСКОГО НАРОДА В ПАТРИОТИЧЕСКОМ ВОСПИТАНИИ

**Д. Ф. Зарипова**

*МБОУ «Школа № 85» Ново-Савинского района г. Казани, Россия*

4812000865@edu.tatar.ru

## CUSTOMS, HOLIDAYS, TRADITIONS OF THE TATAR PEOPLE IN PATRIOTIC EDUCATION

**D. F. Zaripova**

*Municipal budgetary educational institution «School No. 85» of the Novo-Savinsky district of Kazan, Russia*

4812000865@edu.tatar.ru

Вопросы, связанные с культурой этносов и наций, особенно национальные традиции, сколько бы их не исследовали, всегда вызывают большой интерес. Накопленный в течение многих веков огромный жизненно-практический опыт народов Поволжья аккумулируется в народных знаниях. Эти знания складываются и совершенствуются в процессе общения всех народов, проверяются на практике и передаются из поколения в поколение.

**Ключевые слова:** Родной язык, этнокультурное развитие, формы обучения.

Questions related to the culture of ethnic groups and Nations, especially national traditions, no matter how much they are studied, always arouse great interest. The vast vital and practical experience of the peoples of the Volga region accumulated over many centuries is accumulated in folk knowledge. This knowledge is developed and improved in the process of communication between all peoples, tested in practice and passed on from generation to generation.

**Key words:** Native language, ethnic and cultural development, forms of education.

# ПАТРИОТИК ТӘРБИЯ БИРҮДӘ ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ЙОЛАЛАРЫ, БӘЙРӘМНӘРЕ, ТРАДИЦИЯЛӘРЕ

**Д. Ф. Зарипова**

Бүгенге көндә милли тәрбияне үстерү мәсьәләсе яңа проблема түгел. Милли тәрбия, телне үстерү, саклау, милли үзаң формалаштыру белән тыгыз бәйләнештә. Баланы шәхес буларак тәрбияләү өчен тел белү, тел өйрәнү генә җитми, татар халкының мәдәниятен белү, үз милләте белән горурлану, шул халыкка хезмәт итү омтылышы мөһим. Шәхескә белем бирү, аны тәрбияләү һәм тормышка әзерләүдә күп факторлар катнаша: гаилә, тирә-юнь, урам, табигать һәм шулар белән бәррәттән милли-региональ үзенчәлекләр. Һәр халык, һәр милләт үзенең рухи байлыгын үзенчәлекле шартларда, үзенчәлекле юллар һәм алымнар белән туплаган. Аларның һәрберсе дөнья мәдәниятенә үзеннән сизелерлек өлеш кертә, баета. Балаларны кечкенәдән үк үз халкының, үз туган җиренең үзенчәлекләре белән таныштыру гомумкешелек кыйммәтләре белән таныштыруның башлангычы булып тора. Безнең бурыч – үткән буыннар туплаган рухи байлыкны саклап, баетып, аның кешелек тарафыннан иң кыйммәтле дип табылган үрнәкләрен балаларга җиткерү.

Татар халкының уй-холкы, фикере, барлык йолалары, гореф-гадәтләре, традицияләре-үзе бер тәрбия ысулы. Аларны өйрәнү балаларның рухи үсешенә этәргеч бирә. Баланың гаиләдә, коллективтагы тәрбияви нормалары, кагыйдәләре халык педагогикасына салынган. Халык традицияләрен кулланып уздырган дәресләр, чаралар баланың актив үсешенә өстәмә чыганак итеп кулланыла. Һәр укытучы үзенең педагогик эшчәнлегендә аларны куллануның күпләгән юлын һәм ысулларын таба. Бүген яңа методик алымнар, технологияләр зур тизлек, күзгә күренмәгән темплар белән үскән вакытта, методик эшнең әһәмияте аеруча арта. Халык педагогикасы – фәнни педагогиканың нигезе. Анда борынгы заманнардан ук халык акылы, аның зирәк фикерләре, киңәшләре тупланган. Аларны һич тә югалтырга ярамый. Халыкның үзенә генә хас булган тарихи үсешен, аның психологиясен чагылдырган, балаларга һәм яшьләргә белем һәм тәрбия бирү ысуллары, чаралары турындагы карашлар, буыннан-буынга күчеп үсәргә, камилләшергә тиеш. Традицияләрне, гореф-гадәтләрне кире кайтару гына түгел, аларны заманчалаштыру, яңарту, гомумкешелек кыйммәтләре юнәлешендә үстерү дә мөһим эш. Халкыбызның гореф-гадәтләрен, йолаларын өйрәнү хәзерге көндә бигрәк тә актуаль. Әгәр без халкыбызның гореф-гадәтләрен, йолаларын белмибез икән, димәк, без үзебезнең тамырыбызны югалтабыз, милләт буларак яшәүдән туктыйбыз дигән сүз. Әдәбият укытучысының бурычы программада каралган әсәрләрне аңлап үзләштерүдән, аның идея-эчтәлеген аңлатудан, укучыда эчке матурлыкка омтылу кебек күркәм сыйфатлар тәрбияләүдән, әйләнә-тирә мохиткә, төрле вакыйгаларга дөрес бәя бирүдән, мөстәкыйльлеккә өйрәтүдән гыйбәрәт. Шуңа күрә мин укучыларыма үз милләтен, эти-әнисен, әби-бабасын, туганнарын, туган телен яратучылар итеп тәрбияләүгә зур әһәмият бирәм. Дәресләрне тормыш белән бәйләп, халык педагогикасы нигезендә оештырырга тырышам. Халык авыз иҗаты әсәрләрен киң куллану, җирле материаллардан файдалану бик әһәмиятле дип саныйм. Аларда әхлак сыйфатлары киң чагылыш таба. Мәктәптә милли тәрбия берничә юнәлештә бара: телне өйрәтү, халыкның әдәбиятын һәм аның аша мәдәниятен өйрәтү, гореф-гадәтләренә, тарихына карата кызыксыну уяту, дәрестән тыш чаралар ярдәмендә, шул тирәлектә яшәү ихтыяҗы тудыру. Һәр халыкның да рухи мәдәниятендә туган тел төп урынны алып тора. Халыкның милли йөзе, гореф-гадәтләре,

йолалары, туган тел, үз ана теле саклаган очракта гына саклана. Мин төрле яшьтәге укучы балалар белән эшлим. Балаларны туган телебез белән тагын да кызыксындыру максатыннан «Сәнгатьле уку» түгәрәге оештырылды. Халык йолалары, традицияләре, фольклор аркылы бала шәхесендә олыларга карата хөрмәт, табигатькә сакчыл караш, үзара хөрмәт, ярдәмләшү тәрбияләнә. Билгеле бер йолаларның үтәлеп килүе җәмгыятьне дә тотрыклы итә, алардан башка халык тулы кыйммәтле тормыш белән яши алмый. Яшь буын бәйрәмдә катнашу тәртибен кечкенәдән үк өйрәнеп үсә. Татар халкы һәрвакыт үзенең йолаларына тугры булды. Чөнки алар безгә бик ерак бабаларыбыздан мирас булып калганнар. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә «йола теге яки бу халыкның яшәешендә борыннан кереп урнашкан тормыш-көнкүреш традицияләрен яки дини кануннарны үтәүгә бәйләнешле тәртип һәм гадәтләр, «гореф-гадәт», ә «традиция тарихи барлыкка килгән һәм буыннан буынга күчә торган гореф-гадәтләр, әхлак кагыйдәләре, карашлар, зәвыклар» дип бирелә. Тик онытмаска, сакларга, буыннан буынга җиткерергә иде аларны. Татар халкының борынгыдан килгән ел фасылларына бәйле Сабан туйлары, Нәүруз, Нардуган, Сөмбелә; ислам диненә бәйле Рамазан һәм Корбан бәйрәмнәре бүгенге көндә дә сакланган. Табигый, буыннан буынга күчә торган рухи тәҗрибә һәм йолалар вакытлар узу белән һич тә әһәмиятләрен югалтмыйлар, киресенчә, аларның кыйммәте арта гына. Моның шулай булуы әдәби әсәрләр мисалында тагын бер кат исбатлана. Г. Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» әсәре халык йолаларын өйрәнергә, аларны саклап калырга кирәклекне искәртә. Әсәрдә да борынгыдан килгән гореф-гадәтләр, йолалар җентекләп бирелгән. Яшьләр һәм алар арасындагы мөнәсәбәтләр дә барлык нечкәлекләренә игътибар итеп язылган, бала туу йоласы, Корбан бәйрәме, Урак өмәсе, Каз өмәсе, Сабан туе, Яңгыр боткасы, Урак уру, Печәнгә төшү бәйрәмнәре сурәтләнгән. Әсәрләрдәге гореф-гадәтләрне, бәйрәмнәрне истә калдыру максатыннан, дәресләрдә компьютер технологияләрен актив куллану, видеоролик һәм презентацияләр карау яхшы нәтиҗә бирә. Аеруча язучы иҗатларын, әсәрләрен өйрәнгәндә укучы шәхесен һәрьяклы үстерү өчен ярдәм итә. Укучылар үзләре дә төрле сайтлардан кирәкле мәгълүматларны табалар, эзләнәләр һәм сыйныфташлары каршында чыгыш ясыйлар. Укучыларның мөстәкыйльлегенә, танып-белү активлыгына, ныклы һәм тирән белемле булуларына ирешүдә дәрестән тыш эшләрнең дә әһәмияте зур. Мәсәлән, «Каз өмәсе», «Аулак өй» һ.б. күренешләрдә катнашу, укучыларның активлыгын аттыра, татар халкының гореф-гадәтләренә карата хөрмәт уята. Бу гадәтләр югалмасын өчен без аларны онытмаска, хөрмәт итәргә, белергә тиеш. Аларны белсәк, безнең телебез дә югалмас, сакланыр. Шуңа күрә хәзерге заманда бу бик актуаль проблемаларның берсе дип уйлыйм. Бу проблема өстендә заманында танылган шәхесләребез Г. Ибраһимов, Р. Фәхретдин да эшләгән, үзләренең тормыш максатларын тәрбияле, милли буын үстерүдә күргәннәр.

Дөрестән дә, халыклар арасында дуслык бәйләнешләрен ныгытуда бәйрәмнәрнең роле зур, чөнки алар аша халыклар бер-берсенең мәдәниятен, яшәү рәвешен, гореф-гадәтен, йолаларын өйрәнә һәм шулар аша бер-берсенә хөрмәт тәрбияли, үз итә, дуслыгын ныгыта.

## ӘДӘБИЯТ

1. Баязитова Ф. С. Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995.

2. Татар мөселман календаре. – Казан, 1998.

# ПУТИ ФОРМИРОВАНИЯ КОММУНИКАТИВНОЙ КОМПЕТЕНЦИИ У УЧАЩИХСЯ ПРИ ОБУЧЕНИИ РОДНЫМ ЯЗЫКАМ И ЛИТЕРАТУРЕ

**Н. З. Кашипова**

*МАОУ «СОШ № 17» г. Альметьевска Республики Татарстан, Россия*
kashipova73@mail.ru

# WAYS OF FORMING STUDENTS' COMMUNICATIVE COMPETENCE WHEN TEACHING NATIVE LANGUAGES AND LITERATURE

**N. Z. Kashipova**

*Municipal autonomous educational institution «Secondary school 17» of Almetyevsk, Republic of Tatarstan, Russia*
kashipova73@mail.ru

Статья посвящена проблеме обучения русскоязычных учащихся общению на татарском языке. На сегодняшний день важно формирование коммуникативных умений, поскольку коммуникация является основой всего процесса обучения. Важно сформировать в детях умение сотрудничать с людьми, быть терпимыми к различным мнениям, слушать и слышать собеседника, свободно и аргументировано излагать свою точку зрения. Изложены пути формирования коммуникативной компетенции учащихся, которые основаны на систему обучения учителя-практика иностранных языков В. Н. Мещеряковой.
**Ключевые слова:** коммуникативность,коммуникативная компетенция, мотивация, деятельность, игровая технология, партнерство.

The article is devoted to the problem of teaching Russian-speaking students to communicate in the Tatar language. Today, it is important to form communicative skills, since communication is the basis of the entire learning process. It is important to develop in children the ability to cooperate with people, be tolerant of different opinions, listen and hear the interlocutor, freely and argumentatively express their point of view. The ways of formation of students' communicative competence are described, which are based on the teacher's training system-the practice of foreign languages by V. N. Meshcheryakova.
**Key words:** communication, communicative competen, motivation, activity, gaming technologye, partnership.

# ТУГАН ТЕЛ ҺӘМ ӘДӘБИЯТНЫ ӨЙРӘТКӘНДӘ УКУЧЫЛАРНЫҢ КОММУНИКАТИВ КОМПЕТЕНЦИЯСЕН ФОРМАЛАШТЫРУ ЮЛЛАРЫ

**Н. З. Кашипова**

Бүгенге көн заманча укытуга нигезләнгән мәктәпләр алдына куелган төп шартларның иң әһәмиятлесе – иҗади фикер йөртә алырдай, инициативалы, мөстәкыйль, рус һәм татар телләрендә аралаша белгән, барлык дәүләт һәм җәмгыять эшләрендә актив катнаша алырдай шәхесләр тәрбияләп чыгару. Федераль дәүләт белем бирү стандартлары укытучылардан мәктәптә тупланган белем һәм тәҗрибәне тормышта куллана алырлык, коллективта уңай эшчәнлеккә ярашырдай шәхесләр тәрбияләүне таләп итә. Шушы таләпләрне тормышка ашыруда төп эшчәнлек – коммуникатив эшчәнлек.

Коммуникатив эшчәнлекнең нигезендә партнерларның бер-берсен тыңлый, аңлый, үзе ия булган мәгълүматны янәшәдәгеләргә тапшыра,

үз эшен партнерыныкы белән чагыштыра һәм нәтиҗә ясый, бәяли белү осталыгы ята.

Бүгенге татар теле укытучылары алдында торган төп бурыч – рус телле укучыларны татарча аралашуга чыгару. Әлеге эш нәтиҗәле булсын өчен укучыларда коммуникатив компетенцияне формалаштыру мөһим.

Коммуникация – «аралашу», компетенция – «сәләт» дигән төшенчәләрне аңлата. Димәк, коммуникатив компетенция ул – укучыларның бер-берсе белән «аралашу сәләте».

Рус телле укучыларны татарча сөйләшүгә чыгару өчен аралашу шартлары тудырырга кирәк. Озак еллар мәктәптә эшләү дәверендә безгә бик күп төрле дәреслекләр, технологияләр, методикаларга нигезләнеп дәрес бирергә туры килде. Соңгы елларда рус телле укучыларны татар телендә сөйләшергә өйрәтүне, аларның коммуникатив компетенцияләрен камилләштерүне практик укытучы В. Н. Мещерякованың тел өйрәтү системасына нигезләнеп алып бардык. Әйтергә кирәк, әлеге системаның нигезендә тулысы белән коммуникатив эшчәнлек ята.

Укучы телне теләп өйрәнсен өчен укытучы аларны кызыксындыра алырдай алшартлар тудырырга, мотивация булдырырга тиеш. Кем өчендер ул – киләчәктә аралашу дәрәҗәсендә телне өйрәнү, кемгәдер – яхшы билге алу мөмкинлеге.

В. Н. Мещерякованың белем бирү системасына нигезләнеп уздырылган дәресләрдә аралашу ишек төбеннән башлана дип әйтсәк, хаталанмабыз. Сыйныфка үтүче һәр укучы, бүгенге кәефенә карап, укытучы белән исәнләшү алымын сайлый, укытучыдан мактау, юату сүзләрен ишетә. Сыйныф ишегенең бу ягына узгач, русча сөйләшү мөмкинлеген оныту, «авызны йозакка бикләү» һәм ачкычын дәрес азагына кадәр кесәгә салу кирәклеген билгели. Ә дәрес – тулы бер театр!

Башыннан ахырына кадәр укучының сөйләмен, аралашу мөмкинлеген оештыруга юнәлтелгән күнекмәләр бер-берсен тулыландырып, баетылып бара. Эш төрләре җиңелдән катлаулыга таба оештырыла, ләкин укучылар бу катлаулылыкны сизмиләр. Сәбәбе: коммуникативлыкны үстерүдә уен технологиясен куллану. Әлеге технологиягә нигезләнеп оештырылган һәр дәрестә укучылар әкият геройлары белән аралашалар, аларны ашханәгә, даруханәгә, кибеткә озаталар, шул ук вакытта, әкият геройларына татарча аралашырга булышалар. Рус телле укучылар төзеп, аралаша алырдай диалоглар, ял итү вакытларында истә калдырыр өчен кабатлана торган җөмләләр, күмәк уеннар, уен вакытында җырлана торган җырлар, бию һәм спорт хәрәкәтләре – барысы да татарча аралашуга китерә алырдай, коммуникатив компетенцияне камилләштерә торган эш төрләре. Укучы армый, дәрескә кәефсез килгәннәренең дә кәефләре күтәрелә, киеренкелек, сыйныфташлардан, укытучыдан оялу кебек сыйфатлар арткы планда кала. Бер-берләре арасында дуслык, теләктәшлек, ярдәм итү кебек кешелеклелек сыйфатлары урнаша. Дәрес башында «кесәгә яшерелгән ачкыч» балаларны тәрҗемә күнекмәләрен кулланмыйча гына татар телендә аралашуга алып чыга. Һәр укучы аңлый: әйткән сүзне, куелган таләпне үтәү мөһим! «Мин булдырам»! «Мин татарча сөйләшә алам!» Менә бу – дәрескә куелган иң отышлы мотивация. Аралашу осталыкларын практик камилләштерү чаралары да еш оештырыла. Укучылар, төркемнәргә бүленеп, кибет, музей, китапханә, балалар бакчаларында практик сөйләшүләрдә булып кайталар. Әлеге әңгәмәләр видеога яздырыла. Һәр чирек азагында бу эшләрнең унышлы һәм хаталы яклары турында фикер алышу оештырыла, җиңүче дип табылган төркемнәргә мактау грамоталары тапшырыла.

Нәтиҗә: ел азагында укучылар яшьтәшләре, укытучылар һәм әти-әниләренә татар телендә мюзикл тәкъдим итәләр. Бу мюзикл башыннан ахырына кадәр ел буена өйрәнелгән диалоглар, рольле уеннар, ситуатив күнекмәләрне кулланып төзелә.

Белем бирүнең нәтиҗәсе – искиткеч! Әмма укытучыдан бик зур әзерлек, иҗадилык, сабырлык, укучыларның яшь үзенчәлекләрен, психологик халәтләрен, әти-әниләр белән бәйләнешне истә тотып эшләүне таләп итә. Башлангыч сыйныфларда алган белемнәр урта һәм югары сыйныфларда фәнни-тикшеренү эшләре, проектлар эшчәнлеге белән шөгыльләнүгә нигез булып тора.

### ӘДӘБИЯТ


1. Сафиуллина Ф. С. Татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. – Казан: «Хәтер» нәшрияты, 2001. – 68 б.

2. Харисов Ф. Ф. Татар телен өйрәнүдә заманча технологияләр // Мәгариф. – 2002. – № 8. – Б. 34–35.


## ДИДАКТИЧЕСКАЯ КОММУНИКАЦИЯ КАК СРЕДСТВО РАЗВИТИЯ ПОЗНАВАТЕЛЬНОЙ АКТИВНОСТИ НА УРОКАХ ЛИТЕРАТУРНОГО ЧТЕНИЯ


**Г. Ф. Каюмова**

*Казанский Федеральный университет, Россия*
gulfar21@mail.ru


## DIDACTIC COMMUNICATION AS A MEANS OF DEVELOPING COGNITIVE ACTIVITY IN LITERARY READING LESSONS


**G. F. Kayumova**

*Kazan Federal University, Russia*
gulfar21@mail.ru



Автор статьи рассматривает дидактическую коммуникацию как средство развития познавательной активности младших школьников. Именно на начальном этапе школьного обучения складываются особые отношения между учащимися и учителем, которые влияют и на формирование личности учащихся, и на успешность обучения. Анализ современных учебников по литературному чтению (на родном языке) дает возможность сказать о новых подходах в обучении младших школьников. Техника сторителлинг, на котором основан учебник Г.М. Сафиуллиной, Ф.Ф. Хасановой, способствуют проведению урока как интересного путешествия-приключения, где у учителя и учащихся общая задача – помочь героям учебника в мире волшебства и приключений. Творческие вопросы и задания, предлагаемые в учебнике под авторством Ф.Ф. Гарифуллиной, И.Х. Мияссаровой продуманы как тематическая основа эффективной дидактической коммуникации не только по теме урока, но и о природе, обществе, о личностных отношениях.



**Ключевые слова**: дидактическая коммуникация, младший школьный возраст, литературное чтение, современный учебник, сторителлинг, творческое задание.



The author of the article considers didactic communication as a means of developing the cognitive activity of primary schoolchildren. It is at the initial stage of schooling that a special relationship develops between students and the teacher, which affects both the formation of the personality of students and the success of learning. Analysis

of modern textbooks on literary reading (in the native language) makes it possible to talk about new approaches in teaching younger students. The storytelling technique on which the textbook by G.M. Safiullina, F.F. Khasanova, contribute to the lesson as an interesting adventure travel, where the teacher and students have a common task – to help the heroes of the textbook in the world of magic and adventure. Creative questions and tasks offered in the textbook authored by F.F. Garifullina, I.Kh. Miyassarova are thought out as a thematic basis for effective didactic communication not only on the topic of the lesson, but also on nature, society, and savage relationships.
**Key words**: didactic communication, primary school age, literary reading, modern textbook, storytelling, creative task.

## ӘДӘБИ УКУ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ТАНЫП БЕЛҮ АКТИВЛЫГЫН ҮСТЕРҮ ЧАРАСЫ БУЛАРАК ДИДАКТИК КОММУНИКАЦИЯ

**Г. Ф. Каюмова**

Уку-укытуда укытучы һәм укучы арасындагы коммуникациянең уңышы, беренчедән, нәтиҗәдә укучы тарафыннан үзләштерелә торган белем, күнекмәләр белән билгеләнсә, икенчедән, белем бирү процессының тигез хокуклы ике субъекты (укытучы, укучы) арасында үзара аңлашу дәрәҗәсе, шәхесара мөнәсәбәтләрнең характерына да бәйле. Гомумән, педагогикага караган күп кенә хезмәтләрдә укытучыларны хәзерләүнең мөһим аспекты буларак аның коммуникатив компетенциясе, укучылар белән нәтиҗәле аралашу кора белү күнекмәләрен үстерү атала [4]. Галим, белгечләрнең хезмәтләрен өйрәнү [5] башлангыч сыйныф укытучысының коммуникатив компетенциясе үсеше турында түбәндәге күрсәткечләр буенча хөкем йөртергә мөмкинлек бирә:

– укучылар белән вербаль һәм вербаль булмаган чаралар ярдәмендә мәгълүмат алмаша белүе;

– укучылар белән хезмәттәшлек итүнең стратегиясен, тактикасын һәм техникасын нәтиҗәле куллану, уку-укыту һәм тәрбияви нәтиҗәләргә ирешү өчен укучыларның бер-берсе белән хезмәттешләгән оештыру;

– укучыларга эмпатияле мөнәсәбәт һ.б.

Дидактик коммуникация дигәндә, фәндә түбәндәге караш яши: «дидактик коммуникация дәрестә белем бирү шартларында тиләлек һәм үзең турында белемнәрне үзләштерү һәм күнекмәләргә ия будыруны бурыч итеп куйган укытучы һәм укучыларның үзара хезмәттәшлек итүнең максатчан һәм икеяклы процессы буларак танылa. Ул танып белүнең нәтиҗәлелеген, уку-укыту мәгълүматын җиткерү, үзгәртелгән шартларда уңышлы кулланылышын тәэмин итә» [2: 39]. Күп кенә хезмәтләрдә дидактик коммуникациянең төп бурычы буларак укучыларның танып белү активлыгын үстерүгә ирешү танылa [6: 9]. Әмма бүгенге көндә укытучы һәм укучыларның дәрестәге аралашуның вазифаларын, танып белү активлыгы үсешенең әһәмиятен таныган хәлдә дә шуның белән генә чикләп булмый. Бүген укытучы һәм укучы аралашу сыйфатын белем бирүнең шушы субъектларының бер-берләренә карата ышанычы, бер-берләренә ихтирамлы карашлары, аралашу нәтиҗәсендә укучының әхлакый кыйммәтләрне үзләштерүе, социаль тәҗрибәсе арту кебек күрсәткечләр дә билгели.

Замана укытучысы коммуникация коруда чор үзенчәлекләрен, укучыларның яшь үзенчәлекләрен, XXI гасыр баласының психологиясен истә тотарга тиеш. Сторителлинг – коммуникация коруның заманча инструменты, чарасы, аралашу технологиясе. Сүзнең мәгънәсе аның инглиз теленнән тәрҗемәсе

белән туры килә: сторителлинг нинди дә булса вакыйга турында хикәяләп сөйләп бирү дигәнне аңлата. Сторителлинг бик күп өлкәләрдә кулланыла, фәнни әдәбиятта ассызыклаганча, бу да заман таләбе белән аңлатыла: мәгълүмат бик күп булган, даими алмашынып торган заманда кеше текстка игътибар итсен өчен, аны ничек тә кызыксындырырга, игътибарын җәлеп итәргә кирәк [10].

Шунысы кызык, белгечләр мондый технологияне хәтта математика дәресләрендә куллану мөмкинлекләрен ассызыклыйлар [4]. Әдәби уку дәресләрендә исә, әсәрнең эчтәлегенә бәйле рәвештә мондый аралашу оештыру мөмкинлекләре аеруча күп. Күзәтүебез күрсәткәнчә, «Мәгариф – Вакыт» нәшриятында басылган «Әдәби уку» дәреслекләре бу яктан чын таяныч булып тора ала. Г. М. Сафиуллина, Ф. Ф. Хәсәнова, М. Я. Гарифуллина, Ә. Г. Мөхәммәтҗанова авторлыгындагы 1 нче сыйныф дәреслеге (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучыларга тәкъдим ителә) маҗара-сәяхәт рәвешендә төзелгән. Дәреслекнең беренче бүлеге шул рәвешле «Сәяхәткә чыгу» дигән исем астында тәкъдим ителә дә [7: 3]. Дәреслекнең мондый төзелеше – татар әдәбияты, әдәби уку дәресләрен оештыруда методик яңалык булып тора. моңарчы шушы рәвешле корылган дәреслекләр буенча эшләү эше гамәлгә куелмый, гомумән, мондый дәреслекләр язылмый иде. Укучыны дәреслекнең беренче битеннән Әмир белән Әминә дигән балаларның маҗаралары артыннан күзәтеп, шушы маҗаралар юлында үзләре дә теоретик материалны үзләштерәләр, әдәби дөньяга юл ачалар. Башлангыч сыйныф укучылары маҗара геройлары белән бергә «сәяхәт итәләр», юлдагы авырлыкларны җиңәргә өйрәнәләр, белем туплыйлар. Әмир белән Әминә – укучыларның яшьтәшләре, белем юлына яңа аяк басучы балалар, шуңа күрә аларның кичерешләре укучыларга якын. Дәреслек авторлары әкияткә хас сюжет элементларын кертсәләр дә (хикәядә Ябалак, Төлке кебек геройлар балалар белән иркен аралаша), вакыйгалар чынбырлыкка якын тора: балалар китапханәгә керәләр, биредәге тәртипләр белән танышалар.

Шунысы кызык: дәреслек геройлары бу маҗарага укучыларны да җәлеп итәләр. Еш кына алар геройларның гамәлләренә, сүзләренә бәя бирүче булып торалар. Мәсәлән, «Песәй» татар халык әкиятен укыгач, Әмир әкият героен куркак дип атый, ә Әминә батыр дигән бәя бирә. Дәреслек авторлары укучыларга мөрәҗәгать итә: «Ә син ничек уйлыйсың?» [8: 18]. Укытучы, дәреслектәге шушы үзенчәлеккә таянып эш иткән очракта, чын дидактик коммуникациягә ирешә ала: бу очракта укучылар белем, күнекмәләрне дә үзләштерәләр, таныш-белү юлында очраган киртәләр җимерелә, белем, мәгълүмат туплауда, аларны эшкәртүдә укытучы һәм укучылар партнерлар – тигез дәрәҗәдәге хезмәттәшләр буларак эшли башлыйлар, ягъни галимнәр дидактик коммуникациягә хас буларак билгеләгән вазифалар үтәлә [1: 74].

Рус мәктәпләрендә татар төркемнәрендә укучыларга атап төзелгән дәреслекләр традицион шәкелдә язылган, әмма тәкъдим ителгән тема, сораулар, биремнәр ярдәмендә дә уңышлы дидактик коммуникация кору мөмкинлекләре күп. Мисал китерик. 1 нче сыйныф укучыларына Ж. Тәрҗемановның «Табигать китабы» шигыре тәкъдим ителә:

Әйдәгез, урманга
Һәм кырга
Табигать китабын
Укырга.
Бу китап гаять зур,
Гаять бай.

Анда бар:
Җир,
Су,
Күк,
Кояш,
Ай [3: 57].

Дәреслек авторлары әлеге шигырьгә кагылышлы рәвештә ике сорау тәкъдим итәләр: шуларның беренчесе әсәрнең исеме, эчтәлеге белән бәйле (шигырьнең исемен атау һәм автор кулланган чагыштыруның нигезен (табигать – китап) табу). Икенче сорау болай яңгырый: «Табигатьтән нәрсәгә өйрәнергә мөмкин? Шул турыда фикерлә» [3: 57]. Безнеңчә, укытучы беренче сорауга формаль җавап белән канәгатьләнмәскә, укучыларны фикерләрне дәлилле итеп җиткерергә өйрәтергә тиеш: һәр чагыштыруның нигезе була. Табигать белән китап арасында охшашлык исә түбәндәге җирлектә хасил була: икесе дә кешеләр өчен юнәлеш бирүче дус, белем чыганагы булып тора, китап күрсәткән юл буенча атлаганда, тормышта начарлыкка, ямьсезлеккә урын калмаячак. Укучылар шуңа да игътибар итә алалар: Җ. Тәрҗеманов, табигать һәм китап арасындагы охшашлыкны ассызыклап, табигать җисемнәрен һәрберсен аерым тезмә итеп яза: Җир, Су һ.б., ягъни шагыйрь аталган һәр җисемнең китапның аерым бүлеге булуын ассызыклый. Аннары инде, укучы һәм укытучылар арасында «Минем табигатьтән алган дәресем» (ул дәреслектәге икенче сорауга җавапны алмаштыра) темасына әңгәмә-диалог оештырырга була. Укытучы юнәлеш бирүче сораулар, киңәшләр бирә ала, бер үк күренештән төрле, әмма һәрвакытта да файдалы киңәш, дәрес алу мөмкинлеген кисәтә. Әйтик, укучылар көз ел фасылы, көзге күренешләр турында уйлана алалар. Кемдер мондый сабак ала: байлык – вакытлыча күренеш, мал, мөлкәт барсы да ахыр чиктә тузанга, чүпкә әверелә, иясенә мәңге хезмәт итми. Көзен каеннар, өрәңге-усаклар ничек тырышып алтын киемнәрен кисәләр дә, ахыр чиктә усал җил аларны рәхимсез рәвештә тартып ала, җил белән очмаган яфраклар да карала, ямьсезләнә, җиргә түшәлә. Икенче укучы исә яфракларның көзен шәрәләнеп, моңаеп калуларын кеше күңелендәге ямансулык белән чагыштыра ала. Агачларның яз сан яңадан җанлануын, сусыл яшел яфраклар белән каплануын истә тотып, тормыштагы күңелсез, авыр минутларның вакытлыча булуын искәртә, дигән фикергә килә укучы. Шулай ук балаларын яратып ашатучы, очарга өйрәтүче кошлар, тырыш кырмыскалар, һәр кешегә дә нурын тигез таратучы Кояш һ.б. табигать җисемнәре күпме сабак бирә кешегә! Укучылар дәрестә, шул рәвешле, укытучы ярдәмендә әсәрне өйрәнүдә анда яшеренгән тирән мәгънәләрне дә эзләргә, аңларга, әсәрдәге фикерне үз тормыш тәҗрибәсе белән расларга яки инкарь итәргә өйрәнәләр. Болар барысы да дидактик коммуникация нәтиҗәсендә тормышка ашырыла. Ә инде дәрестәге диалог бары предметка турыдан-туры кагылган юнәлештә генә алып барылса, дәрестә укытучы сөйләме өстенлек итеп, укытучы әсәрнең темасы, геройларын, автор позициясен аңлату белән чикләнсә, дәреснең белем бирү һәм тәрбияви кыйммәте күпкә кими.

Нәтиҗә ясап, түбәндәге аспектларга игътибар юнәлтергә кирәк, дип уйлыйбыз: коммуникатив якын килүгә нигезләнеп укыту белән укытучының коммуникатив компетенциясенә таләпләр арта. Ул белем бирүче генә түгел, укучы белән аралашучы өлкән дус, юл күрсәтүче буларак та кабул ителә. Дәрестә укытучы һәм укучылар арасындагы аралашу, беренчедән, танып белү активлыгы үсешенә хезмәт итәргә, икенчедән, укучыларның социаль тәҗрибәсе, шәхес буларак үсешенә хезмәт итәргә тиеш. Әдәби уку дәреслә-

рендә диалогик принципка нигезләнү, сторителлинг кебек техникаларның кулланылышы уңышлы нәтиҗәгә китерә ала.

ӘДӘБИЯТ

1. Арпентьева (Минигалиева) М. Р. Разработка интегративной модели дидактической коммуникации и понимание // Вестник Костромского государственного университета им. Н. А. Некрасова. Сер. Педагогика, психология, социальная работа, ювенология, социокинетика. – 2014. – Т. 20. – № 3. – С. 73–78.

2. Арпентьева М. Р. Форсайт образования: «человек служебный» и «человек этический» как цели образования XXI века // Форсайт образования: ценности, модели и технологии дидактической коммуникации XXI века: коллективная монография. Торонто, 2018. – С. 12–21.

3. Гарифуллина Ф. Ф., Мияссарова И. Х. Әдәби уку: рус телендә башл. гомуми белем бирү оешмалары өчен д-лек. 1 с-ф. – Казан: Мәгариф – Вакыт, 2017. – 87 б.

4. Забелина С. Б., Середа Т. Ю. Сторителлинг как эффективная техника дидактической коммуникации на уроках математики // Вестник Московского государственного областного университета. Сер. Педагогика. – 2020. – № 4. – С. 30–37.

5. Карпова М. А. Специфика коммуникативной компетентности учителя начальных классов // Гаудеамус. – 2016. – Т. 15. – № 4. – С. 88–92.

6. Левитан К. М. Культура педагогического общения. – Иркутск: Изд-во Иркут. ун-та, 1985. – 102 с.

7. Сафиуллина Г. М., Гарифуллина М. Я., Мөхәммәтҗанова А. Г., Хәсәнова Ф. Ф. Әдәби уку. Туган телдә башлангыч гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен д-лек. 1 с-ф. Ике кисәктә. 1 нче кис. – Казан: Мәгариф – Вакыт, 2017. – 80 б.

8. Сафиуллина Г. М., Гарифуллина М. Я., Мөхәммәтҗанова А. Г., Хәсәнова Ф. Ф. Туган телдә башлангыч гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен д-лек. 1 с-ф. Ике кисәктә. 2 нче кис. – Казан: Мәгариф – Вакыт, 2017. – 80 б.

9. Стефанова М. Дидактическая коммуникация (методические рекомендации в помощь учителю начальных классов). – Челябинск: ЧИПКРО, 1990. – 48 с.

10. Челнокова Е. А., Казначаева С. Н. и др. Сторителлинг как технология эффективных коммуникаций // Перспективы науки и образования. – 2017. – № 5. – С. 7–12.

## САМОУЧИТЕЛИ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА В 1920 ГОДЫ

**З. Н. Кириллова**

*Казанский федеральный университет, Россия*

zkirillova@yandex.ru

## SELF-TEACHERS OF THE TATAR LANGUAGE IN THE 1920s

**Z. N. Kirillova**

*Kazan Federal University, Russia*

zkirillova@yandex.ru

В данной работе исследуются самоучители татарского языка, составленные в 1920-е гг. Фатихом Сайфи и Ахметхади Максуди. В результате анализа были выявлены особенности работ «Самоучитель татаро-башкирского языка или руководство научиться без помощи учителя читать, писать и говорить по-татаро-башкирски» Ф. Сайфи (1923 г.) и «Татарстан. Самоучитель татарского языка для русских, составленный по индуктивному методу и десятичной системе» А. Максуди (1926 г.).

**Ключевые слова:** татарский язык, самоучители, Ф. Сайфи, А. Максуди, индуктивный метод.

This work explores the self-teachers of the Tatar language, compiled in the 1920s by Fatih Saifi and Ahmethadi Maksudi. As a result of the analysis, the features of the works «Self-teacher of the Tatar-Bashkir language or leadership to learn to read, write and speak Tatar-Bashkir without the help of a teacher» F. Sayfi (1923) and «Tatarstan. Self-teacher of the Tatar language for Russians, compiled according to the inductive method and decimal system» A. Maksudi (1926).
**Key words:** Tatar language, self-teachers, F. Saifi, A. Maksudi, inductive method.

## 1920 ЕЛЛАРДА ТАТАР ТЕЛЕННӘН ҮЗӨЙРӘТКЕЧЛӘР

**З. Н. Кириллова**

1921 елда татар теле беренче тапкыр рәсми рәвештә рус теле белән тигез дәрәҗәдәге дәүләт теле итеп игълан ителгәннән соң, аны иҗтимагый тормышның барлык өлкәләрендә дә куллану буенча киң эш җәелеп китә. Мәгариф комиссариаты карамагындагы төрле тип уку йортларында татар теле укытыла [1: 11]. Татарстанның күпчелек үзәк оешмаларында һәм кантоннарда рус хезмәткәрләрен татар теленә өйрәтү курс-түгәрәкләре оештырыла [2: 173]. Шул ук вакытта татар телен үзлегеннән өйрәнүчеләр өчен кулланмалар бастыру да максат итеп куела.

XX гасырның 20 нче елларында төзелгән үзөйрәткечләрнең саны күп түгел: бары Ф. Сәйфи [5] һәм Ә. Максуди [4] хезмәтләрен күрсәтергә мөмкин.

Ф. Сәйфинең «Самоучитель татаро-башкирского языка или руководство научиться без помощи учителя читать, писать и говорить по-татаро-башкирски» дип аталган үзөйрәткече 1923 елда Уфада басылып чыга. Исеменнән күренгәнчә, үзөйрәткеч татар һәм башкорт телләрен өйрәтү максатын күздә тотып язылган, әмма анда башкорт теле өчен хас үзенчәлекле авазлар чагылыш тапмый. Хезмәт түбәндәге бүленешкә ия: «Хәрефләр турында», «Уку һәм язу буенча күнегүләр», «Тормышта күбрәк кулланыла торган сүзләр», «Уку һәм сөйләшү» һәм аерым текстлар тупланган бүлек.

Беренче бүлектә (3–9 б.) татар алфавитындагы хәрефләргә һәм аларның әйтелешенә аңлатма бирелә, аерым алганда, хәрефләр язылышының тулы һәм кыска формалары, сузык һәм тартык авазларның әйтелеш үзенчәлекләре (автор аларны хәрефләрнең әйтелеше дип бирә. – *З. К.*) рус телендәге авазлар белән чагыштырыла, ике очракта алман телендәге авазлар белән дә тәңгәллек үткәрелә. Авазларның әйтелеше буенча каршылык тудыра торган фикерләре дә урын ала. Мәсәлән, ә авазын рус телендәге э һәм я хәрефләре уртасында кебегрәк әйтелешле, ү авазын – рус телендәге у һәм ю кебек әйтелешле дип билгеләве һ.б.

Икенче бүлек (9–17 б.) уку һәм язу буенча күнегүләргә багышлана. 10 төркемгә берләштерелеп, башта татарча сүзләрнең кириллицадагы язылышы, җәя эчендә русчага тәрҗемәләре һәм ахырда аларның гарәп шрифтындагы язылышы бирелә. Әлеге сүзлекчәдән соң шул сүзләр белән гарәп язуында сүтезмәләр яки кыска җөмләләр төзелә, аннары аларның русчага тәрҗемәсе урын ала. Сүзләр теге яки бу тематик төркемчәгә берләштерелмәгән, сүтезмә һәм җөмләләр дә мәгънәләре ягыннан бер-берсеннән бик нык аерыла. Мәсәлән: *Кар аз. Ат ара. Кара каш. Аксак каз. Тар такта. Кара сарык. Артка кара. Ата ат сата. Карт кашык сата* [5: 10]. Сүзләр-

нең кирилл хәрефләре белән язылышы күбесенчә рус телендәге хәрефләргә җайлаштырылып эшләнгән. Мәсәлән: *унг (правый), джийылыш (собрание)* һ.б. Рус телендә булмаган үзенчәлекле сузыкларны бирү өчен, өске билгеләр кулланылган: *хǎм (и), кўгǎрчэнь (голубь)* һ.б. Сүзләрнең язылышында сорау тудыра торган урыннар да бар. Мәсәлән: *уким (читаю), бўгхнь (сегодня), кузгэ (зеркало)* һ.б.

Өченче бүлектә (17–35 б.) тормышта аеруча еш кулланыла торган сүзләр тематик төркемнәргә тупланып бирелгән. Барлыгы 17 төркем урын ала: «Үлчәү һәм саннар», «Вакытны күрсәтү», «Кеше», «Әгъзалар», «Киемсалым», «Ашамлык-эчемлек», «Йорт һәм йорт хуҗалыгында кирәкле нәрсәләр», «Мәктәп һәм уку әсбаплары», «Дөнья һәм табигать үзгәрешләре», «Авыл көн күреше», «Хайваннар», «Кошлар», «Шуышып йөри торган хайваннар һәм хәшәрәтләр», «Агачлар һәм җимешләр», «Кәсеп вә һөнәрләр», «Мәгъдәнләр (металл һәм минераллар)», «Сәүдә вә сәнәгать һәм мәдәният». Болардан тыш, еш кулланыла торган сыйфат һәм фигыльләр 18–28 нче төркемнәргә туплап бирелгән.

Дүртенче бүлек «Чтение и разговор» дип исемләнгән (35–39 б.) һәм, 7 төркемгә берләштерелеп, башта гарәп шрифтындагы җөмләләр, аннары аларның русчага тәрҗемәләре бирелгән. Җөмләләр билгеле бер тематик бүленешкә нигезләнмәгән, араларында татар халык мәкаль-әйтемнәре дә очрый.

Бишенче бүлектә (39–47 б.) кечкенә хикәяләр, аерым алганда, «Торна белән төлке», «Ярлы кеше белән төлке», «Мулла» хикәяләре, Г.Тукайның «Шүрәле» поэмасыннан өзек, шулай ук мәкальләр, табышмаклар һәм кыска җырлар да тәкъдим ителгән. Бу бүлектә дә текстларның русчага тәрҗемәләре биреп барыла.

Үзөйрәткечтә рус телендәге кайбер сүз һәм терминнарның язылышында шактый күп хата күзәтелә. Мәсәлән: *светок, былизкий, пиштся, курглый, яболоко, пило; неударенный, гортаныный* һ.б. Болар, әлбәттә, хезмәтнең тиешенчә эшләнеп бетмәве турында сөйли. Шулай ук татар авазларының әйтелешен күрсәтүдәге төгәлсезлекләр, хезмәтнең билгеле бер система яки методик принципка нигезләнеп төзелмәве дә үзөйрәткечнең гамәли әһәмиятен киметә.

Ә. Максудиның «Татарстан. Самоучитель татарского языка для русских, составленный по индуктивному методу и десятичной системе» дип аталган үзөйрәткеченең икенче басмасы 1926 елда Казанда басылып чыга, ә беренче басмасының елы билгеле түгел.

Кулланманың индуктив методка нигезләнүен автор «Сүз башы»нда болай дип аңлата: «Методның индуктивлыгы шуннан гыйбарәт: укучыларга башта телнең грамматик кагыйдәләре түгел, ә сүзләр һәм типик фразалар бирелә. Фразалар шундый комбинациядә төзелгән ки, сүзләрнең грамматик үзгәрешләрендәге каршылыкларны яки тәңгәллекләрне чагыштырып, укучылар үзләре төшенәләр, ягъни тел кагыйдәләре хакында индуктив нәтиҗәләр ясыйлар» [4: 3].

Үзөйрәткечнең унлы системага корылуы түбәндәгечә аңлатыла: «Дәресләр шундый тәртиптә урнашкан: аларның һәрберсе, 11 дәрестән алып китапның ахырына кадәр, бер үк номерда булган алдагы дәресләрнең эчтәлегенә өстәмә яки аларны киңәйтү булып тора. Мәсәлән, 11 дәрес – 1 нче дәресне, 21 – 11, 31 – 21 һ.б.» [4: 3]. Шул рәвешчә, әлеге үзөйрәткечнең бер үк номерлы һәр ун дәресе грамматиканың билгеле бер темаларына кагылышлы бер бөтен система тәшкил итә. Укучылар да, 11 дәрестән башлап, һәр дәресне

узар алдыннан, шул ук номердагы дәресләрне кабатлап алырга тиеш булалар. Ә. Максуди үзе дә: «Шунда ук ун тапкыр кабатланган предмет якынча һәр ун көн саен өч тапкыр кабатланганына караганда тизрәк онытыла» [4: 3], – дип басым ясый.

Үзөйрәткечнең төзелеше түбәндәгедән гыйбарәт: русча-татарча әлифба, дәресләр һәм сүзлек. Башта татар хәрефләре һәм авазлары, басым, авазларның кайбер үзенчәлекләре хакында мәгълүмат бирелә, моннан соң «Русча-татарча сүзләр» исеме белән ике телдә дә кулланылган 118 сүз урын ала. Мәсәлән: татар, базар, фазан, Кабан, лабаз, сарай, калач, заказ, сазан һ.б. [4: 11]. Сүзләрнең гарәп шрифтындагы язылышы янында татарча әйтелешкә нигезләнгән кириллицадагы чагылышы да урын ала. Аерым бер биттә рус исемнәре дә туплап бирелә [4: 14]. Шуннан соң гына үзөйрәткечтә дәресләр урын ала. Аларның төзелеше нигездә бер үк: калын хәрефләр белән гарәп шрифтында язылган яңа сүзләр, аларның русчага тәрҗемәләре бирелә; әлеге сүзләр белән күп санлы диалоглар һәм (яки) аерым җөмләләр тәкъдим ителә, аларның русчага тәрҗемәләрен бирү кирәк дип табылмый, чөнки алар бик гади һәм аңлаешлы; кайбер дәресләрдә генә бер төркем сүзтезмә яки җөмләләрнең русчага тәрҗемәләре дә параллель рәвештә бирелә; дәрес ахырында күбрәк рус теленнән татарчага тәрҗемә итүгә багышланган бирем урын ала. Гадәттә, үзөйрәткечтә грамматикадан кагыйдәләр, теоретик материал күзәтелми, бу тел өйрәнүчеләргә мөстәкыйль рәвештә нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә, бары бик сирәк очракта гына теге яки бу күренешкә аңлатма урын ала.

Без әле муниципаль күләмдә үткәрелә торган «Сәлам, Тукай!» квестын оештыручылар да. Бу уен-бәйге ел саен апрель аенда Шигърият көннәре кысаларында уздырыла. Квест-уенның төп максаты – милли мирасны саклау, татар теленең даирәсен киңәйтү, укучыларның иҗадилыгын арттыру. Уенның программасы бик күп иҗади биремле һәм Тукай иҗаты белән бәйле. Квестта Әлмәт шәһәренең төрле мәктәпләреннән 5 җыелма команда катнаша.

Горурланып сөйләрлек тагын бер зур уңышыбыз бар. 2019 ел – Театр елы уңаеннан «Асылташ» татар теле укытучылары иҗади төркеме Әлмәт мәгариф идарәсе, Әлмәт драма театры оештырган «Театр – мәгърифәтнең көзгесе» исемле конкурсында катнаштык. Нигезләмәнең бөтен шартларына туры китереп, Т. Миңнуллинның «Әниләр һәм бәбиләр» әсәреннән бер өзек алынды. Әлеге өзекне Әлмәт татар дәүләт драма театры сәхнәсендә уйнап, III дәрәҗә дипломга лаек булдык.

2021 «Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы» җиңүләргә бай булды. 2 нче лицей «Поддержка муниципальных дошкольных образовательных организаций и муниципальных общеобразовательных организаций в реализации проектов, направленных на сохранение и развитие языков, традиций, культур народов, проживающих на территории РТ, в рамках Года родных языков и народного единства» проекты җиңүчесе булды.

Йомгак ясап, шуны әйтәсе килә: туган телне өйрәнүдә югары нәтиҗәләргә бары үз эшенең остасы булган, заман белән бергә атлап, аның казанышларын актив куллана торган педагогик кадрлар булганда, укучыларны кызыктыру алымнары уңышлы кулланылганда, әлбәттә, һичшиксез ирешергә була.

ӘДӘБИЯТ

1. Шәймәрданов Р. Х., Хуҗиәхмәтов Ә. Н. Татар милли педагогикасы. – Казан: Мәгариф, 2007.

2. Степанов П. В. Внеурочная деятельность школьников: методический конструктор. – М.: Просвещение, 2010.

## ИЗУЧЕНИЕ КРИТИЧЕСКОЙ И ПУБЛИЦИСТИЧЕСКОЙ ДЕЯТЕЛЬНОСТИ ПИСАТЕЛЯ НА УРОКАХ ЛИТЕРАТУРЫ
## (на примере деятельности Р. Сибата)

**А. Р. Мотигуллина**

*Поволжский государственный университет физической культуры, спорта и туризма, Россия*
alfiya311065@mail.ru

## THE STUDY OF THE CRITICAL AND JOURNALISTIC ACTIVITY OF THE WRITER IN LITERATURE LESSONS
## (on the example of R. Sibat’s activity)

**A. R. Motigullina**

*Privolzhsky State University of Physical Culture, Sports and Tourism, Russia*
alfiya311065@mail.ru

В статье рассматриваются приемы изучения критических и публицистических статей на примере деятельности Рафаэля Сибата. Особое внимание уделяется жанро-

вому разнообразию его статей, эссе, литературных портретов и монографических исследований. Также учащиеся во время обзорных тем, исследуя деятельность талантливого критика и публициста, учатся анализу литературного процесса. Тем самым глубже проникают в проблемы татарской литературы конца XX века.
**Ключевые слова:** татарская литература, критика, публицистика, литературный процесс, эссе, литературный портрет, статья.

The article discusses the methods of studying critical and journalistic articles on the example of the activities of Raphael Sibat. Particular attention is paid to the genre diversity of his articles, essays, literary portraits and monographic studies. Also, students during review topics, exploring the activities of a talented critic and publicist, learn to analyze the literary process. Thus, they penetrate deeper into the problems of Tatar literature of the late twentieth century.
**Key words:** тatar literature, criticism, journalism, literary process, essay, literary portrait, article.

## ӘДӘБИЯТ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ЯЗУЧЫНЫҢ ТӘНКЫЙДИ ҺӘМ ПУБЛИЦИСТИК ЭШЧӘНЛЕГЕН ӨЙРӘНҮ ЮНӘЛЕШЛӘРЕ

### (Р. Сибат эшчәнлеге мисалында)

**Ә. Р. Мотыйгуллина**

Әдәби әсәрне аңлау, бәяләү язучының шәхси лабораториясеннән башка күзаллана алмый. Гәрчә урта белем алу системасында тәнкыйди эшчәнлекне өйрәнү эше чикле булса да, өстәмә белем бирү рәвешендә генә булса да әдип эшчәнлегендә зур урын алып торган, аның иҗтимагый-мәдәни карашларын ачыклауга нигезләнгән, шәхси мөнәсәбәтен билгеләгән якны читтә калдыру мөмкин түгел [2].

Күзәтү дәресләрендә XX гасыр икенче яртысында әдәби барышны бәяләү вакытында әдәби тәнкыйть һәм публцистика өлкәсендә актив эшләгән прозаик Р. Сибат читләтеп үтеп булмый. Язучының мәкаләләрендә, язмаларында, хезмәтләрендә иҗтимагый, гуманистик һәм эстетик карашлары чагылыш таба.

Укучылар белән эшләү вакытында әдипнең тәнкыйди-публицистик эшчәнлеген берничә юнәлешкә бүлеп мөмкинлеген ачыклыйбыз: беренчесе – әдәби портретлар язу осталыгы. Р. Сибатның әдәби портретлар галлереясе киңкырлы: Мөхәммәт Мәһдиев, Рудольф Нуриев, Асия Юнысова, Дамир Хәйруллин һ.б. Ул әлеге шәхесләрнең аерым сыйфатларын ачарга омтыла, аларның татар халкына күрсәткән хезмәтләрен бәяли.

Р. Сибатның әдәби портретларына түбәндәге сыйфатлар хас: ул үзе сурәтләгән шәхесләрнең иҗатын югары күтәрү максатын куймый, бары тик гуманистик сыйфатларының иҗатларында чагылышын күрсәтә.

Р. Сибатның тәнкыйди-публицистик эшчәнлегенең икенче юнәлеше – тәнкыйди-биографик очерклар. Аларда теге яки бу әдип иҗатына бәя тормыш юлы белән тыгыз үреп бирелә. Әмма биографик фактларны барлау үзмаксат булып тормый, игътибар үзәгендә иҗат үзенчәлекләре, аерым тема-мотивлар, мәсьәләләр, дөньяга караш һ.б. язучы биографиясе призмасы аша чагыла [1: 155].

Әйтик, Рашат Низаминың юбилее уңаеннан язылган «Рашатка без шат!» очеркында иҗатка шагыйрь булып килеп кергән әдипнең прозага борылуын күрсәтеп, Р. Сибат аны «романтик рухлы реалист» дип атый һәм прозасында лирик башлангычның көчле булып калуын ассызыклый [6].

Р. Сибатның эшчәнлегенең өченче юнәлешен публицистиканың эссе жанры. Эссены әдип лирик һәм публицистик чигенешләр, истәлек-мемуарлар белән үреп бирә.

«Әдәбиятыбыз Ахуны» эссесында Х.Туфан, С. Хәкимнәрдән соң татар әдәбиятында рухи остазларның берсе булып калган Гариф Ахунов иҗаты яктыртыла [6]. Тәнкыйтьче Гариф Ахуновның туры сүзле, сабыр, тырыш һәм үҗәт булуына соклана [7: 147].

Р. Сибат эсселарында әдипләрнең эшчәнлеген бәяләү критерие итеп милли рухны ачуга йөз тотып, Аяз Гыйләҗев, Рәдиф Гаташ, Рауль Мирхәйдәров, Газинур Морат һ.б. иҗади сыйфатлары ягыннан яктыртыла. Аяз Гыйләҗев – Яшәү һәм Үлем, Яхшылык һәм Яманлык, Матурлык һәм Ямьсезлек турында үз «Дога»сын иҗат итүче; Роберт Әхмәтҗан – сүзләр ярдәмендә матурлык тудыручы, тормышның ямьсез якларын кагылып та матурлык эзләүче; Айдар Хәлим – кискен, фидакарь, усал, тугры, көрәшче; Рауль Мирхәйдәров – татар җанлы; Газинур Морат – фәлсәфи тирәнлеккә ия иҗат әһеле; Мөхәммәт Мәһдиев – пәйгамбәрләрчә бөек, олпат, олы мәгънәле язучы буларак ачыла. Р. Сибат эсселарында лирик һәм фәлсәфи чигенешләр бик зур урын алып тора.

Р. Сибат игътибар иткән әдәби тәнкыйть жанрларының дүртенчесе – рецензияләр. Аның үрнәген тәнкыйтьченең Зөлфәт Хәкимнең «Гөнаһ» романына язылган рецензиясендә күрәбез [3]. Ул аны Кафканың «Замок» әсәре белән чагыштыра. Уртак яклар дип кешеләрдәге фаҗига, көчсезлек, курку, чарасызлык мотивларын күрсәтә.

Р. Сибат тәнкыйтендә аерым урынны (бишенче) монографик мәкаләләр алып тора. Р. Сибатның монографик мәкаләсенә мисал Равил Фәйзуллинның өч томлыгын укыгач туган «Өчтомлыкны укыгач өч сүз» мәкаләсен китерергә мөмкин.

Р. Сибат шагыйрьнең ирекле шигырьләрен татар әдәбияты үсешендә яңа баскыч буларак бәяли. Ул поэзиянең иҗтимагый-сәяси вазифаларын актуальләштерә, үз сүзен әйтеп бирә алган, үз сукмагы белән киткән яшь шагыйрьнең татар поэзиясен озак еллар дәвамында кысып тоткан кануннардан азат булуын үзенә үрнәк итеп ала. Р. Сибат бу мәкаләсендә шагыйрьнең шактый гына нюансларын цитата итеп китерә, аларның бертөсле, озын-ялыктыргыч шигырьләрдән соң яңа сулыш булуын билгели. «Кемгә ничектер, бер карaганда, салкын акыл белән хиссез генә язылган тәгъбирләргә охшасалар да, мин аларда эчке энергия – Җан җылысы тоям. Юк, болар уй-хиссез генә туган юллар түгел!» [4: 136].

Тәнкыйтьченең фикерләре чагылган тагын бер юнәлеш – әдәби процессны бәяләү. Әдипнең тәнкыйди язмаларының бер өлешен әдәби барышның аерым чорын, аның үсеш закончалыкларын һәм тенденцияләрен бәяләү тәшкил итә.

«Бүгенге прозаның нинди җитешсезлекләрен күрәсез? Аларның сәбәбе нәрсәдә дип уйлыйсыз?» дигән сорауга Р. Сибат тезислар формасында җавап бирә һәм шул чор прозасының төп кимчелекләре дип түбәндәгеләрне санап күрсәтә: а) әдипләрнең кайберләре «үз корсагыннан югарырак фикердә тора алмавы», ә бит әдәбиятның иң беренче максаты – кешенең Җанын, Рухын дәвалау; ә) әдәбиятта тулы бер Татар Әдәбияты Концепциясенең тудырылмавы, ягъни сүз сәнгатенең, шул исәптән прозаның да шәрык белән гареб арасында бәргәләнүе, үз юлын билгели алмавы; б) прозаның артык «реаль-тормышчан» булуы; Р. Сибат прозада Ә. Баян кебек лирик-романтик, сентименталь әсәрләр тудыра алырлык шәхесләрне күрергә тели; в) прозаның каты телле, коры булуы, татар теленең сыгылмалылыгын, нәфислеген, гаять колачлы икәнлеген, байлыгын, бөеклеген сөйләп торган әсәрләрнең булмавы; г) әдипләрнең тормыш мәшәкатьләрен кайгыртырга мәҗбүр булулары, ә матди проблемалар иҗат дәртен сүрелдерә, язарга вакыт калдырмый; д) прозаның «картаюы»,

яшьләрнең аз килүе, булганнарының да җиң сызганып эшкә тотына алмаулары; е) язучылар арасында үзара рухи туганлык, эчке якынлык аз булу, яшерен хөсетлекнең үзен сиздерүе; ж) вакыт җилләренә буйсынып, иҗат мәсләкләренә хыянәт иткән, «хамелеон» язучыларның булуы; ж) тәнкыйтьнең сүлпәнәюе [5: 160]. Шулай итеп, Р. Сибат XX гасыр ахырында татар прозасының үсеш юлларын билгели, шул ук вакытта аның кимчелекләрен дә күрсәтеп бара.

Шул рәвешле, Р. Сибатның әдәби тәнкыйть һәм публицистика өлкәсендәге эшчәнлегенең юнәлешләрен ачыклап, аның төрле төрле жанрларда булуын күрсәтәбез. Аларда әдипнең иҗтимагый, фәлсәфи, эстетик карашлары чагылыш табуына басым ясыйбыз. Ә дәрестә тәнкыйди материал белән танышу укучыларның әдәби зәвыгын үсүгә, мәдәни күзаллавы киңәюгә, әхлак сыйфатларның камилләшүенә игътибар итә алабыз.


ӘДӘБИЯТ

1. Закирҗанов Ә. Яңарыш юлыннан (Хәзерге татар әдәбият белеме мәсьәләләре). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. – 303 б.

2. Леонов С.А. Изучение литературно-критических статей // Методика преподавания литературы: Учебник для студ. пед. вузов/ Под ред. О. Ю. Богдановой. – М., 1999. – С. 303.

3. Сибат Р. Зөлфәт Хәкимнең «Гөнаһ»ы, ягъни Төп Мәгънә // Ватаным Татарстан. – 1996. – 16 окт.

4. Сибат Р. Өчтомлылыкны укыгач өч сүз // Казан утлары. – 1996. – № 10. – Б. 133–148.

5. Сибат Р. Проза турында сөйләшү // Казан утлары. – 1997. – № 8. – Б. 158–160.

6. Сибат Р. Рашатка без шат! // Ватаным Татарстан. – 2000. – 3 март.

7. Сибат Р. Әдәбиятыбыз Ахуны // Казан утлары. – 2000. – № 9. – Б. 131–147.


## ОСОБЕННОСТИ ФОРМИРОВАНИЯ НАВЫКОВ ПОНИМАНИЯ С ПОМОЩЬЮ ВИДЕОМАТЕРИАЛОВ


**Г. Р. Мугтасимова**

*Казанский федеральный университет, Россия*
Gulnaz-72@mail.ru


## THE USE OF VIDEOS FOR THE FORMATION OF LISTENING SKILLS


**G. R. Mugtasimova**

*Kazan Federal University, Russia*
Gulnaz-72@mail.ru



В статье рассматривается проблема формирования навыков аудирования на старшем этапе обучения татарскому языку. Особое внимание уделено вопросам использования аутентичных видеоматериалов на уроках татарского языка. Автором обоснована важность использования видеоматериалов на уроках татарского языка, определен их дидактический потенциал, а также предложен комплекс упражнений на основе художественного фильма, направленный на формирование аудитивных навыков у обучающихся старших классов.


**Ключевые слова:** татарский язык, обучение, аудирование, навыки аудирования, видеоматериал, видеофильм.



The article deals with the problem of formation of listening skills at the senior stage of teaching the Tatar language. Special attention is paid to the use of authentic video materials in Tatar language lessons. The author substantiates the importance of using video materials in Tatar language lessons, determines their didactic potential, and also

offers a set of exercises based on a feature film aimed at the formation of auditory skills in high school students.
**Key words:** Tatar language, teaching, listening, listening skills, video material, video film.

## ВИДЕОМАТЕРИАЛЛАР ЯРДӘМЕНДӘ ТЫҢЛАП АҢЛАУ КҮНЕКМӘЛӘРЕ ФОРМАЛАШТЫРУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

**Г. Р. Мөгтәсимова**

Күп кенә белгечләр фикеренчә, иң авыры – сөйләшү һәм тыңлап аңлау күнекмәләрен үзләштерү. Тыңлап аңлау сөйләшү белән һәрвакыт янәшә. Тыңлап аңларга өйрәнмичә торып, сөйләшеп китеп булмый. Әлеге күнекмәләр уңышлы аралашуның алшартын тәшкил итә. Укучыларның тыңлап аңлау күнекмәләре, кагыйдә буларак, начар формалашкан була.

Шулай итеп, бу тема – татар теленә өйрәтү методикасында иң актуаль темаларның берсе, чөнки тыңлап аңлаудан башка сөйләшү, аралашу мөмкин түгел. Тыңлап аңлауны бәяләп бетермәү исә укучыларның тел әзерлегенә бик тискәре йогынты ясарга мөмкин. Моннан тыңлап аңлауга өйрәтү проблемасының мөһимлеге һәм актуальлеге ачык күренә. Хәзерге уку-укыту процессында тыңлап аңлауның күләмен һәм әһәмиятен арттырырга кирәк. Укучыларда татар телен өйрәнүгә карата теләк формалаштыру һәм уку материалын үзләштерүнең кабул ителерлек дәрәҗәсенә ирешү өчен, укытучы укыту процессына заманча алымнар, методлар һәм чаралар кертергә тиеш.

Укучыларны телдән сөйләмне аңларга өйрәтү – коммуникатив методикада татар теленә өйрәтүнең иң мөһим максатларының берсе. Сөйләм эшчәнлегенең әлеге үзенчәлекле төренә максатчан рәвештә өйрәтергә кирәк. Бу максатларга ирешүдә аутентик аудио- һәм видеоматериаллар зур әһәмияткә ия. Татар теле дәресләрендә төрле видеоматериаллар кулланырга мөмкин. Мәсәлән, реклама роликлары, танылган кешеләр белән әңгәмәләр, мультфильмнар, яңалыклар, документаль фильмнар, телетапшыруларның өзекләре һәм башка бик күп нәрсәләр. Төрле видеофильмнарны дәрестә куллану методикасы татарча сөйләмне иркен кабул итәргә һәм дөрес сөйләргә өйрәтә. Аудио һәм видео белән эшләгәндә, дәреснең туксан проценты сөйләшү практикасына нигезләнгән. Акрынлап, этаптан этапка таба сөйләм күнекмәләрен һәм тыңлап аңлауга өйрәтүнең эчтәлеген катлауландыру күздә тотыла.

Татар телендәге теләсә кайсы фильм уңайлы һәм нәтиҗәле дидактик материал була алыр иде. Мондый технологияләрне татар теле дәресләрендә куллану укучыларның сөйләм күнекмәләрен үстерергә булыша, сөйләмне тыңлап аңлауны һәм хәтта сүзләрне дөрес әйтергә өйрәтүне нәтиҗәле итә.

Фильм ул өстәмә мәгълүмат чыганагы гына түгел. Дәресләрдә мондый чараларны куллану укучыларның игътибарын һәм хәтерен ныгытуга йогынты ясый. Сыйныфта караганда, бергәләп танып белү эшчәнлеге даирәсе барлыкка килә. Бу вакытта фильмның мәгънәсен аңларга тырышып утырып, укучылар да игътибарлырак була. Шулай итеп, ирексез игътибар ирекле хәлгә күчә, ә игътибарның көче хәтергә тәэсир итә. Болар барысы да материалны истә калдыру дәрәҗәсенә уңай йогынты ясый.

Әмма фильмны кабызып куйдык та карап чыктык дип кенә уйлау дөрес булмас. Видеоматериалларны дәресләрдә куллану файда китерсен өчен, аларны бары тик карау гына җитми. Бу эшчәнлеккә алдан ныклап әзерләнергә кирәк. Иң элек сайланган фильмның укучыларның белем дәрәҗәсенә, программа һәм укыту планына туры килү килмәвен билгеләү уңышлы булыр иде. Фильмны укучыларга күрсәткәнче карап чыгып, лексик һәм грамматик яктан

анализларга, күрсәтү максатын ачыкларга да кирәк. Телдән фикер алышу яки инша язу яисә башка төрле эшләр күрсәтү максаты булып тора ала. Фильмны дидактик материал буларак кулланыуыбызны истән чыгармаска кирәк.

Әмма, тәҗрибә күрсәткәнчә, сыйныфта нәфис фильмны тулысынча карау нәтиҗәле түгел. Бу, беренче чиратта, фильмның озынлыгы 90 минут яки тагын күбрәк һәм тел мәгълүматы күләменең дә шактый булуына бәйле. Боларны бер дәрестә эшләп бетерү һич мөмкин түгел. Шуңа күрә нәфис фильмны өзекләргә бүлеп карау уңышлырак. Өзекләрнең эчтәлеге мәгънәсе буенча шартлы төгәлләнгән диалог яки персонажларның полилогларын тәшкил итәргә тиеш. Шул ук вакытта барлык нәфис фильмнарның да педагогик практика өчен яраклы булмавын онытмаска кирәк. Тыңлап аңлау компетенциясен булдыру практикасында кулланылырга мөмкин булган нәфис фильмнарны, аерым өзекләрне сайлаганда, кайбер критерийларны исәпкә алу уңышлы булыр иде. Мәсәлән, геройларның сөйләме хәзеге татар сөйләменә туры килергә, нәфис фильмның сюжеты реаль тормыш вакыйгаларын чагылдырырга, өзек персонажларның сөйләменә максималь дәрәҗәдә бай булырга тиеш.

Татар теле дәресләрендә нәфис фильмнарны куллану коммуникатив һәм аудитив компетенцияне нәтиҗәле формалаштыруга ярдәм итә дигән фәнни фаразның дөреслеген практикада тикшерү өчен, эксперимент уздырып карадык. Аның барышында «Инсаф» фильмына биремнәр эшләнде һәм тикшерелде. Режиссер Фәрит Дәүләтшинның «Инсаф» фильмы Рабит Батулланың «Кичер мине, әнкәй» пьесасына нигезләнеп төшерелгән. Бу картинада Бахчисарай авылында яшәүче малайның тарихы сурәтләнелә. Инсаф зур суммага лотерея ота. Әлеге хәбәр тирә-якка бик тиз таралып өлгерә. Шушы мизгелдән малайның тормыш юлы кинәттән яңа борылыш ала.

Барлык биремнәр барыннан да элек фильмның эчтәлеге һәм геройлар сөйләшә торган җанлы татар теле белән җентекләп танышуга юнәлтелгән. Моннан тыш, күп кенә күнегүләрнең лексикологик юнәлеше бар. Ул татар телендә күзәтелә торган кызыклы процессларга игътибарны юнәлтә.

Педагогик тәҗрибә барышында, фильмны караганчы, студентларга түбәндәге эшләр тәкъдим ителде: фильмның мәгънәсен аңлау өчен кирәк булган яки укытуның бу этабында файдалы булырга мөмкин яңа лексик берәмлекләр белән таныштыру, студентларны кызыксындыру, темага, фильм вәзгыятенә кертеп җибәрү, темага караган белемнәрне активлаштыру һәм башкалар. Шулай ук карар алдыннан фильмның исеме, төшерелгән елы һәм режиссеры турында да фикер алыштык. Нәкъ менә фильмны караганчы эшләнә торган биремнәр татар сөйләмен тыңлап кабул итү күнекмәләрен булдырырга һәм ныгытырга ярдәм итә.

Киләсе этап инде ул – фильмны карау. «Инсаф» фильмы 1 сәгать 14 минут дәвам итә, шуңа күрә без аны берничә өлешкә бүлеп карадык. Әгәр кыска метражлы фильм булса, аны тулысынча һәм, әлбәттә, бергә карау яхшырак. Бу этапта түбәндәге биремнәрне эшләп булыр иде. Мәсәлән, өзекне бер тапкыр карагач, рольләрне билгеләп һәм тавышны ябып куеп, экрандагы вакыйгаларны тавышландыру; иң кызыклы урында фильмны туктату һәм вакыйгаларның алга таба ни рәвешле дәвам итүе турында сөйләшеп алу. Тагын бер кызыклы бирем – фильмдагы геройларны тасвирлап бирү, ягъни студентлар персонажларның тышкы кыяфәте, характеры, гадәтләре турында сөйләргә тиеш.

Өченче этапның максаты – фильмны аңлауны тикшерү. Шул максаттан чыгып, фильмдагы проблемалы мәсьәләләр буенча гомуми фикер алышу үткәрелде. Әле тагын ошаган өзекне персонажларның берсе исеменнән сөйләргә дә мөмкин. Бу вакытта укучылар үз фикерләрен әйтергә, чагыштырырга, тәнкыйтьләргә, бәхәсләшергә, бер-берсе белән сөйләшергә өйрәнәләр.

Әлеге эксперимент күрсәткәнчә, «Инсаф» фильмы материалы белән эшләгәндә, студентлар үзләренең актив сүзлек байлыгын тулыландырдылар һәм ныгыттылар; проблемалы мәсьәләләр буенча фикер алышканда, телдән сөйләм күнекмәләре үсте.

Шулай итеп, татар теленә өйрәтү процессында видеоматериалларны куллану укытучы эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген сизелерлек арттырырга сәләтле, чөнки видеоматериаллар аутентик аралашуы үрнәкләрен тәшкил итә, реаль аралашу даирәсен тудыра, татар теле материалын үзләштерүне тагын да җанлырак, кызыклырак, проблемалы, ышандыргыч һәм эмоциональ итә.

Тыңлап аңлауга өйрәткәндә, төрле видеоматериалларны куллануның мөһимлеген ассызыкларга кирәк. Аларны куллану һәркем өчен аңлаешлы, кызыклы, нәтиҗәле, уңайлы белем бирү мохите булдыра, укучылар һәм укытучыларга иҗади яктан үсәргә мөмкинлек бирә, укучыларда татар телен өйрәнүгә теләк формалаштыра.


ӘДӘБИЯТ

1. Бричева М. М., Берсирова С. А., Нещеретова Т. Т., Сасина С. А., Схаляхо Е. Н. Использование художественных фильмов в процессе обучения иностранным языкам // The Scientific Heritage. – 2020. – S. 38–40.

2. Гуняшова Г. А. Использование видеоматериалов в обучении аудированию на уроке иностранного языка // Вестник КемГУ. – 2015. – № 2–3. – С. 34–37.

3. Фатхуллова К. С., Мугтасимова Г. Р. Укучыларның татар телендә аралашу осталыгын үстерү // Языки культуры в контексте исторического наследия: к 100-летию со дня рождения Э. Р. Тенишева : сб. ст. по материалам Всерос. науч.-практ. конф. (г. Пенза, 21–23 апреля 2021 г.) / под ред. Ж. З. Туктарова, В. Ф. Мухамеджановой, Г. Х. Самочкиной. – Пенза: Изд-во ПГУ, 2021. – С. 174–178.


## О СОВРЕМЕННЫХ УЧЕБНО-МЕТОДИЧЕСКИХ КОМПЛЕКСАХ ПО УЧЕБНОМУ ПРЕДМЕТУ «ЛИТЕРАТУРНОЕ ЧТЕНИЕ НА РОДНОМ (ТАТАРСКОМ) ЯЗЫКЕ»


**Г. Н. Мухарлямова, Д. М. Абдуллина**

*Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан, Россия*

*m*ukharlamgul@gmail.com, gibadullina_13@mail.ru


## ABOUT MODERN EDUCATIONAL AND METHODICAL COMPLEXES ON THE SUBJECT «LITERARY READING IN THE NATIVE (TATAR) LANGUAGE»


**G. N. Mukharlyamova, D. M. Abdullina**

*Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, Russia*

*mukharlamgul@gmail.com, gibadullina_13@mail.ru*



В статье рассматривается актуальная проблема национального образования – создание новых УМК по учебному предмету «Литературное чтение на родном (татарском) языке», в свете изменений в системе обучения родным языкам и литературам. Особенности, связанные с изменениями в обществе, в методике преподавания, в содержании учебного предмета находят отражение и в новых учебниках.



**Ключевые слова:** учебно-методический комплекс, компетенция, базовый уровень, углубленный уровень, учебник, сторителлинг.

The article deals with the actual problem of national education – the creation of new UMCS for the academic subject «Literary reading in the native (Tatar) language», in the light of changes in the system of teaching native languages and literatures. The peculiarities associated with changes in society, in teaching methods, in the content of the educational subject are reflected in new textbooks.
**Key words:** educational and methodical complex, competence, basic level, advanced level, textbook, storytelling.

## «ТУГАН (ТАТАР) ТЕЛДӘ ӘДӘБИ УКУ» ПРЕДМЕТЫ БУЕНЧА ЗАМАНЧА УКЫТУ-МЕТОДИК КОМПЛЕКСЛАРЫ ТУРЫНДА

**Г. Н. Мөхәрләмова, Д. М. Абдуллина**

Белем бирү системасында туган тел һәм туган телдәге әдәбиятны заман таләпләреннән чыгып укыту өлкәсендәге үзгәрешләрне исәпкә алып, бу предметлардан яңа буын укыту-методик комплексларын булдыру хәзерге милли мәгариф өлкәсендә иң әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе булып санала. Мәсьәләнең болай куелышы туган (татар) әдәбиятыннан да уку-укыту комплексларын эшләү кирәклеген искәртә.

2021 елда Федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләренә туры китереп эшләнгән яңа Үрнәк белем бирү программалары нигезендә гомуми белем бирү оешмаларының 1–4 сыйныф укучылары өчен әдәби укудан дәреслекләр эшләнде.

Башлангыч гомуми белем бирү этабында «Туган (татар) телдә әдәби уку» предметы укучыларны татар балалар әдәбияты белән таныштыруга, укуга кызыксыну уятуга, әдәби текстны сәнгатьчә кабул итү культурасы тудыруга, милли үзбилгеләнү аша туган җиргә һәм туган илгә карата мәхәббәт хисләре тәрбияләүгә юнәлтелгән.

Уку-укыту предметының төп максаты – киләчәктә китапханә белән мөстәкыйль эшли ала торган, үзен кызыксындырган һәм уку программасы куйган максатлардан чыгып китаплар сайлый, куллана ала торган белемле укучы формалаштыру.

Бу максатны тормышка ашыру укучыларда уку һәм китапка карата кызыксыну тәрбияләү, аларның танып белү мөмкинлекләрен киңәйтү; телдән һәм язма сөйләмнәрен үстерү; уку техникасын камилләштерү; текстны аңлау, кабул итү алымнарын үстерү; чагыштыру, анализлау кебек эшчәнлекнең универсаль гамәлләрен формалаштыру; әдәби анализ элементлары аша укучыларны туган телдәге әдәбиятка, сүз сәнгатенә җәлеп итү, шулай ук укучыларның әхлакый һәм эстетик хисләрен формалаштыру бурычларын хәл итә.

Шулай итеп, әлеге уку предметы, бер яктан, әдәби-сәнгать әсәрләрен өйрәнүне, икенче яктан, укучыларның сөйләм күнекмәләрен һәм осталыкларын үстерүне күздә тота.

Әдәби укудан яңа УМК туган (татар) теле буенча укыту-методик комплексы белән бербөтен тәшкил итә. Алар формалаштырыла торган компетенцияләрдә дә, бирелгән тематикада да бер-берсен тулыландырып киләләр. Ике дәреслектә укучылар бер үк персонажлар белән очрашалар.

Дәреслектәге һәр тема дәресләрдә өйрәнелә торган әсәр белән бәйләнешле бирелә. Укучыларның яшьтәшләре булган дәреслек персонажлары да теманы өйрәнә башлаганнан алып ахырына кадәр укучылар белән бергә белем үзләштерәләр. Алар – укучыга кечкенәдән таныш булган геройлар. Алмаз – танылган татар шагыйре Роберт Миңнуллинның лирик герое булса, Гөлназ Җәүдәт Дәрзаман шигырьләреннән алынды. Тагын бер персонаж – Нур, ул

туган тел дәреслегендә дә бар. Бик акыллы, зирәк укучы. Һәрвакыт киңәшләре белән ярдәм итә, аңлата. Укучылар белән әңгәмәгә кереп, үз киңәшләрен бирә яки үзләштерү өчен катлаулырак материалны аңлата торган Хөрмәтле Дәреслек образына аерым урын бирелгән. Һәр уку елында дәреслектә яңа персонаж кушыла, ул агымдагы елда өйрәнелә торган әсәрләрнең берсенең төп герое буларак кертелә. Мәсәлән, икенче сыйныфта ул Сара исемле кыз. Өченче сыйныфта – татар халык әкияте герое Гөлчәчәк, дүртенче сыйныфта Фоат Садриевның «Тургай» әсәренең төп герое – Ислам.

Өйрәнелә торган темадан һәм куелган уку-укыту бурычларыннан чыгып әдәби персонажлар укучылар белән иркен сөйләшүләр алып баралар. Сторителлинг дип аталган әлеге үзенчәлекле алым укучыларга дәрескә куелган уку бурычын аңларга ярдәм итә, аларны теге яки бу әдәби әсәрне өйрәнүгә этәрә. Төрле коммуникатив биремнәр укучыларның телдән һәм язма сөйләмен үстерергә булыша.

«Туган (татар) телдә әдәби уку» предметыннан яңа укыту-методик комплексы туган телдәге әдәбият укучыларның сөйләмен баету, аларның сөйләм культурасын һәм коммуникатив күнекмәләрен формалаштыруда төп чыганакларыннан берсе булуын исәпкә алып, уку материалын, эш төрләрен, сораулар һәм биремнәрне сайлаганда, укучыларда коммуникатив компетенция формалаштыруны беренчел максат итеп куя.

Яңа дәреслекләр әдәби уку предметыннан белемне төп (база дәрәҗәсендә) һәм тирәнтен үзләштерү мөмкинлеген үз эченә ала. Төп (база дәрәҗәсендә) белем бирү рус телендә белем бирүче мәктәпләрнең татар укучыларын, тирәнтен белем бирү татар мәктәпләрендә, гимназияләрдә укучыларны күз алдында тота.

Мәктәпләрдә уку предметын өйрәнүгә бирелгән сәгатьләр саны төрле: рус мәктәпләрендә бер сәгать, ә татар мәктәпләрендә ике сәгать. Шуңа күрә тирәнтен өйрәнү өчен материал да күбрәк тәкъдим ителә. Шул нигездә өйрәнелә торган материалның күләме дә шактый нык аерыла. Бу авырлык тудырмасын өчен дәреслектә төп (база) һәм тирәнтен дәрәҗәдә белем алучылар өчен материаллар билгеле бер төс һәм график сурәт белән аерып бирелә. Өйрәнелә торган әсәрдән соң бирелгән сораулар һәм биремнәр дә ике дәрәҗәгә бүленә.

Дәреслектә материалны бирү дә үзенчәлекле һәм кызыклы. Әсәрләрнең күләме чагыштырмача зур булмаганга, өйрәнелә торган темага бәйле өстәмә материал кертелде. Бу, үз чиратында, әдәби материалны төрлеләндерергә ярдәм итте һәм укучыларга сайлау мөмкинлеге дә тудырды. Әгәр дә укучы программага караган төп материалны үзләштереп өлгерә икән, ул үз теләге яки укытучы тәкъдиме белән өстәмә әдәби материалга мөрәҗәгать итә ала. Сыйныфтан тыш уку өчен бирелгән материалны табу кыенлыгы туу сәбәпле бу әсәрләр дә дәреслеккә кертелде.

Әдәби әсәр белән танышканнан соң, укучыларга сүзлек тәкъдим ителә. Ул укучы өчен авыр аңлашыла торган сүзнең татарча синонимнары һәм рус теленә тәрҗемәсе белән таныштыра. Бу әсәрне кабул итүне җиңеләйтә.

Дәреслекләрдә үзләштерү өчен билгеле бер күләмдә әдәби-теоретик материал урын алды. Әйтергә кирәк, мондый төшенчәләр күп түгел, аларның саны сыйныф саен ике-өчтән артмый. Ятлау өчен бирелгән текстлар да өч яки дүрт була. Башлангыч сыйныфлар өчен шул җитә дә. Бу саннар тирәнтен өйрәнүчеләр өчен бераз артыграк.

Дәреслектә үткән материалны кабатлау да төрлеләндерелә. Традицион сорау-җавап кына түгел, төрле дидактик характердагы уеннар, ребус, кроссвордлар, квест-уен тәкъдим ителә.

Дәреслекләр татар халкының мәдәнияте, тарихы белән бәйле этномәдәни материалларга да бай. Укучылар Татарстандагы һәм Россиядәге музейлар, тарихи истәлекле урыннар, татар хакына хас ризыклар, милли уен кораллары, кием-салым, бизәнү әйберләре белән таныша. Шулай ук дәреслектә Сабантуй бүләге рәвешендә татар халык авыз иҗаты үрнәкләре тәкъдим ителә.

«Туган (татар) телдә әдәби уку» предметыннан Үрнәк программалар төзегәндә үк без Г. Тукай, М. Җәлил, А. Алиш, Б. Рәхмәт, Ш. Галиев, Р. Миңнуллин кебек татар әдәбияты классикларының һәм хәзерге балалар язучыларының әсәрләренә йөз тотып эшләдек. Нәтиҗәдә дәреслекләрдә кече яшьтәге мәктәп баласын кызыксындыра алырлык әсәрләр урын алды дип ышанабыз.

Шулай итеп, туган телләрне һәм әдәбиятларны укыту методикаларының эчтәлеген яңарту һәм камилләштерүгә вакыт таләбе куйган бурычлар туган телләрне өйрәнүнең мөһимлеген, туган тел һәм әдәбият буенча яңа дәреслекләр булдыру кирәклеген тагын бер кат раслый.

## ЭЛЕКТРОННОЕ ОБРАЗОВАНИЕ НА УРОКАХ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА И ЛИТЕРАТУРЫ

**Л. Р. Нагимуллина**

*Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение «Татарская гимназия № 2 имени Шигабутдина Марджани при Казанском Федеральном Университете» Московского района г. Казани, Россия*

g2.kzn@tatar.ru

## ELECTRONIC EDUCATION ON TATAR LANGUAGE AND LITERATURE LESSONS

**L. R. Nagimullina**

*Kazan Moscow district The 2nd Tatar gumnasium at Kazan Federal University under the name of Shigabutdin Mardjani, Russia*

*g2.kzn@tatar.ru*

В статье анализируется значение электронного образования на уроках родного языка и литературы. Применение компьютерных технологий в процессе образования создает возможность решить ряд задач. Так же доступ к сети Интернет дает возможность воспользоваться огромным количеством дополнительных материалов, которые позволяют обогатить урок разнообразными упражнениями. Электронное образование открывает новые варианты обучения.

**Ключевые слова:** электронное образование, информационные технологии, электронные учебники, инновационные технологии, компьютерные технологии, татарский язык, татарская литература.

The article analyzes the importance of electronic education on tatar language and literature. The using of computer technologies in the education process creates an opportunity to solve a number of problems. Also, access to the Internet makes it possible to use a huge amount of additional materials, which allows enrich lessons with a variety of exercises. E-learning opens up new learning options.

**Key words:** electronic education, information technologies, electronic textbooks, innovative technologies, computer technologies, Tatar language, Tatar literature.

# ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ЭЛЕКТРОН БЕЛЕМ БИРҮ

**Л. Р. Нәгыймуллина**

Бүгенге көндә алга киткән илләрдә электрон технологияләр ярдәмендә белем бирү киң таралыш алган. Россия Федерациясе хакимияте рәисе урынбасары Ольга Голодец кушуы буенча 2013 елдан башлап илдә электрон белем бирү беренче планга чыкты. Шушы вакытка кадәр белем бирү оешмаларының материаль-техник базасы яңартылды. Мәктәпләргә, белем бирүдә файдалану өчен, җитәрлек күләмдә электрон җиһазлар кайтартылды.

Электрон белем бирүнең төп максатына тукталыйк. Ул түбәндәгечә: һәр җирдә тигез, өзлексез белем бирү. Укучы, кайда гына яшәвенә карамастан, башка яшьтәшләре белән бер үк дәрәҗәдә белем алырга хокуклы. Моңа бәйле рәвештә, укытучы үзендә зур җаваплылык тоеп эш итәргә тиеш. Электрон белем бирү – укытучыны эштән читләштерү түгел. Белем бирүнең әлеге ысулы белән педагог бер-берсен тулыландыра, камилләштерә, көчәйтә.

Электрон белем бирү – ул мәгълүмати технологияләрне, программаларны куллану эшчәнлеге, ягъни укытучы һәм укучының үзара бәйләнешен телекоммуникацион челтәр аша булдыру дигән сүз. Мәктәптә электрон белем бирүнең төп максаты дәресләрдә компьютер мөмкинлекләрен күбрәк файдаланудан гыйбарәт. Хәзерге вакытта башка фәннәр белән беррәттән, туган тел һәм әдәбиятны укытканда да электрон белем бирү системасы актив кулланыла. Моңа бәйле рәвештә, туган тел укытучысы үз алдына түбәндәге максатларны куеп эш итәргә тиеш. Беренчедән, мәктәптә Интернет челтәре белән бәйләнеш булдырылырга тиеш. Икенчедән, дәресләрдә электрон дәреслекләрнең кулланылуы мөһим шарт булып тора. Өченчедән, укытучы Интернет ярдәмендә укучыларның белемнәрен киңәйтү һәм мөстәкыйль рәвештә белем алуга юнәлеш бирергә тиеш. Дүртенчедән, дәресләрдә электрон журнал мөмкинчелекләреннән файдаланырга була.

Башлангыч сыйныфларда туган тел дәресләрендә электрон белем бирүне ни рәвешле тормышка ашырырга мөмкин икән, шуңа тукталыйк. Дәресләрдә электрон белем бирүне берничә юнәлештә алып барып була. Шуларның берсе – Интернет челтәрендә мәгариф өлкәсенә караган татар телендәге сайтларны куллану. Әлеге сайтлар аша укытучы да хезмәттәшләре күрсәткән үрнәк ярдәмендә тәҗрибә туплый һәм андагы материалларны дәрестә файдалана ала. Мәсәлән, Татар мәгарифе порталы – belem.ru сайтын гына алыйк. Әлеге сайт туган тел укытучысы өчен зур табыш. Аның аша укытучы мәгариф яңалыклары, бәйгеләр, проектлар һ.б. белән таныша, «Белем+» һәм «Укытучы+» секцияләрендә тәкъдим ителгән материалларны дәрестә файдалана ала.

Электрон белем бирүнең тагын бер юнәлеше – дәресләрдә электрон дәреслекләр куллану. Хәзерге вакытта кулланылышта булган туган тел һәм әдәбият дәреслекләренең күбесенең электрон версияләре бар һәм аларны теләгән һәркем файдалана ала. Мисал өчен, «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты тәкъдим итә торган дәреслекләр әлеге нәшриятның сайтында урнаштырылган. Шулай ук кайбер дәреслекләрне Татарстанн Республикасы Фәннәр академиясе сайтыннан да табарга мөмкин. Дәресләрдә электрон дәреслекләр белән беррәттән электрон сүзлекләр дә кулланырга була. Татар телендәге электрон сүзлекләр күптән түгел генә, ягъни 2018 елда гына барлыкка килде. «Татар теле: зур электрон тупланма» «TATZET» платформасының бер проекты булып тора. Ул Татарстан Фәннәр академиясе тарафыннан эшләнә. Әлеге сүзлекләрне татар теле дәресләрендә файдалану күп кенә мәсьәләләрне хәл итү мөмкинлеген тудыра.

Электрон сүзлекләр дәрестә укучы һәм укытучылар өчен нинди уңайлыклар барлыкка китерә, шуларга тукталыйк. Беренчедән, дәрестә нинди дә булса сүзне эзләү тизлеге арта. Димәк, дәрестә вакыт шактый экономияләнә дигән сүз. Шунысын да искәртергә кирәк: эзләү системасына эзләнелә торган сүз хата белән язылган булса, сүзлекнең электрон версиясе әлеге сүздәге хатаны күрсәтә. Мисал өчен, сүзләрнең төрле үзлекләрен өйрәнгәндә дә электрон сүзлек кулай вариант булып тора. Чөнки ул сүзгә бәйле үзенчәлекләрне бер генә төрле юнәлештә тәкъдим итеп калмыйча, төрле яклап ачыклап бирә. Ә басма сүзлекләрдә бу уңайлыклар тудырылмаган.

Белем бирү барышында электрон дәреслекләр куллану түбәндәге мөмкинлекләрне бирә:

1) акбур белән тактага язу өчен вакыт сарыф ителми, ягъни бу эш кирәкми;

2) теманы аңлату өчен вакыт күбрәк кала;

3) дәресләр кызыграк, үзенчәлеклерәк, нәтиҗәлерәк уза.

Электрон дәреслекләр файдаланып уздырылган дәресләргә укучылар да битараф калмый. Аларның фәнгә карата кызыксынуы арта, күп күләмдә мәгълүмат бирелә һәм әлеге мәгълүмат төрле яклап үзләштерелә. Мондый дәресләрдә баланың игътибары бермә-бер арта.

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрен электрон белем бирү кысаларында оештыру күнегүләрне төрләндерү мөмкинлеген дә бирә. Мисал өчен, укучыларга түбәндәге эш төрләре тәкъдим ителә ала: аудирование, текст белән эш, яңа сүзләр белән танышу, диалог белән эш, сорауларга җавап бирү, үзеңне тикшерү, схема, сурәт, таблицалар белән эш һ. б. Шулай ук балаларга тестлар, диагностик тикшеренүләр, күчереп язу, изложение һәм инша язу эшләрен дә эшләтергә мөмкин.

Туган тел дәресләрендә компьютер куллану күп кенә мәсьәләләрне чишү мөмкинлеген тудыра. Мисал өчен, укытучы яңа материалны аңлатканда, компьютер ярдәмендә шактый мәгълүмат бирү мөмкинлеген ала. Шулай ук дәрес барышында төрле фото, портрет, картина, сурәт, күрсәтмә материаллар буенча да биремнәр башкарырга була. Язучылар, шагыйрьләр турында фоторәсемнәр, видеоязмалар күрсәтү, әдипнең үзе язган шигырен укыганын тыңлату, аларның биографияләренә кагылышлы видеоматериаллар күрсәтү, сәнгатьле уку күнекмәләрен булдыру, әдәби әсәр мотивлары буенча төшерелгән спектакль-кинофильмнардан өзекләр күрсәтү һ.б. – болар барысы да компьютер технологияләре аша тормышка ашырыла ала. Укылган әсәрләр буенча да компьютер технологияләре ярдәмендә төрле дәрәҗәдәге иҗади эшләр башкарырга була. Хәзерге вакытта электрон белем бирү шактый киң таралыш алган булса да, дәреснең 15–20 минуты гына компьютер белән эш итүгә багышланган булырга тиеш.

Гомумән алганда, электрон белем бирү укучыларда татар телен өйрәнүгә карата уңай караш формалаштыра, аларның белем һәм культурасын камилләштерергә ярдәм итә, фәнгә кызыксыну уята һ.б., шул ук вакытта укытучыга эшләү өчен уңышлы җирлек тә булдыра. Чөнки электрон чыганаклар аша тәкъдим ителгән материалны укучы тизрәк һәм яхшырак үзләштерә.

## ӘДӘБИЯТ

1. Харисов Ф. Ф. Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. – Казан: Татһ. кит. нәшр., 2015. – 302 б.

2. Шәкүрова М. М., Йосыпов А. Ф. Татар телен укыту методикасы: теория һәм практика. – Казан: Казан ун-ты, 2009. – 167 б.

# ИЗУЧЕНИЕ ОСОБЕННОСТЕЙ ЖАНРА ПОЭМЫ НА УРОКАХ РОДНОЙ (ТАТАРСКОЙ) ЛИТЕРАТУРЫ
## (на примере поэмы «Татарларым» Р. Миннуллина)

**Л. Р. Надыршина**

*Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова*
*Академии наук Республики Татарстан, Россия*
leysan_tatar@mail.ru

# THE STUDY OF THE PECULIARITIES OF THE GENRE OF THE POEM IN THE LESSONS OF NATIVE (TATAR) LITERATURE
## (on the example of the poem «My tatars» by R. Minnullin)

**L. R. Nadyrshina**

*Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov*
*of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, Russia*
leysan_tatar@mail.ru

В статье рассматривается проблема изучения жанровых особенностей поэмы на уроках родной литературы. На материале творчества Р. Миннуллина рассматривается алгоритм анализа поэмы, выделяются ключевые моменты, на которых необходимо сфокусировать внимание при изучении произведения. Особое внимание уделяется выявлению доминирующих в поэме проблем и разъяснению авторской позиции. В результате анализа определяются жанрово-стилевые особенности произведения.
**Ключевые слова:** татарская литература, методика преподавания родной литературы, жанр, поэма, идея-проблематика.

The article deals with the problem of studying the genre features of the poem in the lessons of native literature. Based on the material of R. Minnullin's creativity, the algorithm for analyzing the poem is considered, the key points on which it is necessary to focus attention when studying the work are highlighted. Special attention is paid to identifying the dominant problems in the poem and explaining the author's position. As a result of the analysis, the genre and style features of the work are determined.
**Key words:** Tatar literature, methods of teaching native literature, genre, poem, idea-problematics.

# ӘДӘБИЯТ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ПОЭМА ЖАНРЫ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕН ӨЙРӘТҮ
## (Р. Миңнуллинның «Татарларым» поэмасы мисалында)

**Л. Р. Надыршина**

Әдәбият дәресендә текст белән эшләү – һәр дәреснең төп бурычларының берсе [4: 152], чөнки әдәби әсәр укучының рухи дөньясына йогынты ясап, аны шәхес буларак үстерә [1: 172]. Шул ук вакытта әдәби әсәрнең эчтәлеге буенча мәгълүматлы булу белән чикләнмичә, текстны теге яки бу жанр үрнәге буларак системалы өйрәнү-анализлау һәрвакыт игътибар үзәгенә куелырга тиешле мәсьәлә булып тора. Төрле авторларның әсәрләрен уку барышында, аларның жанр хасиятләре барлана, әйтик, шигъри текстларга бәйле урта мәктәп курсында лирик (гражданлык, күңел, пейзаж лирикасы һәм фәлсәфи лирика) һәм лиро-эпик (поэма, баллада) турында нәзари күзаллау булдырыла. Поэмага мөнәсәбәтле, бу жанрның төп үзенчәлеге – анда лирик һәм эпик башлангычларның бергә үрелеп килүе; эпик башлангычның – сурәтләнгән

вакыйгалар сюжетыннан, лирик башлангычның сурәтләнгәннәргә шәхси мөнәсәбәт, автор-хикәяләүче яки лирик геройның хисләре, фикерләре, бәясеннән гыйбарәт булуы искәртелә. Кайсы катламның әйдәп баруына карап, аның ике төре – лирик яки эпик башлангыч өстенлек иткән поэмалар аерып чыгарылуы әйтелә. Поэманы жанр буларак анализлау барышында, әдәби әсәрдә эпик вакыйгалар, лириклык тудыру алымнары, автор бәя-мөнәсәбәтен җиткерү чаралары һ.б. махсус калкытыла.

Әйтик, туган телдә (татар) белем бирүче мәктәпләрнең 9 нчы сыйныфында Роберт Миңнуллинның «Татарларым» поэмасын өйрәнү каралган. Әлеге әсәрне анализлауда автор артыннан бару алымы [бу алым турында кара.: 2: 73–78] уңышлы булыр дип саныйбыз. Шагыйрь үзе дә поэмасын аерым бүлекләргә бүлгән, һәр бүлектә билгеле бер фикер-карашны махсус калкытып куйган, әлеге фикерләрне табып-билгеләп чыгу автор позициясен ачыкларга ярдәм итәчәк.

Мәсәлән, поэманың беренче бүлегендә Р. Миңнуллинның татарларга хас нинди уңай якларны ассызыклавын билгеләтеп, татар милләтенең менталитетын күрсәткән холык сыйфатларын ачыкларга мөмкин, аны укучылар дәфтәрләренә дә язып куя алалар (бу очракта укытучы әлеге сыйфатларны схема рәвешендә дә бирә ала): «Татарлар – талантлы, булдыклы, укымышлы, тырыш, тапкыр, чыдам халык». Лирик геройның үз милләте белән горурлануы лирик катламда әйдәп баруы ачыклана, бу хиснең «Тарих дигән биек йолдызлыкта / Бөек татар булып кабынганбыз!..» икеюллыгында яңгыравы билгеләнә.

Поэманың икенче бүлегендә татар халкы тарихына караган аерым сәхифәләр барлана: автор милләтнең дөньяны шаулаткан күпсанлы олы кабиләләр белән бәйләнеше булуын ассызыклый, Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда, Казан ханлыгына мөнәсәбәтле шанлы чорларны хәтердә яңарта. Бу бүлектә укучылар табарга тиешле төп фикер татар халкының данлы тарихка ия булуын аңлау белән бәйле. Хис катламында милләтнең бөеклеге белән горурлану хисенең югалган дәүләтчелек турында уйланып үкенү, ачыну, шул чакларны кайтарып булмаудан сагышлану катыш булуы да аерым билгеләнә, аның «Теләсәк тә хәзер кайтып булмас / Бабайларның бөек дәверенә» юлларында чагылуы искәртелә.

Өченче бүлектә милләтнең киләчәге турында уйлану үзәктә тора, укучылар аның «татар юлы» метафорасына салынган булуын билгеләргә тиеш була. Авторның, бу юлның катлаулы булуын искәртеп, аннан язуны гөнаһка тиңләве, ягъни милләтнең һәр вәкиле татарлыгын онытмаска, милләтнең дөнья аренасыннан төшеп калмавына ирешү юлында тырышырга тиешлеген ассызыклавы күрсәтелә. Бу бүлекнең хис катламында алдагы көнгә бәйле шөбһә-билгесезлек хисе өстенлек алуы билгеләнә.

Дүртенче һәм бишенче бүлекләрнең үзәгендә укучыларга җиткерелергә тиешле мәсьәлә – маңкортлык проблемасы. Шагыйрь башка халыкларга хезмәт итеп, татарлыгын җуйган милләттәшләренә «Иманыннан һәм диненнән язган, / һәм теленнән язган татарларым...» дип эндәшә, шул рәвешле милләтнең асылын билгеләгән төп рухи кыйммәтләрне атый, «Без хәтерсез түгел, татарларым! / Татар барда һәрчак хәтер булсын!..» дип, милли хәтер һәм горурлыкның милләтне саклап калудагы ролен ассызыклый. Бу бүлекләрдә укучылар лирик геройның милли йөзен җуйган милләттәшләренә карата шелтәсе, бу хәлгә борчылуы, әлеге вазгыятьне үзгәртә алмаудган гаҗизлеге һ.б. хисләр тыгыз үрелеп килүен аңларга тиеш.

Алтынчы бүлектә шагыйрь татарларның территориаль яктан бүлгәләнгән булуын, дөньяның төрле почмакларына таралып яшәвен ассызыклый, шуңа

бәйле бердәмлек проблемасын калкыта. Укучлар, авторга ияреп, татар кешесе, кайда гына яшәсә дә, һәрвакыт үзенең кайсы милләт вәкиле булуын онытмаска, милләтенә хезмәт итәргә тиеш дигән нәтиҗәгә килә. Бу бүлектә дә лирик башлангыч өстенлек итүе билгеләнә: лирик герой татар милләтенең таркаулыгына борчыла, ачына.

Шуннан соңгы бүлектә Роберт Миңнуллин татарларны милләтне сакларга өнди, милләтне саклап калырга ярдәм итәчәк сыйфатларны санап бара, укучылар бу сыйфатларны аерым юлларны уку барышында үзләре билгеләп чыга: бердәмлек (Таркалырга безнең хакыбыз юк, / Бик тырышсалар да таратырга...), патриотлык (Исән әле Ватан сез бар чакта, / Татарларым – ватанпәрвәрләрем!), милләтпәрвәрлек Исән әле татар сез бар чакта, / Татарларым – татарпәрвәрләрем), җаваплылык (Без үзебез әгәр аттырмасак, / Кем аттырыр безнең татар таңын?! / Без үзебез әгәр сакламасак, / Кемнәр саклар безнең татар җанын?!), кыюлык (Кычкырып әйт, татар, үз сүзеңне!), маңкортлыкка бирелмәү (Киләчәккә маңкорт булып түгел, / Татар булып барыйк, татарларым!..).

Поэманың бетем өлешендә шагыйрь үзе язганнарга нәтиҗә ясый, бу өлештә төп фикер соңгы юлларда теркәлгән: «Халкыбызның киләчәген уйлыйк, / Кабатламыйк тарих хаталарын!.. / Мин сүземне әйттем! Язмышыбыз / Үзебездән тора, татарларым!» Бу бүлекне анализлап, укучы шагыйрьнең тарихтан сабак алырга, таркалмаска чакыруын, милләтнең киләчәге өчен һәрберебезнең җаваплы булуын ассызыклавын ачыклый.

Поэманы укып, аерым проблемаларны билгеләп барып, һәр бүлектә шагыйрь җиткерергә теләгән фикерләрне аерып чыгаргач, укучылар әсәрнең жанр үзенчәлекләрен системалы рәвештә атап бирә алачаклар, аның лирик башлангыч өстенлек иткән поэма булуын билгеләячәкләр. Шулай ук текстны анализлап бетергәч, шагыйрьнең аны ни өчен «оран-поэма» дип атавы турында да сорашу мөһим, бу билгеләмә хакында фикер алышу лирик герой һәм шагыйрьнең бер үк кеше булуын ачыкларга, әсәрнең язылу максатын аңларга мөмкинлек бирәчәк. Поэманы Р. Миңнуллинның үзе укуында тыңлау да әдәбият дәресләрен җанландырырга, шагыйрьнең җан авазын үтемле итеп җиткерергә ярдәм итәчәк.

Шул рәвешле, Р. Миңнуллинның «Татарларым» поэмасын анализлау-өйрәнү барышында укучылар поэмадагы эпик һәм лирик башлангычларны аерып чыгару күнекмәләре булдыралар, әсәрнең идея-проблематикасын, автор позициясен билгеләргә өйрәнәләр.

## ӘДӘБИЯТ


1. Закирҗанов Ә. М. Мәктәп курсында әдәбият теориясен өйрәнү мәсьәләләре // Диалог культур в контексте образовательной деятельности: сборник материалов Всероссийской научно-практической конференции. Отв. редакторы Н.М. Асратян, Э.Р. Ганиев, А.Г. Мухаметшин. – Набережные Челны: Набережночелнинский государственный педагогический университет, 2020. – Б. 171–174.

2. Заһидуллина Д. Ф. Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. Яңадан эшләнгән һәм тулыландырылган икенче басма. – Казан: Мәгариф, 2004. – 367 б.

3. Миңнуллин Р. М. Татарларым: милли шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – 262 б.

4. Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. Әдәбият дәресләрендә коммуникатив компетенция формалаштыру // Правовые основы функционирования государственных и региональных языков в условиях дву- и многоязычия (мировой опыт реализации языковой политики в федеративных государствах): Материалы международной научно-практической конференции. – Казань: ИЯЛИ, 2019. – С. 150–153.

# ЭЛЕКТРОННЫЕ МЕТОДЫ ОБУЧЕНИЯ НА УРОКАХ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА

**Р. С. Нуриева**

*Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение «Лицей имени В. В. Карпова» села Осиново Зеленодольского муниципального района Республики Татарстан, Россия*

mama6868@mail.ru

# ELECTRONIC METHODS OF TEACHING IN THE TATAR LANGUAGE LESSONS

**R.S. Nurieva**

*Municipal budgetary educational institution «Lyceum named after V.V.Karpov» of the village of Osinovo, Zelenodolsk municipal district of the Republic of Tatarstan, Russia*

mama6868@mail.ru

В этой статье рассказывается электронные методы обучения татарскому языку учащихся начальных классов с обучением на русском языке. Анимационный сериал «Ак Буре» – инновационный проект, направленный на формирование у детей интереса к изучению татарского языка и татарской культуры. Учебник «Салям» также интересен детям для изучения татарского языка. По учебнику «Салям» создан сайт. На сайт можно зайти с компьютера, iPad, телефона и при необходимости просмотреть учебник, рабочую тетрадь, книгу учителя. Кроме того, можно поиграть в игру, выучить песню или попеть в караоке, или выучить слова через карточки. В статье также говорится о преимуществе программы ActivInspire для работы с интерактивной доской. ActivInspire – это новое программное обеспечение компании Promethean для обучения с использованием компьютеров и интерактивных досок. ActivInspire открывает перед нами новые, богатые возможности.

**Ключевые слова:** интерактивные доски, мультимедийные проекты, инновационный проект «Ак Буре», сайт «Салям», программа ActivInspire, задания разных типов.

This article describes electronic methods of teaching Tatar to primary school students with instruction in Russian. The animated series «Ak Bure» is an innovative project aimed at forming children’s interest in learning the Tatar language and Tatar culture. The textbook «Salam « is also interesting for children to learn the Tatar language. A website has been created based on the textbook «Salam». You can access the site from a computer, iPad, phone and, if necessary, view a textbook, workbook, teacher’s book. In addition, you can play a game, learn a song or sing karaoke, or learn words through flashcards. The article also talks about the advantage of the ActivInspire program for working with an interactive whiteboard. ActivInspire is Promethean’s new software for teaching using computers and interactive whiteboards. ActivInspire opens up new, rich opportunities for us.

**Key words:** interactive whiteboards, multimedia projects, Ak Bure innovation project, Salam website, ActivInspire program, tasks of various types.

# ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ЭЛЕКТРОН УКЫТУ АЛЫМНАРЫ

**Р. С. Нуриева**

Заман алга барган саен, бүгенге уку-укыту процессында иң әһәмиятле урынны заманча технологияләрнең берсе булган компьютер технологиясе алып тора. Хәзер әлеге технология кеше эшчәнлегенең барлык өлкәләренә дә нык үтеп керде. Бер генә белгечлекне, профессияне дә аңардан башка күз алдына китереп булмый. Мәгариф оешмаларын компьютерлаштыру – мәгариф

үсешендәге өстенлекле юнәлешләрнең берсе. Шунлыктан мәктәпләр интерактив такталар, мультимедиа проектлары белән җиһазлана, дәресләрдә компьютерлар кулланыла. Башка күп кенә һөнәрләр кебек үк, укытучы һөнәре дә компьютер технологияләрен нәтиҗәле куллануны күз алдында тота. Компьютер технологиясеннән нәтиҗәле файдалану – хәзерге көндә укыту методикасының мөһим бурычы. Яңа төр эшчәнлек, компьютерны «йөгәнли белү» гә кызыксыну булдыру бәрабәренә укытуның сыйфатын күтәрүгә ирешү – әлеге технологиянең иң өстенлекле ягы. Төрле фән дәресләрендә, шул исәптән, татар теле дәресләрендә дә мөгаллимнәр әлеге технологияләрне торган саен киңрәк һәм нәтиҗәлерәк кулланалар. Технологик алгарыштагы һәр яңалыкка балалар сокланып карый, һәм, әлбәттә, аларның кызыксынучанлыгын һәм танып-белү активлыгын үз шәхесләренең максатчан үсешенә юнәлдерү мөһим. Нәкъ менә дәрестә укучылар укытучылары җитәкчелегендә үз интеллектларын һәрьяклап үстерү, белем алу һәм тормыш мәсьәләләрен хәл итү өчен мәгълүмат туплау максатында компьютер технологияләрен кулланырга өйрәнә.

Компьютер – укучы белән белемнәр системасы арасында арадашчы, белем алу чарасы. Компьютердан файдалану укыту эшчәнлеген баета, укыту процессын кызыклы, нәтиҗәле һәм иҗади итеп оештырырга мөмкинлек бирә.

Татар телен башлангыч сыйныфларда укытканлыктан, бу уку елында «Ак Бүре» анимацион сериалын дәресләрдә куллана башладым. Беренче сыйныфлар өчен ул бигрәк тә отышлы. Мультфильмда яңгыраган музыка дәресне җанландырып җибәрә, күңелләр күтәрелеп китә. «Ак Бүре» анимацион сериалы – балаларда татар телен һәм татар мәдәниятен өйрәнүгә кызыксыну уятуга юнәлдерелгән инновацион проект. Мультфильмның төп герое Ак Бүре һәм аның дуслары балаларны татар сүзләренә һәм гыйбарәләренә аңлаешлы һәм күңелле өйрәтәләр, шулай ук халкыбызның гаҗәеп тере мәдәният дөньясына озаталар. Сүзләрне искә төшерү һәм дөрес язылышын истә калдыру өчен дә бик уңайлы.

Соңгы елларда рус төркемендәге балаларны «Сәлам» дәреслеге белән укыта башладык. Бу балаларга да, укытучыларга да бик уңайлы, чөнки «Сәлам» дәреслеге буенча сайт оештырылган. Сайтка компьютер, iPad, телефон аша да кереп була һәм кирәк вакытта дәреслекне, эш дәфтәрен, укытучы китабын карарга мөмкин. Моннан тыш, уен уйнап, җыр өйрәнеп яки караокега җырлап, яисә карточкалар аша сүзләр өйрәнеп тә була. Карусель, космос, капчык, фонарь, тир уеннары бирелгән. Бу уеннар балаларга сүзләрне истә калдырырга ярдәм итә, активлыкларын, телне өйрәнүгә кызыксынучанлыкларын арттыра. Уенда һәр баланың да катнашасы килә, шуңа күрә алар сүзләрне өйдә дә өйрәнеп килергә тырышалар, дәрестә дә игътибарлырак булалар. Карточкалар (рәсемнәр) укучыларга сүзләр өйрәнү өчен кирәк. Бер ягында – сүз, икенчесендә ул сүз аңлаткан рәсем булуы тел өйрәнүчегә бик уңайлы. Һәрбер бүлеккә туры килгән җырлар бирелгән. Җырларны төрлечә кулланырга була: сүзләре белән дә, сүзләрне яшереп тә, алга да, артка да җибәреп була. Җырның сүзләренә карап физкультминуткалар да ясарга мөмкин. Сайтта дәреслекне ачарга була. Кайбер күнегүләрне аудиода тыңларга була. Шулай ук эш дәфтәрен дә ачып күнегүләрне интерактив тактада да эшләргә була. Грамматик күнегүләр дә, кроссвордлар да, төрле типтагы күнегүләр бирелгән. Интерактив тактада эшләргә балаларга бик ошый. Алар үзләре теләгән төсне сайларга яраталар.

Интерактив такта укучыларда эшләү активлыгын гына арттырып калмый, ә яңа материалны һәр укучыга җиңел, аңлаешлы итеп җиткерергә дә ярдәм итә. Интерактив такта белән эшләү өчен ActivInspire программасы бик отышлы. Бу программада татар теле дәресләрен кызыклы, файдалы итеп үткәрү өчен төрле төрдәге күнегүләр төзергә була. Бу күнегүләрне татар төркемендә,

беррәттән рус төркемендә укучы балалар өчен дә кулланырга була. ActivInspire программасы белән мин тирәнрәк танышырга һәм аны дәресләрдә мөмкин кадәр күбрәк кулланырга дигән максат куйдым. Шулай ук, бу программа татар телен өйрәнүгә кызыксыну арттырыр, дәресләрне җанлырак итәр, балаларның үз-үзләренә ышанычын арттыруына шигем юк. Бу программа интерактив такта белән эшләү өчен, үз кушымталарыңның эшләүчесе (разработчик) булырга зур мөмкинлекләр ача. Укучылар өчен бу мавыктыргыч эшчәнлек, ул дәрес белән кызыксынуны арттыра һәм аларны татар теле дәресләрендә материалны күбрәк белергә, аңларга этәрә.

ActivInspire ул компьютер һәм интерактив такталарны файдаланып укыту өчен Promethean компаниясенең яңа программа белән тәэмин ителеше. ActivInspire безнең алда яңа, бай мөмкинлекләр ача:

– дәресне гадәти сыйныф тактасындагы кебек үк алып барырга, дәрес темпын контрольдә тотарга, практик күнекмәләр булдырырга ярдәм итә;

– гади тактада язган кебек язарга, рәсем ясарга һәм ясалган әйберне бетерергә мөмкин;

– үзең төзегән күнегүләрне флипчарт (Флипчарт – ActivInspire тәрәзәсендә урнашкан турыпочмаклы формадагы киң эш киңлеге (пронстранство), анда дәресләргә әзерләнергә һәм аларны үткәрергә мөмкин) файллары рәвешендә сакларга һәм башка дәресләрдә, сыйныфларда ачып кулланырга мөмкин;

– дәресләрнең флипчартларын сурәтләр, видеоклиплар һәм тавыш белән тулыландырырга мөмкин;

– дәрес материалларын һәм мәгълүматны чыгару тизлеген дәрес планы нигезендә төзергә мөмкин;

– Microsoft Word яки турыдан-туры интернеттан текст өстәргә мөмкин;

– гади һәм нәтиҗәле инструментарий ярдәмендә фикерләү процессын стимуллаштырырга, укучыларны дәрескә җәлеп итәргә, аларның игътибарын арттырырга мөмкин;

ActivInspire программасы ярдәмендә төрле типтагы күнегүләр төзеп, дәресләрдә кулланам. Мәсәлән: соответствивие (туры китерү), распределить по категориям (категорияләр буенча урнаштыру), кроссвордлар, тренировка памяти (хәтерне ныгыту), последовательности (эзлеклелек) кебек күнегүләрне яңа материалны аңлатканда да, ныгыту, кабатлау һәм тикшерү эшләре эшләткәндә дә кулланырга була.

ActivInspire программасы, интерактив такта аша, төрле типтагы биремнәр, күнегүләр эшләп, укыту сыйфатын күтәрергә, татар телен өйрәнүгә кызыксыну уятырга, югары нәтиҗәлелеккә ирешергә мөмкинлекләр ача.

Татар теле дәресләрен төрле уеннар кулланып, заманнан артта калмыйча, интерактив такталарда да эшләп үткәрсәк, бу балаларда телгә уңай караш, кызыксыну булдырыр, укыту сыйфатын арттырыр. Татар теле һәм әдәбиятын укытуны камилләштерүнең чиге юк, фәкать эзләнергә, яңалыкка омтылырга, билгеләнгән максатка кыю барырга гына кирәк.

## ӘДӘБИЯТ

1. Габдулхаков В. Ф.Теория и практика // Развитие творческой одаренности учащихся. Сборник статей и методических материалов международной научно-практической конференции. – Казань: КФУ. – 214 б.

2. Фәтхуллова К. С., Юсупова Ә. Ш., Денмөхәммәтова Э. Н. Татар теле – күңелем теле. – Казань: Мир без границ, 2013. – 308 б.

3. Хәйдәрова Р. З. Татар теле һәм әдәбияты укытуда яңа технологияләр. – Яр Чаллы. –2011. –69 б.

4. prometheanworld.com›ru

5. http://selam.tatar/

# НАИМЕНОВАНИЯ ЛИЦА, ФИГУРИРУЮЩИЕ В ИЗДАНИЯХ ДЛЯ ЮНЫХ ЧИТАТЕЛЕЙ

**Н. Н. Сабирова**

*Казанский (приволжский) федеральный университет, магистр 2 курса.Научный руководитель – д-р филол. наук, профессор Ф. Ш. Нуриева*

Gibadullina.nailya2012@yandex.ru

# NAMES OF PERSONS APPEARING IN PUBLICATIONS FOR YOUNGER READERS

*Kazan (Volga Region) Federal University, masters student 2nd year. Scientific supervisor – Doctor of Phil.sciences, professor F. SH. Nurieva*

Gibadullina.nailya2012@yandex.ru

Мы обнаружили, что наименования лица очень часто используются и в печатных изданиях для юных читателей и раскрываются по множеству категорий: возрастным особенностям, статусу в обществе и профессии.

**Ключевые слова:** наименования лица, язык печати, функциональный стиль, лексическое значение, категория, статус.

We found that the names of personalities are very often used in print publications for young readers and are revealed in many categories: age characteristics, status in society and profession.

**Key words:** names of the person, printing language, functional style, lexical meaning, category, status.

# КЕЧЕ ЯШЬТӘГЕ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН ЧЫККАН МАТБУГАТТА ТЕРКӘЛГӘН КЕШЕ ШӘХЕСЕ БЕЛӘН БӘЙЛЕ АТАМАЛАР

**Н. Н. Сабирова**

Мәгълүмат мәйданы безнең заманда искиткеч зур һәм бай. Әлеге мәйданда берсеннән берсе яңа газеталар һәм журналлар, электрон мәгълүмат чаралары елдан-ел артып тора: аудио, видео язмалар пәйда булып тора. Бу шулай ук кече яшьтә укучылар өчен язылган матбугатка да карый.

Матбугат теле, әдәби телнең аерым бер кулланылыш шәкелләреннән булган публицистика стиленә карый. Әдәби тел – телнең үз нормаларына салынып эшкәртелгән кулланышы.

Функциональ-стилистик күзлектән чыгып караганда, үзенең күпкырлы максат-бурычларына бәйле рәвештә, публицистик стиль иң катлаулы стильләрдән санала [1: 4].

Матбугать битләрендә кеше эшчәнлеге белән бәйле атамалар зур урынны алып тора. Сәбәбе – кешенең дөньядагы тоткан урынын күрсәтү белән бәйле булу. Хезмәт әлеге юнәлештә башкарылды. Анализ ясау өчен без кече яшьтәге укучылар өчен язылган «Көмеш Кыңгырау» газетасына һәм «Ялкын» журналы материалларына мөрәҗәгать иттек, андагы мәкаләләрдә урын алган лексик берәмлекләргә күзәтү ясадык.

*Исегездәме, моннан берничә ел элек федераль каналдан барган «Голос» проектында* ***Сәйдә Мөхәмматҗанова*** *татар җыры башкарып безнең күңелләрне һәм тамашачы мәхәббәтен яулаган иде* [2: 5]. Әлеге мисалда исем + фамилия кулланылган. Еш кына авторлар үзләренең язмаларында иҗат белән бәйле шәхесләрне әлеге конструкция аша бирәләр.

*Фильмда **Җәмил ролен Уфа малае Арслан Крымчурин, Оксана ролен Мәскәү кызы,** инде танылып өлгергән **актриса Марта Тимофеева** башкара.* «Сеңелкәш» фильмының яшь актерлары белән танышабыз [2: 5]. Әлеге мисалда без шәхес атамасын да, кешеләрнең профессиясен ачыклаучы атамаларны да күрәбез. Танылган кеше булуларына карамастан, иҗат белән бәйле эш булганлыктан китерелгән мисалда да исем + фамилия кулланылып килгән.

«*Россия» каналыннан барган «Зөләйха күзләрен ача» фильмында Зөләйханың улы Йосыф ролендә безнең Казан егете, 171 нче мәктәпнең 4 нче сыйныф укучысы Исмәгыйль Низамиев та уйный* [3: 4]. Алдагы мисалда шәхес атамасының ике төрле кулланылу очрагы бар. Беренчесе – кешене исеме белән атау, бу очракта тарих аша безгә билгеле шәхесләр булса, икенчесе – исем фамилиясе кулланылган очрак, бу иҗат белән бәйле рәвештә килә. Шулай ук туганлык атамалары булган сүзне дә күрәбез: ул. Кешенең җәмгыятьтәге статусы – укучы. Яше ягыннан үзенчәлеген ачкан мисал – егет.

*Г. Тукайның әкиятләрен уку, алар буенча театраль өзекләр күрсәтү, әти-әниләре белән бергә мультфильмнар карау балалар күңеленә бик якын килде* [3: 5]. Әлеге мисалда татар укучысы өчен билгеле шәхес Габдулла Тукай китерелгән. Язучы буларак аның исемен тулысынча язмыйча, баш хәрефен генә куеп нокта куйсалар, фамилиясе тулысынча язылган.

*Мондый идеяне Казанның мәктәп укучысы Алия Минһаҗи тормышка ашырган. Абыйсы да ярдәмгә килгән аңа. Озак та үтми абыйлы-сеңелле Минһаҗилар бу эшкә керешкән. Шунысын да әйтеп узыйк: Айзат Төркиянең Инстанбул шәһәрендәге Мимар Синан Гүзәл Сәнгатьләр Университетының сәнгать тарихы бүлегендә 3 нче курсында укый. Алия Казанның 4 нче гимназия-интернатының 10 нчы сыйныфын тәмамлый* [4]. Әлеге мисалда шәхес атамалары күп яктан ачылган: а) туганлык атамалары – абыйсы – 2 нче зат тартым белән кулланылган, абыйлы-сеңелле – җенесе ягыннан аера, шулай ук парлы туганлык атамсы; ә) җәмгыятьтәге статусын күрсәтүче – укучы; б) атаманы исеме һәм фамилиясе белән – Алия Минһаҗи, исемен генә – Алия, Айзат, фамилиясе – Минһаҗилар.

*Кадерле, балалар! Әле башланып кына килүче олы тормыш юлында сезгә уңышлар телим! Шуны онытмагыз: укытучыларыгыз сезне ярата, сагына һәм көтә! Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры Р. Т. Борһанов* [4]. Әлеге мисалда да шактый гына шәхесне атаучы сүзләр кулланылышка кергән, төрле бүленешне күрсәтәләр: а) яшь ягыннан үзенчәлек – балалар, профессиясе ягыннан – укытучыларыгыз, министр, шәхеснең фамилиясе генә кулланылган очрак – Борһанов.

*Әмма моңа кадәр Тәслимә, улы Илназ өйдә булган көннәрдә талымлап тормый, башын мендәргә тидерүгә үк йоклап китә. Бүген улы юклыктан шулай боргалана инде ул.* [4] Әлеге мисалда шулай ук исеме генә кулланылган, чөнки алдагы мисалдагы кебек үк телгә алынган шәхесләр бер даирә эчендә генә билгеле булып торалар. Туганлык атамасы ягыннан да бүленешне күрәбез: улы.

Нәтиҗәдә ясап әйткәндә, без шәхес атамаларының яшь укучылар өчен язылган матбугат битләрендә дә бик еш кулланылуына һәм аларның бик күп категорияләр буенча ачып бирелгәнлегенә тап булдык: яшь үзенчәлеге, җәмгыятьтәге һәм профессиясе ягыннан статусы.

## ӘДӘБИЯТ

1. Миңнуллин Б. К. Гомуммилли телнең яшәеш формасы буларак әдәби тел һәм аның функциональ стильләре. – Фәнни Татарстан, 2017. – 31 б.

2. Гафарова В. Р. Текстка грамматик анализ ясау: Уку-укыту әсбабы / В. Р. Гафарова. – Казан: Отечество, 2016. – 85 б.
3. «Йосыф булу – җиңел түгел» // Көмеш кыңгырау. – 2020. – 21 апрель – Б. 5.
4. «Татар җыры белән җиңеп була» // Көмеш кыңгырау. – 2020. –14 май – Б. 2.
5. « Җаныңны бирсәң дә...» http://yalkyn.ru/news/ijat/anyny-birs-d – Б. 3–5.

## РАЗВИТИЕ КОММУНИКАТИВНОЙ КОМПЕТЕНЦИИ ПРИ ПОМОЩИ ПЕРЕВОДА

**Р. К. Сагдиева, Д. Х. Хуснутдинов**

*КФУ Институт филологии и межкультурной коммуникации, Казань, Россия*
ram-sag777@mail.ru

## DEVELOPING COMMUNICATIVE COMPETENCE THROUGH TRANSLATION

**R. K. Sagdieva, D. H. Husnutdinov**

*KFU Institute of Philology and Intercultural Communication, Kazan, Russia*
ram-sag777@mail.ru

Основная цель уроков родного (татарского) языка – научить учащихся общаться. Для достижения этой цели учитель может использовать самые разные методы работы. Коммуникативную компетенцию можно также развить с помощью переводческой работы. Данная статья посвящена актуальной проблеме – развитию коммуникативной компетенции учащихся на уроках родного (татарского) языка. Речь идёт о роли фактического материала, контекста в образовании.
**Ключевые слова:** коммуникативная компетенция, перевод, текст, родной язык, урок.

The main goal of native (Tatar) language lessons is to teach students to communicate. To achieve this goal, the teacher can use a variety of working methods. Communication competence can also be developed through translation work. This article is devoted to an urgent problem – the development of the communicative competence of students in the lessons of their native (Tatar) language. It is about the role of factual material, context in education.
**Key words:** communicative competence, translation, text, mother tongue, lesson.

## ТӘРҖЕМӘ АША КОММУНИКАТИВ КОМПЕТЕНЦИЯНЕ ҮСТЕРҮ

**Р. К. Сәгъдиева, Д. Х. Хөснетдинов**

Татарстан Республикасы җирлегендә оештырыла торган билингваль, полилингваль мәктәпләрнең төп максаты – туган телне саклап калу һәм шул ук вакытта укучыларның рус һәм чит телләрдә дә иркен аралаша алуларын тәэмин итү. Шуның белән бәйле, татар телен укытканда, чагыштырмалы алымны файдалану уңышлы нәтиҗәләр бирә ала. Әлеге хезмәттә без аерым темаларны өйрәткәндә кулланыла ала торган кайбер эш төрләрен тәкъдим итүне максат итеп куйдык. 6–7 сыйныфларда аваз иялтемнәре белән таныштырганда, дәресне түбәндәге күнегү белән башларга мөмкин:

Шигырьләрне сәнгатьле итеп укыгыз. Калын хәрефләр белән бирелгән аваз иялтемнәренә игътибар итегез. Алар ничек аерыла? Нәтиҗә ясагыз.

**Кикрикүк-кикрикүк!**
Кычкырам иртән иртүк.
Иң беренче уянам,
Аннан сезне уятам.
*Резеда Фәрхетдинова*

Голосистый петушок,
Дай поспать ещё часок.
**Ку-ка-ре-ку, ку-ка-ре-ку!**
Нет покоя человеку!

| | |
|---|---|
| Ишегалдында көн-төн | К нам пришла собачка |
| Ул – кизүдә, ул – сакта. | Умная собачка, |
| «Һау-һау» дип өреп куя, | Хвостиком виляет, |
| Шыгырдап алса капка. | Громко, громко лает: «Гав-гав-гав!» |
| *Ленар Шәех* | *Надежда Комисарова* |

Укучылар үзара фикер алышканнан соң, татар, рус һәм инглиз телләрендә төрлечә әйтелә торган аваз ияртемнәренә мисаллар китерергә тиеш булалар.

Түбәндәге күнегү дә укучыларда гадәттә кызыксыну уята:

Укыгыз. Ни өчен бер үк сарык төрле илдә «төрлечә» кычкыра икән?

Сарык Англиядә дә сарык

Тик ул анда инглизчә сөйләшә. Төрле илләрдә хайваннарның тавышы төрлечә ишетелә икән. Бездә, татарларда, эт өргәне «һау-һау», руслар – «гав-гав», немецлар – «вау-вау», инглизләр – «ба-ба», французлар – «ау-ау», итальяннар «бу-бу» дип аңлаталар. Сарык бездә «бе-е-бе-е», Германиядә – «ме-ме-е», Испаниядә – «би-би», Төркиядә – «мми-мми», Англиядә – «ба-а» ди. Руслар дуңгыз «сөйләшүен» «хрю-хрю», татарлар – «мырык-мырык», инглизләр – «уинк-уинк», немецлар – «квик-квик», итальяннар – «фрон-фрон» диләр. («Күңелле атна» газетасыннан) [1].

«Татар теленнән презентацияләр» кулланмасы да әлеге дәресне мавыктыргыч итә ала [2].

Бәйлек һәм бәйлек сүзләрне өйрәткәндә, дәресне алдагы күнегү белән башларга тәкъдим итәбез:

Укыгыз, чыгыштырыгыз һәм нәтиҗә ясагыз.

Пишет пером – каләм белән яза.
Держит в руке – кулында тота.
Разговаривает с мамой – Әнисе белән сөйләшә.

Укучылар билгеле бер фикергә килгәннән соң, татар һәм рус телендәге бәйлекләрнең охшаш һәм аермалы якларын ачып бирә торган таблица күрсәтелә. Балалар андагы мәгълүмат белән танышалар:

Татар телендә: *Өйгә **таба** бара.* Бәйлек (послелог). Сүз артында килә. Бәйлекләр аерым языла. Сүзләрне һәм җөмләләрне бәйли. Сүзләрне килеш белән төрләндерәләр. Бәйлекләрне килеш кушымчалары белән алыштырып була (*укыр өчен килү – укырга килү*).

Рус телендә: *Идёт **к** дому.* Предлог. Стоит перед словом. Предлоги со словами всегда пишутся раздельно. Связывают слова в словосочетаниях и предложениях.Изменяют слова по падежам. Между предлогом и словом, к которому он относится, всегда можно вставить другое слово (*к дому – к большому дому*).

Ахырдан укучылар үзләре чыгарган нәтиҗәгә йомгак ясыйлар: татар һәм рус телендәге бәйлекләр кайсыбер очракта тәңгәл килә, ә кайчак татар телендәге бәйлек килеш кушымчасы белән генә белдерелә. Һәм киресенчә.

Татар теле дәресләрендә укытучылар һәрвакыт тәрҗемә эшләренә мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр. Иң мөһиме: текст катлаулы булмаска, һәм шул ук вакытта укучыларның сүзлек байлыгын арттыру максаты да алгы планга чыгарга тиеш. Балаларга мәкаль-әйтемнәр, сынамышларны тәрҗемә итү бер яктан җиңел, икенче яктан кызыклы:

Мәкальләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. Нинди ярдәмче фигыльләр кулландыгыз?

*Когда голова думает, язык отдыхает.
*Мал язык, да всем миром владеет.

*Ешь суп с грибами, держа язык за зубами [1].

Сөйләм телен үстерү максатыннан, ике яисә өч телдәге охшаш текстларны файдалану да уңышлы бер алым булып тора. Мәсәлән, түбәндәге текст бирелә:

Иртән уянган Әхәт тәрәзәгә карады. Урамдагы күренешкә гаҗәпләнде. Кичә генә урамда яңгыр коя иде. Бүген кыш җиткән. Күлдәвекләрне көмештәй боз каплаган. Урам яктырган. Кояш болытлар арасыннан җиргә карый. Ул Әхәтне эзли шикелле.

Әхәт тиз генә ашады да өстенә җылы бишмәтен, башына кызгылт башлыгын киде. Аякта – итекләр. Урамга йөгереп чыкты. Урамда салкынча, күңелле. (Факил Сафиннан)

Укучылар әлеге өзекнең эчтәлеген сөйлиләр, фикер алышалар, билгеле бер грамматик бирем дә тәкъдим ителә ала. Аннары аларга эчтәлеге белән охшаш рус телендәге текст бирелә:

Голая земля промёрзла, а зимы ещё не наступила. Но вот потеплело, и к вечеру пошёл снег. Крупные снежинки закружились в воздухе. С каждой минутой их становилось больше, и наконец снег повалил хлопьями.

Я накинул на плечи полушубок и вышел на крыльцо… Воздух был чистый, свежий. Кругом было совсем тихо… Я стоял и следил за тем, как из вечернего неба сыпал и сыпал на землю белый пух зимы. (Георгий Скребицкийдан) [1].

Укучыларике текстны үзара чагыштыралар. Рус телендәге өзекне татар теленә тәрҗемә итәләр. Бу очракта алдагы татар телендәге текст балаларга ярдәмлек функциясен башкара.

Түбәндәге эш төрен дә укытучылар максатчан файдалана алалар:

Укыгыз, татарчага тәрҗемә итегез. Ничек уйлыйсыз: Сөләйман патшага сугышчы, сәүдәгәр һәм җир эшкәртүче нәрсә дип җавап бирделәр икән? Әкиятне дәвам итеп сөйләп карагыз.

Сулейман мудрый

Мудрый царь Сулейман состарился и стал бояться смерти. И тогда к нему явился повелитель злых духов и сказал:

– О царь! Прими этот волшебный сосуд с живой водой. Выпей её, и ты обретёшь бессмертие.

Старый царь Сулейман был мудр и потому осторожен. Он приказал, чтобы к нему привели первых трёх проходящих мимо его дворца. И вскоре предстали перед царём знатный воин, богатый купец и простой земледелец.

Спросил Сулейман каждого из них:

– Скажи, буду ли я счастлив, выпив живой воды?

Воин ответил: ....(Әкияттән) [1].

Текстны тәрҗемә иткәннән соң, укучыларның үзара татар телендә фикер алышулары бик мөһим. Теге яки бу текст белән эшләгәндә, балалар парлашып та шөгыльләнә алалар, ягъни текст белән танышканнан соң, бер-берсенә сораулар бирәләр, җавапларын тыңлыйлар, хаталарын төзәтәләр.

ӘДӘБИЯТ

1. Сәгъдиева Р. К., Харисова Г. Ф., Сабирҗанова Л. К., Нуриева М. Ә. Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 7 нче с-ф. – Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. – 215 б.

2. Сәгъдиева Р. К., Хөснетдинов Д. Х. Татар теленнән презентацияләр. 664 слайд. – Казан: Мәгариф – Вакыт, 2016. (диск)

## ФОРМИРОВАНИЕ КОММУНИКАТИВНОЙ КОМПЕТЕНЦИИ С ИСПОЛЬЗОВАНИЕМ КРОССВОРДОВ В ОБУЧЕНИИ ТАТАРСКОМУ ЯЗЫКУ

**Р. Р. Салахова**

*Казанский федеральный университет, Россия*
Ruzilya5@mail.ru

## FORMATION OF COMMUNICATIVE COMPETENCE THROUGH CROSSWORDS IN TEACHING THE TATAR LANGUAGE

**R. R. Salakhova**

*Kazan Federal University, Russia*
Ruzilya5@mail.ru

В данной статье рассматриваются различные подходы к формированию речевого компонента профессиональной культуры в процессе подготовки специалиста к будущей профессиональной деятельности, отмечаются преимущества использования кроссвордов в формировании коммуникативной умений и навыков профессиональной коммуникации на татарском языке.
**Ключевые слова**: татарский язык, коммуникативная компетенция, речевая деятельность, кроссворд.

This article discusses various approaches to the formation of the speech component of professional culture in the process of preparing a specialist for future professional activity, and notes the advantages of using crosswords in the formation of professional communication skills in the Tatar language.
**Key words**: Tatar language, professional culture, speech activity, crossword puzzle.

## ТАТАР ТЕЛЕНӘ ӨЙРӘТҮДӘ КРОССВОРДЛАР КУЛЛАНЫП КОММУНИКАТИВ КОМПЕТЕНЦИЯНЕ ФОРМАЛАШТЫРУ

**Р. Р. Сәлахова**

Сөйләм – кеше эшчәнлегенең төп компонентны булып тора, аның үсеше сөйләм эшчәнлегенең башка төрләрен үзләштерүгә юл яра. Югары һөнәри белем бирү мәктәпләренең төп бурычы – булачак белгечләрдә һөнәри осталык һәм күнекмәләр формалаштыру, боларга студентларның белем дәрәҗәсе, фикерәү сәләте, һөнәри әзерлеге һәм коммуникатив компетенциясе керә. Коммуникатив компетенция белем алучыларның сөйләшә белү осталыгын, эзлекле рәвештә фикер йөртү сәләтен камилләштерү, сүзлек байлыгын арттыру, сөйләм күнекмәләренә ия булуын күздә тота. Аны формалаштыруда кроссвордлар куллану отышлы чаралардан санала. Кроссворд сүзе инглиз теленнән алынган, ул «сүзләр киселеше» дигән мәгънәгә ия [1: 8], аны чишү мавыктыргыч һәм файдалы шөгыль, ул балаларга да, урта буын кешеләренә дә, өлкәннәр дә ошый. Уку процессында кроссвордлар куллануның нәтиҗәлелеген арттыру өчен түбәндәге таләпләр үтәлергә тиеш:

1. Беренчедән, кроссвордларны чишү артык күп вакыт алмаска тиеш, чөнки нинди генә кызыклы тоелмасын, бер төрлелек ялыктыра, кызыксынуны киметә, икенчедән, әлеге таләпне үтәлмәсә, бер дәрес кысаларында телнең төрле аспектлары һәм сөйләм эшчәнлегенең башка төрләрен дә кулануга ирешеп булмый. Кроссвордның оптималь күләме, безнең фикеребезчә, 5–15 бирем чикләрендә.

2. Кроссворд биремнәре аңлаешлы булырга һәм андагы сораулар студентның алдан үзләштергән материалларына нигезләнергә тиеш. Кроссвордта аңлашылмый торган сүзләр яки терминнар булмау зарур.

3. Кроссворд биремнәрендә җиңел һәм катлаулы сорауларны аралаштыру мөһим. Катлаулы сораулар студентларның фикерләү сәләтен үстерү белән беррәттән, аларның әлеге эшкә кызыксынуын арттыра, тиз арада чишелә торган кроссворд кызык түгел, ул уйландырырыга тиеш. Әмма җиңел биремнәрсез дә булмый, алар, үз чиратында, һәр студентка дәрестә катнаша алу, ягъни фикерләрен туплап, үз җавап вариантын тәкъдим итү мөмкинлеге бирә, чөнки җиңел сорауларга җавапны һәркем дә белә.

Кроссвордлар чишү төрлечә оештырырыга мөмкин:

1. Индивидуаль мөстәкыйль эш: а) бөтен төркем бер үк вакытта; б) студентларның бер өлеше кроссворд чишә, шул ук вакытта калганнары сөйләм күнекмәләрен арттыру юнәлешендәге башка эш төрләре белән мәшгуль.

2. Төркем ике командага бүленә, аларның һәркайсына бер үк төрле кроссвордлар тәкъдим ителә. Кроссвордны чишү вакыты чикләнелми, әмма «Кем тизрәк чишә?» дигән шарт куела.

3. Ярышта бер үк төрле кроссвордлар чишәргә тиеш булган өч һәм аннан да күбрәк команда катнаша. Кроссвордны чишүгә чикләнгән вакыт бирелә.

Югарыда санап үтелгән вариантлар һәркайсы үз өстенлекләренә ия. Беренчесе студентны индивидуаль рәвештә эшләвенә уңай шартлар тудыра, шул ук вакытта укытучыга аның теге яки бу лексиканы үзләштерү дәрәҗәсен аңларга мөмкинлек бирә. Калган формаларның үзенчәлеге студентларның төркемләп эшләве белән аңлатыла, биредә конкурентлык сәләте алга чыга. Әлбәттә, бу очракта әзерлек дәрәҗәсе түбән булган студентлар эшнең нәтиҗәсен киметергә мөмкин, әмма аларның кроссвордны чишү барышында үз җавап вариантыларын тәкъдим итүләре, шул рәвешле аларның әлеге эштә катнашулары, активлык күрсәтүләре шулай ук зур әһәмияткә ия. Мәсәлән, «Көндәлек режим» темасына монолог сөйләргә яки диалогка әзерләнү барышында «Атна көннәре», «Вакытны ничек әйтәбез?» кебек темаларны үзләштерү мөһим. Түбәндәге кроссвордны чишү, беренчедән, текстны тулыландырырга ярдәм итә, икенчедән, атна көннәре исемнәрен кабатларга һәм истә калдырырга мөмкинлек бирә.

1. Кроссвордны чишегез. Җавапларны һәр баганага астан өскә таба языгыз, алар белән текстны тулыландырыгыз. Үрнәк буенча «Минем көн тәртибе» темасына монолог төзеп, сөйләргә әзерләнегез.

Кроссвордның биремнәре: 1. Көзнең беренче ае нинди ай? 2. Атнаның алтынчы көне нинди көн? 3. Атна башындагы көн ничек атала? 4. Ял көннең исеме ничек? 5. Берсекөнгә ял буласы көнне нинди көн дип атыйлар? 6. Кичә сишәмбе иде, ә бүген нинди көн? 7. Атна уртасындагы көннең атамасы ничек?

*Институтта укулар (1. _________) аеннан башлана. Без, гадәттә, атнага алты көн укыйбыз. (4. ___________) көнне ял итәбез. Бу көнне туганнар, дуслар белән очрашабыз, кайвакыт кино-театрларга барабыз. (3. __________) атнаның иң авыр көннәреннән санала. Без һәр көнне дүртәр-бишәр пар дәрес укыйбыз. Уку атнасы (2. _________) тәмамлана, бу көнне мин аеруча көтеп алам, чөнки аның икенче көнендә ял итәм. Гадәттә, безнең дәресләр тугызынчы яртыда башлана. Ә менә атнаның дүртенче көнендә без институтка сәгать унга киләбез, чөнки (7.____________) көнне дәресебез унберенче ун минутта башлана. Аның алдагы көнендә, ягъни (6.___________) көнне институтта уникегә кадәр генә булабыз, аннан соң*

*«Мәскәү» спорткомплексына физик тәрбия дәресенә китәбез. Миңа иң ошаган көн – (5.____________), чөнки бу мөселманнарда изге көн санала. Халыкта «**Сишәмбе** көнне яңа эш башларга ярамый, уңышсыз* була*», – дигән ышану яши. Минемчә, көнеңне дөрес планлыштырсаң, һәр эшең дә уңышлы булыр.*

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | ч | |
| | | | | | ә | |
| | | | | | р | п |
| | | | | | ш | ә |
| | | д | | җ | ә | н |
| | ш | ү | | о | м | җ |
| с | и | ш | ә | м | б | е |
| е | м | ә | | г | е | ш |
| н | б | м | | а | | ә |
| т | ә | б | | | | м |
| я | | е | | | | б |
| б | | | | | | е |
| р | | | | | | |
| ь | | | | | | |

Күргәнебезчә, әлеге кроссворд структурасы ягыннан әлләни авыр түгел, мондый кроссвордны командага бүленеп чикләнелгән вакыт аралыгында чишү өчен тәкъдим итәргә мөмкин. Биредә сүзләр киселеше юк диярлек, аркылы юлда язылган сүз (сишәмбе) кроссворд чишүне бераз җиңеләйтә, әмма аны да күрсәтмәскә мөмкин, бу исә студентларның телне белү дәрәҗәсеннән чыгып хәл ителә.

Студентка кроссвордны үзеннән төзетү дә сөйләм эшчәнлеген үстерүдә үзенчәлекле эш төрләренең берсе булып тора. Ул студенттан мөстәкыйльлек, иҗадилык таләп итә. Биредә әзер материалдан да, өстәмә материалдан да файдаланырга мөмкин. Өстәмә материал рус телендә булган очракта, студент татарчага дөрес итеп, төзек җөмләләр белән тәрҗемә итәргә тиеш була.

Укытуда яңа технологияләр куллану – заман таләбе. Мондый дәресләр укучыларны да, студентларны да битараф калдырмый киресенчә, аларның кызыксынучанлыгын арттыра. Кроссвордлар чишүне дә яңа технологияләр аша оештырырырга була. Бу юнәлештә кроссворд төзү өчен махсус сайтлар, он-лайн сервислардан файдаланырга мөмкин. Шундыйларның берсе – Фабрика кроссвордов [4]. Бу бик уңайлы сервис, биредә таблицалар ясап утыру ихтыяҗы юк, сайлап алынган сүзләрне әзер шакмакларга дөрес итеп урнаштырырга гына кирәк. Әлеге сервис ярдәмендә теләсә нинди структурага ия булган кроссвордларны эшләү мөмкинлеге бар. Төзеп бетергәч, аны бастырып чыгарасы гына кала. Дәресләр дистанцион форматта укытылган очракта, студентларга алдан төзелгән кроссвордның сылтамасы бирелә һәм студент мөстәкыйль рәвештә әлеге сылтама аша кереп, кроссвордны чишә ала. Югарыда тәкъдим ителгән кроссворд әлеге сервис ярдәмендә төзелде.

Кроссворды онлайн в Online Test Pad [3] сервисында кроссвордның бик күп төрләре тәкъдим ителә, биредә кроссворд конструкторы бар, аның ярдәмендә япон кроссворды, филворд яки сканфордлар да төзеп була. Әмма артык катлаулы структуралы башваткычлар дәрестә киенренкелекне арттырырга мөмкин, шуңа күрә биредә чама хисен югалтмау сорала.

Cross: составь свой кроссворд онлайн [5] сервисын аеруча игътибарга лаек. Биредә кроссвордның сүзләрен (җавапларын) кертү һәм үлчәмен билгеләү таләп ителә, соңыннан әзер (тутырылган) кроссвордны Word форматында компьютерга йөкләргә кирәк. Әеге сервис ярдәмендә төзелгән кроссвордны дәрестә файдалану өчен кроссворд шаблонына хәбәрләмәләрне (сорауларны) кертергә һәм кирәкле күләмдә (экземпляр) бастырып чыгарырга була.

Йомгаклап әйткәндә, телгә өйрәтү дәресләрендә кроссвордлардан файдалану, аларда коммуникатив компетенция формалаштыру белән бергә уку материалын аңлаешлы һәм кызыклы итеп җиткерергә; белемнәрне системага салырга булыша, студентларның иҗади үсешен тәэмин итә, үзлектән белем алуны яхшырта, яңа темага җиңелрәк төшенергә мөмкинлек тудыра.


ӘДӘБИЯТ

1. Волков В. В. Использование методики кроссворд-тестирования при изучении гуманитарных и социально-экономических дисциплин // Актуальные проблемы гуманитарных и социально-экономических наук. 2019. Т. 13, № 8. – С. 8–14.

2. Сафиуллина Ф. С. Татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. – Казан, 2001. 383 б.

3. Кроссворды онлайн в Online Test Pad // URL: https://onlinetestpad.com/ (дата обр. 08.10.2021 г.)

4. Фабрика кроссвордов // URL: https://puzzlecup.com/crossword-ru/ (дата обр: 08.10.2021 г.).

5. Cross: составь свой кроссворд онлайн https://cross.highcat.org/ru_RU/ (дата обращения: 08.10.2021 г.).


## ДЕРИВАЦИОННО-СЕМАНТИЧЕСКИЙ АСПЕКТ ИЗУЧЕНИЯ ГЛАГОЛОВ ДВИЖЕНИЯ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА В РУССКОЯЗЫЧНОЙ АУДИТОРИИ


**Р. Р. Салахова, Ф. Р. Сибгаева**

*Казанский (Приволжский) федеральный университет, Россия*

Ruzilya5@mail.ru


## DERIVATIONAL AND SEMANTIC ASPECT OF STUDYING THE VERBS OF THE TATAR LANGUAGE MOVEMENT IN THE RUSSIAN-SPEAKING AUDIENCE


**R.R. Salakhova, F.R. Sibgaeva**

*Kazan (Volga Region) Federal University, Russia*

Ruzilya5@mail.ru



Статья посвящена анализу лексико-семантической группы глаголов, обозначающих движение в современном татарском и русском языках. Интерес к изучению глаголов движения разноструктурных языков объясняется тем, что они занимают важное место в смысловой стороне языка и сравнительный аспект поможет студентам глубже проникнуть в суть сопоставляемых лингвистических явлений, а также послужит базой для построения лингводидактической теории.



**Ключевые слова**: татарский язык, глаголы движения, семантика, словообразование.



The article is devoted to lexical-semantic group of verbs denoting movement in modern Tatar and Russian languages. Interest in the study of verbs of motion of languages of different structures is explained by the fact that they occupy an important place in

the semantic side of language and comparative aspect will provide students with a deeper insight into the matching of linguistic phenomena and serve as the basis for constructing a didactic theory.
**Key words:** Tatar language, verbs of movement, semantics, word formation.

Актуальность данной темы определяется межкультурными барьерами при изучении татарских глаголов движения носителями русского языка, возникающими, на наш взгляд, вследствие недостаточного сопоставительного анализа. При сравнении разноструктурных языков специфика каждого из них проявляется достаточно ярко. Особенно интересен в этом плане словообразовательный уровень, поскольку при его исследовании на поверхность выступает тот типовой признак, который лежит в основе наименования целых классов слов, отчетливее проступают системные связи и отношения, связывающие всю структуру языка.

Основным признаком глаголов движения является направленность движения, состоящая из разных компонентов: движение по горизонтали и вертикали, вверх – вниз, внутрь – изнутри наружу, с пересечением границы пространства – без пересечения границы, от точки – к точке и т.д. На основе лексико-семантических признаков глаголы поступательного движения подразделяются на две подгруппы: 1. Глаголы, обозначающие направление движения: *бару* ‘идти’, *керү* ‘войти’, *күчү* ‘переехать’, *төшү* ‘спускаться’.

2. Глаголы, обозначающие способ движения: *атлау* ‘шагать’, *йөзү* ‘плавать’, *йөгерү* ‘бежать’, *агу* ‘течь’, *үрмәләү* ‘карабкаться’ [5: 74].

Глаголы, обозначающие направление движения, включают группу глаголов, фиксирующих векторные характеристики движения по ***вертикали*:** а) вверх: *күтәрелү* ‘подниматься’, *менү* ‘взбираться’, ‘подниматься’, ‘залезать’ ‘вверх’, ‘взбираться’; б) вниз: *төшү* ‘спускаться’, ‘опускаться’, *егылу* ‘падать’, *иңү* ‘опуститься’, ‘спуститься’; и по ***горизонтали**:* а) вовнутрь: *керү* ‘входить’, ‘въезжать’; б) изнутри: *чыгу* ‘выходить’, ‘выезжать’; *в*) к субъекту или объекту: *якынаю* ‘приблизиться’, *килү* ‘прийти’; г) от субъекта или объекта: *китү* ‘уходить’, *ерагаю* ‘удаляться’; д) разнонаправленное движение: *таралу* ‘расходиться’, *чәчелү* ‘рассыпаться’ [3: 49], [4: 15].

Указание на перемещение субъекта в пространстве между двумя точками как по горизонтали, так и по вертикали является обязательным для обоих языков и представлено антонимичными средств типа *керү* ‘входить’, ‘въезжать’, *килеп керү* ‘войти’, *кайтып керү* ‘вернуться’, *барып керү* ‘зайти’ и *чыгу* ‘выходить’, ‘выезжать’, *кереп чыгу* ‘заскочить’, *алып чыгу* ‘вывести’, *атлап чыгу* ‘перешагнуть’, *йөзеп чыгу* ‘переплыть’, *сикереп чыгу* ‘перепрыгнуть’, *китү* ‘уходить’, ‘уехать’, ‘отъехать’, ‘выехать’ и *килү* ‘приехать’, ‘приходить’, ‘подъехать’ и т.п.

Таким образом, в русском языке такие глаголы образуются при помощи *префиксов в-, вы-, от-, у-, под, при-, в.* Например значение, «движение вокруг точки» в русском языке выражается глаголами с префиксом *об-: объехать, облетать, обползать,* а в татарском языке лексемами *әйләнү, урау* или *әйләнеп үтү, урап узу*. Значение возвратного действия составляет основу русских глаголов *вернуться* и *возвращаться*. В татарском языке для такой цели существует глагол *кайту*, функционирующий как в самостоятельном употреблении, так и в составе производной конструкции: *кайту, очып кайту, барып кайту*.

Интересно отметить, что составные глаголы в русском языке отсутствуют, а в татарском языке они очень распространены. Как видно из примеров, составные глаголы в татарском языке состоят из комбинации деепричастия

на *-п* или на *-а/-ә, -ый/-и* с некоторыми модифицирующими глаголами. Причем, роль модифицирующих глаголов очень часто выполняют глаголы движения. Таким качеством обладают следующие глаголы: *йөрү* ‘ходить’, *керү* ‘войти’, *китү* ‘уходить’, *килү* ‘приходить’, *төшү* ‘спускаться’, *узу* ‘проходить’. Рассмотрим словообразующий тип «деепричастие + модифицирующий глагол *бару*, который выражает: 1) нарастание, развитие действия, усиление действия: *яхшыланып бару* ‘улучшаться’; 2) действие, развивающиееся в направлении своего конца, предела: *бетеп бару* ‘кончаться’; 3) регулярно совершающееся действие: *укып бару* ‘читать регулярно’; 4) внезапное или стремительное действие, направленное от говорящего или от какого-либо исходного пункта: *китеп бару* ‘уйти быстро’; 5) действие, протекающее в определенном направлении: *менеп бару* ‘подниматься’ [6: 479].

Такого рода глагольные конструкции могут и вызывают определенные трудности для русскоязычной аудитории. Дело в том, что подобные же конструкции могут являться и свободными синтаксическими сочетаниями и при переводе татарских текстов на русский язык бывает очень сложно установить, является ли данное сочетание составным глаголом или простым словосочетанием синтаксического порядка. Поэтому при изучении глаголов движения, необходимо, в первую очередь, обратить внимание на следующие структурно-семантические особенности:

– свободные сочетания возникают тогда, когда деепричастие выражает обстоятельство, а следующий за ним глагол – основное действие.

– когда деепричастие и следующий за ним глагол – выражают действия, происходящие последовательно или параллельно. Например, *шәһәргә барып кайттым.* ‘Съездил(а) в город’. *Кибеткә кереп чыкты.* ‘Вошла в магазин и вышла’. В приведенных примерах сочетания деепричастие – глагол в личной форме по структуре напоминают составные глаголы, однако своим содержанием коренным образом от них отличаются. Такие глаголы не образуют единого значения, а выражают два разных антонимичных друг-другу видов движения: *бару* ‘поехать*’* и *кайту* ‘приехать*’*, *керү* ‘зайти*’* и *чыгу* ‘выйти*’*.

Составные же глаголы движения выражают одно новое лексическое значение и в связи с этим в предложении носят единую для них синтаксическую функцию в качестве одного из членов предложения [2: 134–135]. Например, в предложении *Галия сәхнәгә менеп китте. ‘Галия поднялась на сцену*’ составной глагол выражает одно действие и в предложении является самостоятельным членом – сказуемым. Семантическая структура глаголов движения татарского языка в большей части значений совпадает с аналогичной структурой глаголов движения русского языка. Глаголы обоих языков развивают переносные значения, связанные со сменой субъекта действия, что по-видимому, объясняется сходством свойств данных субстанций, способных восприниматься органами чувств. Категории способа и направления действия в русском языке могут быть совмещены в одной лексеме: *карабкаться, лезть* [1: 67]. В татарском языке названные категории выражаются обычно разными аналитическими глаголами или глагольными сочетаниями, отображающими один денотат: *менеп бару ‘подниматься*’, *кереп басу ‘войти и остановиться*’, *‘войти и встать*’, *үрмәләп менү ‘карабкаться*’, *‘лезть‘, сөйрәлеп бару*’, *‘плестись*’ и др.

В процессе преподавания татарского языка русскоязычным учащимся, исключительную важность приобретает учет национального своеобразия семантической структуры глаголов. Так например, в речи у русскоязычных студентов в первые годы их обучения татарскому языку значительное место имеет трансференция. Лексико-семантическая трансференция в речи

у студентов заключается в том, что происходит перенесение значения тождественного по смыслу слова одного языка в другой язык. Механизм этого процесса заключается в том, что двуязычный учащийся в целях выражения того или иного значения использует не контекстуальное, а основное словарное соответствие. Например, обучающийся татарскому языку может сказать *кар бара* '*идет снег*' (правильно: *кар ява*), *өйгә килү* 'приходить домой' (правильно: *өйгә кайту), мәктәпкә килү* 'идти в школу' (правильно: *мәктәпкә бару*) и т.д.

В обучении правильному употреблению глаголов движения необходимо выделить 4 этапа. На первом этапе, когда учащиеся изучают падежи пространственного значения (*кая?* 'куда?', *кайдан*? 'откуда?'), вводятся основные глаголы движения, такие как *килү, китү, керү, чыгу.* На этом этапе необходимо подчеркнуть, что татарский глагол *бару* означает одновременно и 'идти' и 'ехать', глагол *китү* – 'уйти' и 'уехать', *кайту* – 'прийти', 'приехать', так же стоит отметить значение повторяемости у глаголов *йөрү* и *бару.*

На втором этапе изучаются аналитические глаголы движения. На наш взгляд, эту тему целесообразно вводить после ознакомления учащихся с структурно-словообразовательными особенностями татарского языка. На данном этапе рационально рассмотреть глаголы движения, которые выполняют модифицирующую роль: *укып бару* 'читать регулярно', *укып чыгу* 'дочитать'.

На третьем этапе изучаются глагольные фразеологизмы. Здесь рассматриваются фразеологизмы с компонентами «бару», «төшү», «килү» и т. п. Например: *чыгырдан* ***чыгу*** 'выводить из себя' – раздражаться; *аңга* ***килү*** 'приходить в себя' – успокаиваться; *рух* ***төшү*** 'падать духом' – унывать, отчаиваться. Очень важной задачей на этом этапе является грамотная подборка эквивалентов фразеологизмов на русском языке.

Таким образом, изучение глаголов движения татарского языка в русскоязычной аудитории остается актуальной и сложной задачей. Процесс изучения осуществляется поэтапно, требует определенных методов и тщательного подбора дидактических материалов.

Подводя итоги, можно констатировать следующее: были выявлены тождественности и различия глаголов движения в татарском и русском языках. Несмотря на не родственность исследуемых языков, обнаружено много схожестей в значении и употреблении глаголов движения. Результаты проведенного исследования могут быть использованы для дальнейшего изучения грамматического строя татарского и русского языков и вместе с тем могут помочь решить ряд важных практических лингводидактических задач, связанных с проблемами изучения глаголов движения татарского языка.

ЛИТЕРАТУРА

1. Аминова А. А. Семантико-словообразовательный диапазон глаголов русского, татарского и английского языков // Ученые записки Казанского университета. 2008 г. Т. 150. Кн. 2. Серия гуманитарных наук. – С. 64–71.

2. Ганиев Ф. А. Образование сложных слов в татарском языке. – Казань: Печатный двор, 2002. –192 с.

3. Гилазетдинова Г. Х., Салахова Р. Р. Семантические особенности глаголов поступательного движения в татарском языке // Филология и культура. 2016. – № 1(43). – С. 48–52.

4. Суванова В. Б. Лексико-семантическая группа глаголов движения в тувинском языке (в сопоставительном аспекте): автореф. дис. … канд. филол. наук. – Новосибирск, 2006. – 23 с.

5. Татарская грамматика: в 3-х т. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1993. Т. I. – 584 с.

6. Татарская грамматика. Т. II. Морфология. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1993. – 397 с.

# ПУТИ ФОРМИРОВАНИЯ КОММУНИКАТИВНОЙ КОМПЕТЕНЦИИ УЧАЩИХСЯ В ПРОЦЕССЕ ОБУЧЕНИЯ РОДНОМУ(ТАТАРСКОМУ) ЯЗЫКУ, ЛИТЕРАТУРЕ

**З. Г. Саляхова**

*Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение «Гимназия № 10» Авиастроительного района г.Казани, Россия*

zuhra.idrisova@yandex.ru

# WAYS OF FORMATION OF STUDENTS' COMMUNICATIVE COMPETENCE IN THE PROCESS OF TEACHING NATIVE (TATAR) LANGUAGE, LITERATURE

**Z. G. Salyakhova**

*Municipal budgetary educational institution «Gymnasium No. 10» of the Aviastroitelnaya district of Kazan, Russia*

zuhra.idrisova@yandex.ru

В практике преподавания родного (татарского) языка и литературы могут применяться различные методы и приемы для формирования коммуникативных компетенций. Но при этом нельзя забывать, что развитие ее направлено на выражение учеником своих мыслей, чувств, желаний. В ходе обучения ученик должен научиться ориентироваться в любых речевых ситуациях, уметь строить монологические и диалогические высказывания, развивать творческое мышление, а все это способствует развитию нравственной личности ребенка. Развитие коммуникативной компетенции на уроках – одно из главных направлений работы учителя.

Формирование коммуникативной компетенции на уроках родного (татарского) языка и литературы способствует разностороннему развитию языковой личности ученика, а также предполагает необходимость гармоничного сочетания собственно учебной деятельности, в рамках которой формируются базовые знания, умения и навыки, с деятельностью творческой, связанной с развитием индивидуальных задатков учащихся, их познавательной активности, творческого.

**Ключевые слова:** Формирование коммуникативной компетенции, речь и речевое общение, речевая деятельность, диалог, текст, учащиеся.

Various methods and techniques can be used to form communicative competencies in the practice of teaching native (Tatar) language and literature. At the same time, we must not forget that its development is aimed at expressing the student's thoughts, feelings, desires. During the training, the student must learn to navigate in any speech situations, be able to build monological and dialogical statements, develop creative thinking, and all this contributes to the development of the moral personality of the child. The main direction of the teacher's work is the development of communicative competence in the classroom.

The formation of communicative competence in the lessons of the native (Tatar) language and literature contributes to the versatile development of the student's linguistic personality, and also implies the need for a harmonious combination of the actual educational activities, within which basic knowledge, skills and abilities are formed, with creative activities related to the development of individual inclinations of students, their cognitive activity, creative.

**Key words:** Formation of communicative competence, speech and speech communication, speech activity, dialogue, text, students.

# ТУГАН ТЕЛ (ТАТАР ТЕЛЕ) ҺӘМ ӘДӘБИЯТ УКЫТУ БАРЫШЫНДА УКУЧЫЛАРДА КОММУНИКАТИВ КОМПЕТЕНЦИЯ ФОРМАЛАШТЫРУ ЮЛЛАРЫ

**З. Г. Сәлахова**

Бүгенге көндә туган (татар) тел һәм әдәбият укыту бөтен мәгариф системасында сизелерлек үзгәреш шартларында гамәлгә ашырыла. Белем бирүнең сыйфатын күтәрү дә актуаль проблемаларның берсе булып тора. Бу проблеманы хәл итү мәгариф эчтәлеген модернизацияләү, белем бирү процессын оештыру ысулларын һәм технологияләрен оптимальләштерү аша тормышка ашырыла.

Россия мәгарифен модернизацияләү концепциясе шуны ассызыклый: үз мөмкинлекләрен максималь рәвештә тормышка ашырырга омтылучы, төрле ситуацияләрдә аңлы һәм җаваплы сайлый белүче, яңа тәҗрибәне кабул итәргә сәләтле шәхес тәрбияләү өчен, иң беренче чиратта, коммуникатив компетенцияне формалаштырырга кирәк.

Шуңа күрә коммуникатив компетенцияне формалаштыру – хәзерге вакытта мәктәпнең төп бурычларыннан берсе. Коммуникатив компетенция үз эченә әйләнә-тирә кешеләр һәм вакыйгалар белән аралашу ысулларын, төркемдә эшләү күнекмәләрен, коллективта төрле социаль рольләрне белүне ала.

Коммуникатив компетенция – укучыларда сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләренә караган ныклы күнекмәләр формалаштыруны күздә тота. Мәсәлән, сөйләм эшчәнлегенең төрләре (тыңлап аңлау, сөйләү, уку, язу) аша укылган яки тыңланган текстның темасын, төп һәм өстәмә фикерен аңлау; текстны файдаланып, әңгәмә үткәрү, төрле стильгә һәм жанрга караган текстларны дөрес уку һәм аңлау; тәкъдим ителгән темалар буенча диалогик һәм монологик сөйләм оештыру (парлап эшләү); төрле чыганаклардан мәгълүмат туплау; сүзлекләрдән һәм электрон чаралардан дөрес файдалану; сөйләм этикеты нормаларын белү, аларны сөйләмдә дөрес куллану һ.б.

Дәресләрдә эш формалары, методлары һәм алымнары шуңа юнәлдерелгән булырга тиеш: бирелгән материал укучыларга проблеманы мөстәкыйль рәвештә хәл итүче чыганак ролен генә үти. Бу планда инновацион педагогик технологияләрне куллану зур роль уйный. Коммуникатив технологияләр иҗади активлыкны үстерә, фикерләү эшчәнлеген формалаштыра, укучыларны үз карашларын якларга өйрәтә, материалны тирәнрәк аңларга ярдәм итә

Коммуникатив компетенциянең ике алымын күрсәтеп үтәргә мөмкин.

